Сөембикә

№9 • СЕНТЯБРЬ • 1997 ел

ISSN 0869–1398



Рәисә

САХИЕВА:

"Сөембикә манарасы, борынгы диварлар, хан мәчете хәрабәләре— гаделлек әнә шул ерак гасырлар аша аваз сала".



Ак һәйкәл

Татар Анасына салынган беренче һәйкәл. Скульптор Альфред Әбдерәшитов эше.

Аналар сагынуы, Аналар әрнүе бу сында!

Йә, нинди мәңге бетмәс, мәңге онытылмас җәрәхәт бу?! Югыйсә, тыныч җәй таңын туплар шартлавы сискәндереп уятканга, зәңгәр күк йөзен кайгы пәрдәсе каплаганга да ничәмә-ничә еллар үтте бит инде. Шулай да йөрәк һаман сыкрый, һаман сулкылдый.

Безгә — сугыштан соң туган буынга — утлы чор вакыйгалары тарих аша, китаплар, кинофильмнар аша килеп ирешә. Ата-бабаларыбыз истәлегенә калкып чыккан һәйкәл-обелисклар шул хакта искәртә.

...Мамадышлылар бу көнгә тәфсилләп әзерләнделәр. Югыйсә, өч көн тоташ койган яңгыр, Нократ елгасы ягыннан искән салкын җил аларны шактый борчуга салган иде.

Бәхеткә, 22 июнь көнне ялтырап кояш чыкты. "Менә бит, Ходайның рәхмәте", — диеште күкрәкләренә орден-медальләр тагып, шәһәр үзәге — Хәтер аллеясына юл тоткан ветераннар — изге гамәл өчен көне дә уң килеп тора бит аның".

Ватан-ана хакына яу кырында шәһит киткәннәрне искә алырга килүчеләр арасында төрле буын вәкилләре бар. Халык җыелып бетүгә, бер төркем кунаклар иртеп район хакимияте башлыгы Әгъзам Гобәйдуллин да килеп җитте.

Күзләребез өстенә ак җәймә бөркәнгән һәйкәлгә төбәлгән. Әнә, ул акрын гына түбәнгә шуыша. Барысы да, ак сынга карап, тынып кала. Ул телгә килер дә:

"Улларым сугыштан кайтмады,
Кайтты тик: "Көт!" дигән хатлары.
Өзелеп көтәм мин һәр таңны,
Улларым әйләнеп кайтмады", —дип

янә юксынуын дөньяга чәчәр кебек.

Илебез иминлеге өчен көрәштә 8 баласын югалткан уртакирмәнле Фатыйха әби Әхмәдиевага һәйкәл ачу тантанасы ачык дип белдерелә. Район хакимияте башлыгы, бу изге гамәлнең башында йөрүче "Казан утлары" журналының бүлек мөхәррире Шаһинур Мостафин, академик Әхмәт Галиев, Фатыйха әбинең оныгы Мәрзия Бикмурзина, сугыш һәм хезмәт ветераннары Любовь Штягина, Дмитрий Манунов чыгышларына "Солдатлар" җыры кушыла. Ак һәйкәл, типтын калып, якташларын тыңлый.



Фатыйха әби Әхмәдиеваның оныгы Мәрзия Бикмурзина.

Соңгы көннәрендә Фатыйха әби:

"Иртән торып тышка чыксам,
Ай түгәрәк шикелле...
Үзем үлсәм, җаным кайтыр
Ак күбәләк шикелле", — дип көйли торган була.

Аның ак күбәләк булып кайткан җаны арабыздадыр, кайдадыр шушында, янәшәдә генә йөридер сыман. Ни дип бәргәләнә микән ана җаны? Бәлкем, "Газизләрем турында бер-бер хәбәр килмәсме?" — диган уй тынгы бирмидер аңа.

Күз нурыдай саклап үстергән баланы югалтудан да авыррак кайгы бар микән дөньяда?

Фатыйха белән Фәттах Әхмәдиевлар сугыш кырында бер-бер артлы 8 улларын югалталар: иң элек гражданнар сугышында Исмәгыйль башын сала. Аннары — Бөек Ватан сугышында — Ибраһим, Мөгътәсим, Мөхлисулла, Мәгъсумҗан, Габделбарый, Мисбахетдин, Әгъмәлетдин. Һәркайсы батырларча һәлак була. Мисбахетдин исә легендар капитан Гостелло батырлыгын кабатлый.

Ут эченнән кайгы кәгазьләре килә башлагач, Фәттах абзыйның йөрәге түзми, вакытсыз гүргә керә.

9 Майга бары төпчек уллары — Әгъмәлетдин генә исән кала. Тик ул да, японнар белән сугышта, Газинур Гафиятуллин шикелле, гәүдәсен дошман пулеметы өстенә куя.

— Әгъмәлетдин абзый әбиемнең соңгы өмете иде, — дип искә ала Фатыйха әбинең оныгы — 7 бала анасы Мәрзия апа Бикмурзина. — Аннан хатлар гел килеп торды. 1945 елда элемтә өзелде. Шулай берчак күрше Миңсылу түтигә ияреп, якындагы Чытыр авылына — аның яңа гына сугыштан кайткан энесе Мәгъсумҗан абый Юнысовларга мендем. Шунда ишеттем дә инде абыйның дошман дзотын күкрәге белән томалап, батырларча һәлак булуын. Сабый гына бит әле ул чагында мин. Йөгереп кайттым да, әбигә түкми-чәчми сөйләп бирдем. Гаҗәеп сабыр иде әбием, кайгысын күрсәтмәде. Икенче көнне ул бик хәстәрләп Мәгъсумҗан абый янына барырга җыена башлады. Тәмле ризыклар пешерде, улларына атап җыйган чикләвекләрен янчыкка тутырды. Бәйрәмнәрдә генә кия торган бөрчекле ак күлмәген киде, ак яулыгын бөркәнде дә, мине дә үзе белән ияртеп, җәһәт-җәһәт атлап Чытырга юл тотты.

Килеп кердек. Мәгъсумҗан абый әбекәйгә күтәрелеп карый алмый. Борчыла инде.

Әби шулчак:

— Улым, син миңа Әгъмәлетдин кебек бик якын, һәммәсен дә яшермичә генә сөйләп бир әле, — диде. Солдат барысын да бәйнәбәйнә сөйләде.

Әби, үзе белән бергә картайган таягына таянып, газиз улларының исемнәрен берәмтекләп кабатлыйкабатлый: "Кайда ятасыз сез хәзер, балакайларым?" — дип, үзалдына сөйләнеп кайтты.

Ана урын өстенә егыла. Үләр алдыннан ул болай ди: "Улларымны күрермен дип өметләнгән идем, кайтмадылар инде. Ләгънәт кенә төшсен бу йөзе кара сугышка, аны башлаучыларга. Минем кебек чәчләре вакытсыз агарган аналарның, улларым кебек, гомерләре иртә өзелгән балаларның ачы нәфрәте эзләп тапсын аларны..."

Каршыбызда бер кулына кече улының пилоткасын, икенчесенә — кыр чәчәкләре тоткан таш Ана. Ак яулыгын җилкәсенә төшереп бәйләгән. Аның сагыш тулы күзләре соңгы өмете — Әгъмәлетдин улы һәлак булган якка — Көнчыгышка төбәлгән.

Мәдинә АВЗАЛОВА.

Газинур Хафизов фотосурәтләре.



“Мерседес”та кем йөрер?



Татарстанның һәм Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре Асия Фәрит кызы ХӘСӘНОВА — күренекле җәмәгать эшлеклесе, талантлы журналист. Бөек Ватан сугышы вакытында тукталып, унҗиде ел чыкмый торган “Азат хатын” журналын торгызуга, аның чын үз йөзен тәгаенләүгә, баш мөхәррир буларак, зур өлеш кертә. Әлеге вазифаны армый-талмый 20 ел буе башкара. Бу чорда “Азат хатын” хатын-кызларның мәнфәгатьләрен яклаучы, әдәбият, мәдәният һәм сәнгать мәсьәләләрен үзәккә куючы иң популяр басма булып үсеп җитә.
А. Хәсәнованың каләме үткен, фикере нигезле. Ул вакытлы матбугатта үзенең аналитик язмалары белән катнашып килә. Асия ханымга август аенда 85 яшь тулды. Без юбилярга саулык-сәламәтлек, рухи күтәренкелек, иҗат уңышлары телибез һәм укучыларга аның чираттагы язмасын тәкъдим итәбез.

Асия Хәсәнова. 1945 ел.

Шагыйрь Әхмәт Гаделнең безнең, олы буын кешеләренең йөрәгенә аеруча нык тәэсир итә торган шигыре бар. “Калды...” дип атала ул.

Тиңсез илем минем бар иде,
Киңлегендә урман, тау иде.
Кырларында бихисап җаннар,
Күгендә кош, җирендә җанвар...
Еллар урладылар илемне,
Бердәнбер гүзәл җиремне,
Калды, калды моңлы җырларым,
Шомыртбашы, Мәшләк кырлары...

Шагыйрь үзе Мамадыш районының Ак чишмә авылында туган. Аны шигырь язарга илһамландырган Шомыртбашында исә ул эшләгән, авыл мәктәбендә балалар укыткан. Моннан күп еллар элек беренче мәртәбә бу авылга барып төшкәч, мин дә таң калган идем: күз күреме җир — аппак шомырт чәчәге белән капланган урманнар... аларның очыкырые юк сыман... баш әйләндергеч хушис... кошлар сайрый. Оҗмахның бер илаһи почмагы булып күренде миңа бу җир. Шул урманнар ышыгында Шомыртбашы авылы утыра. Нинди матур, нинди мәгънәле исем! Бу авыл минем өчен дә бик кадерле, анда минем ирем, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, профессор, берничә ел Казанның финанс-икътисад институты ректоры булып эшләгән керәшен егете Павел Васильевич Абрамов туып үскән. Авылларның гаҗәеп тылсымлы тарту көче бар. Авылда туып үскән кеше соңыннан кайда гына яшәмәсен: Казандамы, Мәскәүдәме, кояшлы Калифорниядәме, яки “Бер күргәч, үләргә дә мөмкин” дип даны чыккан Неапольдәме, барыбер, ул Татарстанда калган бәләкәй генә авылын өзелеп сагына, аны кайтып күрү турында еллар буена хыяллана. Павел да, эше никадәр генә тыгыз булмасын, ел саен авылына кайтып килә торган иде. Авыргач, кайта алмавын авыр кичерде, мәрхүм.

Күптән түгел шул гүзәл Шомыртбашыннан бер хат алдым. Автор минем кайбер язмаларым турында үзенең фикерләрен язган. Хатта түбәндәге сүзләр дә бар: “Син халык артисткасы Галия Булатова турындагы китабыңда: “Революциягә чаклы хатын-кыз бәхетсез булып туа, бәхетсез булып яши иде...” — дип язгансың. “Без бәхетлеме соң?” — дип сорый ул миннән. Хатын-кызның ачы язмышы турында матбугатта еш укырга туры килә. Моннан бер-ике ел элек журналист Венера ханым Ихсанова хатын-кызлар турындагы мәкаләсен хәтта “Без кемгә кирәк?” дип исемләгән иде. Бу сораулар бүген генә тудымы? Хатын-кызның ачы язмышы турында Тукай да, Фатих Әмирхан да, Мәҗит Гафури да, Галимҗан Ибраһимов та, рус һәм башка милләт әдипләре дә язды. Моннан ике йөз еллар элек туган инглиз әдибе Уильям Теккерей үзенең атаклы романы “Шөһрәт ярминкәсе”ндә (“Ярмарка тщеславия”) менә нәрсәләр яза: “Хатын-кызларның газаплы тормышы турында ирләр нәрсә белә? Хатын-кызларның күпчелеге зур түземлелек белән көн саен кичерә торган газапларның ирләргә йөздән берен генә татырга туры килсә дә, без акылдан шашар идек. Шуның өстенә әле ул иреннән бер генә җылы сүз дә ишетми”. Хатын-кызның көндәлек эшен, тормышын әдип берничек тә бәяләнми, тәкъдир ителми торган коллык дип атый. “Өзелеп яратучы коллар”, — ди әдип хатыннар турында. Уйласаң гаҗәпкә каласың: бу коллыкка без, утка очкан күбәләк кебек, үзебез теләп керәбез ләбаса! Дөресрәге, бу коллыкны үзебез тудырабыз түгелме? Иргә чыгуга, ире белән тигез эшләп килүче хатын, бер кеше кушмаса да, өйдәге барлык эшне үз өстенә ала: юа, җыя, себерә, чистарта, пешерә, кисә-тегә, базардан, кибеттән азык ташып, гаиләсен туйдыра, бакчада эшли, еш кына үзләре белән бергә торучы ата-аналарын бага. Балаларын йөгерә-йөгерә бакчага илтә, йөгерә-йөгерә мәктәпкә ата-аналар җыелышына йөри, балалар авырса, аларны шифаханәгә йөртеп дәвалый, кирәк булса, айлар буе шифаханәдә баласы янында тора. Болар белән генә канәгатьләнмичә, күп хатыннар балаларын музыка мәктәпләренә, каратэ, дзюдо һәм спортның башка төр түгәрәкләренә, чит телләрне өйрәнү дәресләренә йөртәләр. Чын марафон! Кыскасы, ханым үз теләге белән ике камыт киеп куя. Ни өчен бу эшләрне барысын да без, хатын-кызлар, эшләргә тиеш? Уйлыйбызмы без бу турыда? Хатын беркайда да эшләмичә өйдә генә утырса бер хәл иде. Әмма, кагыйдә буларак, күпчелеге эшли бит. Алай гына да түгел, иренә караганда җаваплырак эштә эшләп, хезмәт хакы югарырак булган ханымнар да өйдәге барлык эшне үз җилкәләренә салалар. Гади инженер булып эшләүче аю кебек зур гәүдәле ирне быел, алтмышы тулуга, сәгате-минуты белән пенсиягә озаттылар. Күрәсең, эшләп әллә ни кинәндермәгәндер. Шул ир һәр көнне көндез икешәр сәгать йоклап ял итеп ала. Ә аның зур гыйльми исемнәре булган хатыны институттан сулышы кубып, атылып кайтып керә дә, ашарга әзерли, аннан бакчасына китә. “Нишләп иреңне эшләтмисең”, — дим.

"Әй, аңа ярты көн ялынырга кирәк, аның белән ызгышып торганчы", — ди ул.

Көнбатыш матбугаты Рәсәй хатын-кызларының иртәдән кичкә кадәр ишәк кебек карусыз эшләүләре турында әледән-әле гаҗәпләнеп яза. Ир шулай эшләгән хатынның кадерен белсә, хезмәтен тәкъдир итсә әле бер хәл. Кайберләре хатыннарын кыйныйлар, аны ямьсез сүзләр белән рәнҗетәләр. Моннан ике ел элек танылган язучыбыз Нәбирә Гыйматдинованың "Кыргый" исемле тетрәндергеч повесте басылып чыкты. Авылның уңган чибәр кызы Җәмилә Идрис исемле егеткә иргә чыга. Туйдан соң атнаун көн дә узмый, Идрис хатынын аның югалтканчы типкәләп кыйнап ташлый. Ничек кенә мәсхәрәләми ул хатынын: аңа исеме белән дәшү юк, ул "аңгыра сарык", "кибәк баш", "хатын сәләмәсе"... Бу вакыйгалар революциягә чаклы булган хәлләр түгел бит, Җәмилә дә, Идрис тә — безнең замандашлар. Хатынны кыйнау — наданлык, кыргыйлык билгесе. Күп еллык тарихы, зур әдипләре, галимнәре булган татар халкының вәкиленә, мөселманга бу хурлык түгелме? Ул әлеге кыргый гамәлләре белән бөтен татар халкының йөзенә кызыллык китерә ич.

Атаклы детектив остасы Агата Кристидан: "Сезнең сюжетлар ничек туа?" — дип сорагач, ул: "Савыт-саба юганда минем кемне булса да үтерәсем килә", — дигән. Әнә шундый ачу китергеч, үлгәнче бетми торган эшләрне ирләрнең кайсы җитди эш дип карый? Кайсысы тәкъдир итә? Ә инде берәребезнең ире зур галим яки күренекле язучы, композитор яки җаваплы эштәге шәхес булса, әйткән дә юк инде: аңа "тиешле шартлар" тудыру өчен хатын "бите белән җир себерә". Менә еллар уза, ханым Стефан Цвейг тасвирлаган авыр эштән "янган", йончыган кин сөякле карт алаша кебек ямьсез Лепореллаңи, яки Әмирхан Еникинең "Яшьлек хатасы" исемле хикәясендәге "аягүрә сүнгән" Зөбированы хәтерләтә башлый. Ә гомере буе үзе яраткан эш белән генә шөгыльләнгән ире, кадер-хөрмәттә яшәгән чабыш аты кебек, уйнаклап тора. Әмма ханым бу үтергеч аерманы күрми. "Менә балалар да үсеп җитте, бер бүлмәдә күмәкләшеп яшәмиләр, чиратлар, акчасызлык, ярлылык инде артта калды кебек. Матди ягыбыз яхшырды, машинабыз да бар. Хәзер ирем белән парлашып театрларга, кичәләргә йөрергә, машинага утырып, Идел, Кама буйларын урап кайтырга, чит илләрне дә барып күрергә мөмкин", — дип хыялланa ханым. Әмма еш очракларда, бигрәк тә бүгенге "яңа заманнарда", "Мерседес"та ул түгел, яшь хатын йөри.

Танып ханым сөйли: "Көне буе бакчада җиләк-җимеш җыеп, ике кулыма ике авыр әрҗә тотып өйгә кайтып төштем. Без 14 нче катта торабыз. Карасам, лифт эшләми. Шуны күргәч, кулымнан әрҗәләрем төшеп китте", — ди. Казанда һәр көнне 95 лифт ремонтта тора икән. Аларның кайберләре ярты шар ел ремонтта. Ярты ел 10-14 нче катка менеп-төшеп йөр әле?! Эшләми торган лифтлар, ватык краннар, айлар буе сусыз утыру, әледән-әле ватылып үзәккә үтә торган батареялар хатын-кызның хәлен әйтеп бетергесез авырайта. Ир-егетләребез эшли торган эшләр бит болар! Европа ханымнары Татарстан газыннан утыз елга якын файдаланып, рәхәттә яшиләр. Безнең нефть чыганаклары янындагы авылларның кайберләрендә әлегә кадәр газ да юк. Ул авылларда чын ирләр юкмы әллә?

Барлык туйларда әйтелә торган теләкләрнең берсе — үлгәнче бергә яшәгез. Моның ни дәрәҗәдә әһәмиятле икәнен кешеләр бөтен тирәнлеге белән картайгач кына аңлыйлар. Бар бит дөньяда тормыш юлын ире белән бергә узган бәхетле хатыннар! Әдәбиятыбызның олуг шәхесләре Гариф Ахунов һәм Нурихан Фәттахларның гаиләләренә сокланам мин. Бу гаиләләрдә бер-берсенә булган тирән хөрмәт, бер-берсе турында кайгырту, бер-берсенә ярдәм итәргә тырышу ирләргә дә, хатыннарына да үз өлкәсендә җитди иҗади уңышка ирешергә, менә дигән балалар тәрбияләп үстерергә мөмкинлек бирде.

Шомыртбашыннан килгән хатның авторына "Сеңлем, бәхетле булу — безнең үз кулыбызда. Моның өчен ямьшшыны билгели торган гамәлләреңне уйлап эшләргә, иң әһәмиятлесе, сине ярата да, ихтирам да итә торган җитди егеткә иргә чыгарга, тормышыңны корып җибәргәч, өй эшләренә, иреңнең һәм балаларыңның хезмәтчесенә әйләнмәскә. Ирене ярату ул әле аның аяк астында туфрак булу дигән сүз түгел. Хикмәт менә шунда", — дип җавап бирәсем килә.

Асия ХӘСӘНОВА.



Икенче Бөтендөнья татар конгрессында

29 августта Казанда, Татарстан дәүләт Зур концерт залында Икенче Бөтендөнья татар конгрессының пленар утырышы булды. Аны Татарстан Республикасы Премьер-министры Фәрит Мөхәммәтшин ачып җибәрде.

Аннан соң Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәрип улы Шәймиев чыгыш ясады. Ул үзенең чыгышында татар милләтенең бүгенге дөньяда тоткан урынына анализ ясады, лаеклы киләчәген тәэмин итүнең алшартларына тукталды. Моның гаранты, диде ул, Татарстан Республикасының суверенитеты.

Конгресска Австралия, Германия, Канада, Румыния, Америка Кушма Штатлары, Төркия, Финляндия, Чехия, Япония, Әзәрбайҗан, Беларусь, Казахстан, Украина, Үзбәкстан, Балтыйк буе илләреннән, Россия Федерациясенең 60ка якын төбәгеннән һәм Татарстанның үзеннән 459 делегат катнашты. Делегат булып сайланучылар — милләтебезнең күренекле шәхесләре — галимнәр, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләре, дин әһелләре... Алар арасында Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиев, Россиядә танылган хәрби җитәкче Рәсим Акчурин, Мәскәү физтехника институты директоры Камил Вәлиев, Башкортостан Фәннәр академиясе президенты Роберт Нигъмәтуллин, Татарстан Фәннәр академиясе президенты Мансур Хәсәнов, Саратов шәһәрендәге "Идел" милли-мәдәни үзәге рәисе профессор Фрид Рәшитов, Литваның татар мәдәнияте үзәге президенты Адомас Асанавичюс һәм башкалар бар иде.

Делегатларның 18 проценты — хатын-кыз. Яшьләре 30га кадәр булган делегатлар — 2 процент, 30дан 50гә кадәр — 25 процент, 50 яшьтән соң 73 процент тәшкил итте. Иң зур делегацияләр — Татарстан, Башкортостан республикаларыннан, Мәскәү, Казахстан, Үзбәкстан, Украина, Санкт-Петербург, Белорусиядән икәнлеге мәгълүм булды.

Конгресста Россия Премьер-министрының милләтара мөнәсәбәтләр буенча урынбасары Рамазан Абдулатипов, Башкортостан Республикасы Президенты Мортаза Рәхимов, Россия Федерациясе Дәүләт Думасының милләтләр эше буенча комитеты рәисе Владимир Зорин, медицина фәннәре докторы, кардиолог Ренат Акчурин, Монреаль университеты профессоры Люк Дюамель, төрки телле илләрнең мәдәниятне һәм сәнгатьне үстерү буенча халыкара оешмасы — "Төрксой"ның генераль директоры Полад Бил-Бил оглы, Әстерхан өлкәсе губернаторы Анатолий Гужвин, мәшһүр сәнгатькәрләр — Фәридә Кудашева, Мостай Кәрим, Нажар Нәҗми, Гомәр Бәширов, Әмирхан Еники, Төркиядән профессор Надир Дәүләт кебек дәрәҗәле, олы кунакларның күп булуы әлеге форумның югары дәрәҗәсен дәлилли.

Рамазан Абдулатипов Россия Президенты Б. Ельцинның һәм Россия хөкүмәте Рәисе В. Черномырдинның Икенче Бөтендөнья татар конгрессына котлауларын җиткерде. Аның "Яшәсен бөек татар халкы!" дигән сүзләреннән соң зал көчле алкышларга күмелде.

Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма Комитеты рәисе Индус Таһиров үз докладында Башкарма комитетның биш еллык эшчәнлегенә нәтиҗә ясады. Фикер алышулар вакытында татар милләтенең бүгенгесе һәм киләчәге турында гыйбрәтле чыгышлар яңгырады.

Пленар утырышта "Бөтендөнья татар конгрессы" халыкара иҗтимагый оешмасы уставы кабул ителде.

Конгресс татар халкына, Татарстан Президенты М. Шәймиевка, Россия Президенты Б. Ельцинга һәм халыкара оешмаларга мөрәҗәгатьләр һәм резолюция кабул итте, Башкарма Комитетның тәкъдим ителгән составын раслады. Башкарма Комитет рәисе итеп кабат академик Индус Таһиров сайланды.

Абунә-98

Гаилә — бәхет ачкычы, ди халык мәкале. Ә кеше җиһанга бәхет өчен туа. Бәхет үз чиратында фәкать гаилә аша гына килә. Чөнки гаилә инсаниятнең дәвамлылыгын тәэмин итүче бердәнбер илаһи оя. Динебез дә гаилә мәсьәләләрен һәрвакыт игътибар үзәгендә тоткан. Шуңа күрә мөселманнар арасында никахны өзү бик сирәк күренеш.

Коммунистик тоталитар режим исә никахның бу алтын кагыйдәсен пыран-заран китереп ташлады. Шул рәвешле халыкны гасырлар буе энҗе бөртекләредәй җыелып килгән гореф-гадәтләреннән мәхрүм итте. Моның нәтиҗәсе искиткеч аяныч: татар үз милләтеннән йөз җыера башлады. Кырык проценттан артык егет-кызларыбызның башка милләт вәкилләре белән тормыш коруы моңа ачык дәлил.

Милләтебезнең яңарышы, киләчәге әнә шушы югалган рухи кыйммәтләребезне кайтаруга бәйләнгән. Без кыл өстендә. Әмма сират күпере аша канатлы атка атланып хәвеф-хәтәрсез чыгу мөмкинлеге дә бар. Моның өчен бөтен дөньяга танылган мәшһүр "Сөембикә" журналы киңәшләрен генә тотарга кирәк.

Бәйлисе бар йөрәкне

Башына кайгы-хәсрәт төшкәндә сыенып урын, киңәшер кеше таба алмаучылар да байтак әле тирә-ягыбызда. Мондый очракларда нишләргә соң? Язмышка буйсынып яшәргәме? Әлеге сорауларга җавап эзләп тәмам аптырагач, газета-журналларга хат язып киңәш сораучылар да юк түгел. "Сөембикә"гә дә күп килә андый эчтәлекле хатлар. Шуларның берничәсен сезгә дә тәкъдим итәбез.

"Хөрмәтле редакция!"

Мин дә бүген ерак чакрымнар аша яраткан журналым "Сөембикә"гә дәшәм. Томанлы тормышымда әле сүнеп җитмәгән яшәү учагына өмет очкыны кабызырдай сердәшче кирәк миңа.

Йөрәк әрнүләрем аша бу хатны язарга этәргән төп сәбәп — иремнең эпилепсия белән авыруы.

Бер-беребезне яшьли яратышып өйләнештек без. Аның авыруы турында кияүгә чыкканчы ук белә идем. "Шулай булгач, күрә-белә торып нигә тормышыңны авыру кеше белән бәйләдең соң?" — диючеләр дә булыр, мөгаен. Тик нишлим, йөрәккә боерык биреп булмый, диләрме әле? Бөтен җаным-тәнем, булмышым белән яраттым мин аны.

Кияүгә чыккач, әнә шул көчле яратуым белән терелтмәкче булган идем. Ниндидер эчке җан авазы да: "Ул тереләчәк!" —дип дәшкән кебек иде.

Гаилә корып яшәвебезгә менә ике ел булды, кечкенә кызыбыз үсеп килә. Авыру ир белән нәни бала тәрбияләүнең кыенлыкларын үзенең башына төшкән кеше генә аңлый. Һәрвакыт күңелнең бер җире китек, йөрәк тыныч түгел. Соңгы вакытларда бигрәк тә ешайды аның авыруы.

Туганнарым да ярага тоз сибеп торалар. Юатыр урынга, ташла да кит, нигә җәфаланасың, дөньяда ир беткәнмени сиңа, диләр. Әйе, әйтүе җиңел. Йә, ничек итеп ташлыйм мин аны? Ул бит газиз баламның атасы, яраткан ирем. Мин ташласам, кемгә кирәк ул? Аның дөньяда яшәү мәгънәсе дә бер мин бит.

Ул үзе дә мине бик ярата, хөрмәт итә, тавыш күтәреп эндәшкәне дә юк. Авырса да, гаилә өчен барын булдырырга тырышып яши.

— Дөньяда Ходай язган барлык авырлыкларга да чыдарлык көчем бар. Тик бернәрсәгә, синең мине ташлап китүеңә генә түзә алмам, — ди үзе дә. Шул ук вакытта ул миңа: "Бик авыр булса, кит, түзәргә тырышып карармын", — дип тә юата.

Бик авыр чакларда да мин аңа күз яшемне күрсәтергә тырышмыйм. Ялгызым калганда гына эчем бушанганчы үксеп-үксеп елыйм. Елыйм, әмма язмышымны аның белән бәйләгәнгә үкенеп түгел, аңа ярдәм итә алмаганыма, шул авыру алдында көчсезлегемнән гарьләнеп елыйм.

Кояш чыгып, ай батканчы Ходайдан иремнең терелүен сорап ялварам. Әмма күз яшьләре белән генә ярдәм итеп булмый шул.

Ишетүемчә, эпилепсия авыруы белән бик күпләр интегә, шул сәбәпле күпме гаиләләр таркала. Медицина зур үсеш алган бу заманда әлеге авыруга каршы берәр чара уйлап табып булмый микәнни соң? Бәлки, чит илләрдә дәвалый алалардыр? Байлыгым булмаса да, көчемнән килгәнчә тырышырга әзермен, иремне генә терелтсеннәр!

Кешеләр, зинһар ярдәм итегез! Йортыма кайчан да булса шатлык иңәр дигән өметләр белән яшим мин бүген.

Башкортостан.
Миләүшә".

"Сөембикә"—

"Сөембикә" — гаилә журналы.

"Сөембикә" — телебезне, динебезне, гореф-гадәтләребезне, хак тарихыбызны һәм, әлбәттә, татар милли гаиләсенең традицияләрен торгызу юнәлешендә максатчан эш алып баручы бердәнбер басма. Әгәр сезне татар милләтенең киләчәге борчый икән, "Сөембикә"— сезнең өчен иң кулае, иң кирәклесе.

"Сөембикә" — күпкырлы басма. Аның сәхифәләрендә әдәбият һәм сәнгать әсәрләре дөнья күрә. Укучыларыбызның күңеленә хуш килгән "Моң бишеген кем тибрәтер?" рубрикасы 1998 елда да дәвам иттереләчәк. Сезнең үтенечегез буенча "Әнигә дә, бәбигә дә", "Татар дөньясы", "Минем каенанам — мировой!", "Гасыр чаңы ни хакында?" кебек элекке рубрикалар шулай ук журналда урын алачак.

Ана һәм Баланы, гомумән, хатын-кызны социаль яклау — журналыбызның төп темасы. Ул тагын да системалырак төс алыр, дип ышандырабыз. Бизнес, базар икътисады, эшмәкәрлек мәсьәләләре дә читтә калмас. "Айсылу" кушымтасының офыклары киңәер.

Әйе, язмышны берәү дә сайлап алмый. Ул безнең тормышта, ак җеп булып сузылып, баштан ахыргача бара да бара....

Миләүшә, Ходайның сиңа биргән язмышын сынау дип кабул итеп, фаразлап карыйк әле. Гадәттә, мондый зур сынаулар бары тик рухи яктан көчле кешеләргә генә бирелә. Синең авыру кеше белән бәйләнгән тормышың да шуңа ачык мисал. Хатыңнан күренгәнчә, син җаның-тәнең белән ireңне терелтергә омтыласың. Әлеге изге ният үзе генә дә олы җанлы, миһербанлы кеше булуыңны дәлилли. Әлбәттә, үз тормышыңа син үзең хуҗа һәм аны үзгәртергә дә бары тик үзең генә хаклы. Бу рухи халәт, рухи вазгыять. Шунлыктан, сиңа авыруларга язылган дару рецепты кебек тәгаен генә киңәш тә биреп булмый. Дөресен әйткәндә, ул рецепт синең үз кулыңда. Минемчә, дәваны син еллар аша табачаксың. Бик теләсәң, әлбәттә.

Ә хәзергә, әйдә, бу мәсьәләдә психология фәннәре кандидаты Людмила Федоровна БЛИНОВАның кыска гына киңәшен тыңлап карыйк.

— Эпилепсия белән авыручы кешенең тормышы иң элек ул яшәгән тирәлеккә, гаиләгә бәйләнгән була. Һәм бу очракта авыруны кешеләрнең рухи мөнәсәбәте даруга караганда да тизрәк һәм нәтиҗәлерәк дәваларга мөмкин.


Әлеге җәһәттән конкрет бер мисалга тукталып китү дә урынлы булыр дип, мөгаен. Мин, психолог буларак, унбиш ел элек бер яшь гаилә белән танышкан идем. Бу гаиләдә 20 яшьлек ир-егет эпилепсия белән авыручы кызга өйләнде. Матур гына яшәп киттеләр. Тик тора-бара әлеге авыру үзенең барлыгын белдерә башлый. Егетнең әти-әнисе малайны тизрәк хатыннан аерту хәстәренә керешә. Әмма яшь ир сөйгәнен ташламады, киресенчә, аны яклау, саклау юлына басты. Күп тә үтми, хатыны белән башка шәһәргә күчеп китте. Нәтиҗәсе куанычлы. Гаилә бәхетен тапты. Хәзер алар бер кыз белән бер ул тәрбиялиләр. Иң куанычлысы шул, балаларында әлеге авыруның бернинди билгеләре дә сизелми. Димәк, эпилепсия авыруының нәселдән-нәселгә күчүе зарур түгел дигән сүз бу.

Бу гаиләдә әни кешенең авыруы турында телгә алып сөйләшү гадәте юк. Шуңа күрә сирәк кенә булгалаган авыру чалымнары бәхетле гаиләнең җылы томаны эчендә югалып кала.

Әгәр бу киресенчә булса? Яшь хатынны нинди зур фаҗига көткән булыр иде. Әлбәттә, беркемне дә авыру кеше белән яшәргә мәҗбүр итеп булмый. Монысы инде аңнан, тәрбиядән, мәгънәдән тора.

Дөрестән дә, бу бик четерекле мәсьәлә. Ләкин уйланырга мәйдан киң. Тормышта бик күп гыйбрәтле хәлләргә тап буласың. Менә шулар хакында, хөрмәтле укучылар, без сезне сөйләшергә, фикер алышырга чакырабыз. Ихтимал, Миләүшәгә киңәш бирергә теләүчеләр дә табылыр? Сездән хатлар көтәбез!

Зәлидә ӘКБӘРОВА



Журнал килә – бәйрәм килә

"Сөембикә" журналын ничегрәк күрергә телисез?" — дип язасыз. Мин бу журналны гомерем буе укып киләм һәм аның нәкъ хәзергечә чыгуын теләп калам. Һәр сан шатлык, яңалык, рухи байлык алып килә. Журнал килә — өйгә бәйрәм килә. Арттырып таләп итү дә, сорау да гөнаһ булыр кебек.

"Сөембикә" — затлы журнал. Көнүзәк темага язылган мәкаләләрегез сокландыра. Матур рәсемнәрегез белән безне кызыклы дөньяга алып керәсез. Безне яшәтәсез, яшәртәсез, слатасыз, җырлатасыз...

Шулай да бер тәкъдимем бар. Соңгы вакытта татарлар арасында эчүчелек нык таралды, бу безнең милләт язмышын куркыныч астына куя. Журналда эчү белән бәйле фаҗигалар турында күбрәк язсагыз, отышлы булыр иде.

Сез милләт өчен тырышучы кешеләр. Рәхмәт, "Сөембикә"!

Сөембикә ИХСАНОВА,
Менделеевск шәһәре.

сезнең журнал!

Аш-су, кием-салым, медицина, ир белән хатын мөнәсәбәтләре буенча киңәш-табышлар укучыларыбызның мәнфәгатьләре нигезендә оештырылачак.

"Сөембикә" — иң популяр милли басма. Сез инде аның географиясе белән таныш: Америка, Япония, Австралия, Төркия, Алмания, Финляндия, БДБ илләре... — менә аның таралу юлы.

Сентябрь аеннан 1998 елга "Сөембикә" журналына язылу башланды. Ул Үзәк каталогка кертелде. Аңа Татарстанның, Россия Федерациясенең һәр почта бүлегендә язылырга мөмкин. Чит мәмләкәтләрдә яшәүчеләр моны үз юллары аша башкара алалар.

Редакция, чыгымнарның икеләтә артуына карамастан, журналга язылу бәясен элеккечә калдырды. 6 айга — 32400 сум. Тагын бер күркәм яңалык: "Сөембикә"гә 1 елга да язылырга мөмкин. Бәясе — 64800 сум. Күпләр өчен бу бик уңай булыр дип саныйбыз. Мәшәкате кими. Журналның индексы — 73002.

"Сөембикә" — татар гаиләсе өчен иң зарур басма. Язылыгыз, укыгыз, дусларыгыз-якыннарыгызга да бу хакыйкатьне җиткерегез!

Безнең тышлыкта

Рәисә Габдулла кызы СӘХИЕВА — Президент аппаратының дәүләт-хокук идарәсе җитәкчесе, Президент каршындагы Ярлыкау комиссиясе әгъзасы, Татарстанның атказанган юристы. Президент кул куйган һәр Указ, һәр рәсми документ иң элек Рәисә ханым кулыннан уза дисәк, һич ялгышмабыз. Бу мөлаем һәм нәзакәтле ханымның шушы җаваплы эштә танылуы татар хатын-кызларының акылын һәм булдыклылыгын тагын бер кат дәлилли...
Без аңа берничә сорау белән мөрәҗәгать иттек. Сезгә дә шул әңгәмәне тәкъдим итәбез.



Гаделлек илчесе

Г. ХАФИЗОВ фотосурәте

— Рәисә ханым, Татарстанның Ярлыкау комиссиясе эшчәнлеге хокукый җәмгыять төзүгә бер адым буларак кабул ителә. Аның максатлары нидән гыйбарәт?

— Ярлыкау комиссиясе Татарстан Республикасы Президентының 1994 елның 14 апрель Указы нигезендә оештырылды. Анда 12 кеше эшли, рәисе — юстиция министры А. М. Салабаев. Комиссия әгъзалары арасында без өч хатын-кыз: "Сөембикә" журналының баш мөхәррире Роза ханым Туфитуллова, мәгариф министры урынбасары Вера Боговарова һәм мин. Комиссиянең рәсми документларын эшләү, кирәкле мәгълүматларны туплау эше безнең идарәгә йөкләтелде.

Ярлыкау комиссиясе Татарстан Республикасы Конституциясенең 111 нче статьясы, Россия Федерациясе белән Татарстан Республикасы арасында 1994 елның 15 февралендә кул куелган Килешү — Шартнамә нигезендә төзелде. Элек мондый комиссия бары тик Мәскәүдә, СССР, Россия күләмендә генә иде.

Комиссиянең бурычы — ярлыкау мәсьәләләре буенча материалларны, хөкем ителгән кешеләрнең җинаять эшләрен, аларның гаризаларын карап чыгып, үз тәкъдимнәрен Президентка җиткерү.

— Аңлавымча, сез җинаять кылган һәм суд тарафыннан хөкем ителгән кешеләрнең эшләрен карыйсыз. Андый кешеләрне ярлыкау мөмкинме?

— Ярлыкау — ул Президент тарафыннан хөкем ителгән кешеләргә карата аерым очракларда гына кулланыла торган шәфкатьлелек акты. Президент законнарны, суд карарларын үзгәртмичә, гаепләрен аңлаган һәм төзәлү юлына баскан кайбер шәхесләрнең язмышын бераз җиңеләйтү йөзеннән, үзенең Указы белән аларга билгеләнгән җәзаны үзгәртә. Җәзадан тулысынча азат итә яки срогын кыскарта, яисә җәзадан шартлы рәвештә азат итә. Нәтиҗә чыгарганда һәрнәрсә игътибарга алына: ул кешенең холкы, җинаятьнең җәмгыятькә карата куркынычлык дәрәҗәсе, гаилә хәле, тәртибе, сәламәтлеге, төзәтү-хезмәт учреждениесе җитәкчеләре, күзәтү комиссиясе фикере һәм башка мөһим дәлилләр. Нәкъ халык мәкалендәгечә: җиде кат үлчә, бер кат кис.

— Соңгы елларда җинаятьчеләр арасында хатын-кызлар күбәйде. Әйтегез әле, яшәешне дәвам итү өчен яратылган гүзәл затлар җинаять юлына ничек баса?

— Хатын-кызлар да, ирләр дә җинаятьне күпчелек очракта исерек хәлдә кыла. Бераз гадиләштеребрәк әйтсәк, бөтен явызлык аракыдан дип нәтиҗә ясарга мөмкин. Моннан тыш, еш кына хатын-кыз җилкәсенә төшкән тормыш авырлыгы, гаилә проблемалары, төрле аңлашылмаучылыклар, көнләшү, ир белән хатын арасындагы низаглар җинаятькә сәбәп була. Менә сезгә бер мисал. Ир белән хатын аерылыша, ике бала хатында кала. Ир суд карарында билгеләнгән кайбер әйберләрне хатынына бирми. Шуннан хатыны, әнисен, дусларын ияртеп, иренең эш урынына килә, аның шкафыннан бик күп сәгатьләр алып китә. Ире аны судка бирә, хатынны алты елга ирегеннән мәхрүм итәләр. Ул Президент исеменә үтенеч язып, комиссия аның эшен караганда, срогының яртысыннан артыгын утырган иде инде. Бу очракта әхлакый өстенлек хатын ягында. Бу беренче карашка ук күренеп тора. Шуңа күрә комиссия әгъзалары бертавыштан әлеге хатынны төрмәдән чыгарырга дигән карарга килде.

Аяныч ки, хатын-кызлар арасында кеше гомеренә кул сузучылар да бар. Бу бик әрнеткеч хәл. Бигрәк тә ул яшьләргә кагыла. Мәсәлән, егерме яшьлек бер кыз яңа туган баласын үтергән өчен өч елга ирегеннән мәхрүм ителгән. Ятим үскән бала була ул, туганнарында яши. Бер егетне ярата, балага уза, ә егет өйләнми, ташлап китә. Көмәненнән котылырга тырыша, ләкин вакыт узган була инде. Туганнары орыша. Баланы дус кызының мунчасында таба, дус кызы кирәк-яраклар алырга чыгып киткән арада сабыйның борынын томалап үтерә. Әлбәттә, моны һич аклап булмый. Әмма аның ятим булуын, йорт-җир, эшләгән урыны, булышыр кешесе юклыгын исәпкә алып, суд та аңа өч ел гына бирә. Кыз үзе дә соңыннан үкенә. Эшен без караган вакытта ике елдан артык утырган иде инде. Комиссия әгъзалары бу яшь хатынның алдагы тормышы турында кайгыртып, җәзадан азат итәргә дигән фикергә килделәр. Гаебен аңлар, нормаль тормыш кора алыр дип өметләнәбез. Гомумән,

Президент та, комиссия дә ярлыканган һәр кешегә тормышын дөрес юлдан башларга мөмкинлек бирү, җәмгыятькә файдалы кешеләрне арттыру максатында эшли.

— Рәисә ханым, ярлыкауны үтенүчеләрнең күпмесенә ышаныч күрсәтелә?

— 1996 елда гына да Президент исеменә ярлыкауны сорап, 1412 кеше гариза бирде. 1095 гариза комиссия утырышында каралды һәм 122 кеше Президент Указы белән кичерелде. Шулар арасында 20 хатын-кыз һәм бер балигъ булмаган яшүсмер бар. Каралган эшләр буенча 15 кеше — җәзадан тулысынча, 65 кеше шартлы рәвештә азат ителде. 42 кешенең бирелгән сроклары кыскартылды. Комиссия эшли башлаганнан бирле 224 хөкем ителүчегә карата ярлыкау кулланылды.

— Мәгълүм булганча, 1997 елның 1 январеннан Россиянең яңа Җинаять кодексы гамәлгә керде. Аның нинди үзенчәлекләре бар?

— Моңа кадәр кулланылган Җинаять кодексы 1960 елда кабул ителгән иде. Ә 36 ел дәвамында аңда күп үзгәрешләр булды, бигрәк тә соңгы 10 ел эчендә яңа төр җинаятьләр килеп чыкты. Шуңа күрә кодекс камилләштерелде, инде җәза төрләре дә артты. Мәсәлән, гомерлеккә ирektән, дәүләт бүләкләреннән, класслы чиннардан мәхрүм итү кебек җәза төрләре өстәлде, үлем җәзасы билгеләү очраклары кыскартылды. Алыпсатар, әрәмтамаклык хакындагы статьялар бетерелде. Икътисад өлкәсендәге җинаятьләргә каршы көрәш йөзеннән яңа бүлек өстәлде. Ялган кәсәбәчелек, кредит алганда закон бозучылар, рекламада ялган мәгълүмат бирүчеләр, налог түләүдән баш тартучыларга карата җаваплылык рәсмиләштерелә. Яңа кодекста статьялар саны да артыграк.

— Россия Европа Советына керде. Европа Советына керүнең бер шарты — үлем җәзасы бирүдән баш тарту. Бу турыда фикерегез ничек?

— Хәзерге вакытта Россиянең закон чыгару органнары да, Президент та шушы мәсьәләне хәл итү белән мәшгуль. Әлбәттә, үлем җәзасы бирүне кинәт кенә бетереп кую мөмкин түгел. Шуңа күрә бу эш этаплы рәвештә алып барылачак дип фараз ителә.

— Рәисә ханым, әңгәмә барышында мин Сезнең һәр нәрсәдән хәбәрдар булуыгызга, һәр законны яттан белеп, һәр нечкәлеген аңлата белүегезгә сокланып утырдым. Юрист белгечлегендәге кырыс закон кысалары хатын-кызның йомшак күңеленә тәэсир итәме?

— Минемчә, безнең эштә иң мөһиме — ир-ат яки хатын-кыз булу түгел, ә сәләт, белем һәм тәҗрибә.

— Шулай да, хатын-кыз булуыгыз эшегездә ярдәм итәме, комачаулыйммы?

— Ярдәм итә дип уйлыйм. Чөнки хатын-кызда тоемлау сәләте көчлерәк. Ир-атлар мәсьәләне гомумән күзаллыйлар.

— Ярлыкау комиссиясе Сезнең эшчәнлекнең бер өлеше генә. Президент аппаратында хокук идарәсе җитәкчесе вазифасы да зур тырышлык таләп итәдер.

— Конституция буенча, Президент аппараты Президентка үз вазифаларын үтәргә ярдәм итү өчен булдырыла. Без ул кушкан юнәлешләр буенча мәгълүмат туплыйбыз, материаллар эшләп бирәбез. Президентның һәр эше юридик яктан нигезләнгән булырга тиеш.

— Рәисә ханым, Сез ни өчен юрист белгечлеген сайладыгыз?

— Мин авылда үстем. Кечкенәдән үк гаделсезлекне сөймәдем. Үзегез беләсез, гаделсезлекләр авылда да җитәрлек. Законнарны өйрәнеп, кешеләргә ярдәм итәсем килә иде. Ул заманда авыл мәктәбен тәмамлап килүчегә юридик факультетка керү шактый четерекле хәл, шуңа күрә мин Әгерҗе районының Девятерня сигезьеллык мәктәбен тәмамлагач, Арча педагогия училищесына кердем.

— Әти-әниегез Әлфия апа белән Габдулла абый Шәрифуллиннарның тирә-юньдә данлыклы укытучылар булуы да тәэсир итми калмагандыр?

— Әлбәттә. Алар тәрбияләгән күркәм сыйфатлар миңа бүгенгәчә ярдәм итә. Училищены тәмамлагач, Зәй районында өч ел укыттым. Шул ук вакытта, Казан педагогия институтында читтән торып укыдым. Тик юрист булу теләге шулкадәр көчле иде, тәвәккәлләп, университетның юридик факультетына имтиханнар тапшырдым. Эш стажы булу да ярдәм итте. Университетны тәмамлагач, ТАССР Югары Советы Президиумына инструктор итеп эшкә билгеләделәр. Чөнки анда рус телен дә, татар телен дә яхшы белүче кирәк иде. Ул вакытта тәрҗемәчеләр юк иде әле, юридик кәгазьләрне үзем язып, үзем тәрҗемә итеп ике телдә әзерли идем.

— Эшегезнең гаилә тормышына йогынтысы бармы?

— Минемчә, өй белән эшне бервакытта да бутарга ярамый. Гаилә — ул синең шәхси биләмәң. Аннан соң, гаилә проблемалары бер хатын-кыз өстендә генә булмаска тиеш. Иптәшем дә, улым да моны бик яхшы аңлыйлар, булышалар. Тату яшибез. Улым Айрат фигуралы шуу белән мавыкты, хәзер спорт мастерына кандидат. Әмма юрист булырга хыяллана.

— Димәк, юристлар династиясе башлана?

— Чынлап та, шулай икән. Сеңлем Ләрисә Әлмәттә прокурор урынбасары булып эшли. Тормыш иптәшем дә белеме буенча юрист.

— Рәисә ханым, мин Сезне концертларда, кичәләрдә еш очратам...

— Әйе, мин сәнгатьне яратам, аңа һәрвакыт вакыт табарга тырышам. "Лебединое озеро" балетын ун тапкыр карадым бугай. Яраткан җырчыларым Зилә Сөнгатуллина, Илһам Шакиров, Әлфия Авзалованы да еш тыңлыйм, Татарстан җыр һәм бию ансамбле чыгышларын... Шуберт, Чайковский әсәрләре ошый. Әле күптән түгел Парижда булырга туры килде. Анда атаклы Рудольф Нуриев биегән бинада, мәшһүр "Гранд-Опера"да "Сильфида" балетын карарга насыйп булды. Минемчә, сәнгать — ул һәркем өчен бетмәс-төкәнмәс илһам чишмәсе.

— Тормышта Сезнең өчен иң җитмәгәне нәрсә?

— Иң элек — вакыт, калганнарына түзәргә була.

Әңгәмәдәш — Нурсөя ШӘЙДУЛЛИНА.

1998 елда "Татарстан балалары" дигән комплекслы дәүләт Программасы гамәлгә кертеләчәк

Бала - гаиләнеке!



Бала кемнеке: гаиләнекеме, дәүләтнекеме? Бу турыдагы озакка сузылган бәхәсләргә, ниһаять, нокта куелды. Бала — гаиләнеке! Аның сәламәтлеге, физик һәм акыл үсешенә дә бары тик гаилә тәрбиясе аша гына ирешергә мөмкин, дигән уртак бер фикергә киленде шикелле. Татарстан Дәүләт Советының унберенче пленар сессиясендә "Татарстан балалары" дип аталган комплекслы дәүләт Программасын гамәлгә кертүне күздә тоткан бик әһәмиятле карар кабул ителүе менә шуны күрсәтте. Димәк, җәмгыятьтә гаиләгә, балаларга карашның кискен төстә үзгәрүе көтелә. Ләкин бөтен яктан какшаган, сәламәтлеген җуйган бүгенге гаиләләрнең бала тәрбияләү кебек күп чыгым һәм көч сорый торган авыр йөкне тартып барырга хәленнән килерме? Һәм бу нинди юллар аша тормышка ашырылачак? Журналист Әлфия СӘГЪДИЕВА әлеге сораулар белән дәүләт Программасын әзерләүдә катнашучы буларак, Татарстан халык депутаты, парламентның "Җәмгыяви мәсьәләләр һәм яшьләр эшләре" комиссиясе әгъзасы Сүрия Әсхәт кызы УСМАНОВАга мөрәҗәгать иткән иде. Түбәндә сез аның җавабы белән таныша аласыз.

— Әйе, бүгенге хәлендә гаилә заман таләп иткән дәрәҗәдәге бала тәрбияләп үстерә алмый. Димәк, моның өчен аңа мөмкинлекләр тудырырга кирәк. Базар мөнәсәбәтләренә күчү бу мәсьәләгә бөтенләй яңача карауны таләп итә. Дәүләт Программасы менә шуны күздә тотып эшләнә дә.

Капиталистик юнәлеш алып, төрле илләр белән үзенең икътисади-сәяси-мәдәни мөнәсәбәтләрен көйләргә керешкән Татарстан Республикасының дөньякүләм танылуы, бу өлкәдә уңышка ирешүе бары тик акыллы, белемле, сәләтле, сәламәт карашлы шәхесләре аша гына мөмкин икәнен бүген инде һәркайсыбыз яхшы аңлый. Ә андый шәхесне дәүләт түгел, бары тик гаилә, ата-ана гына тәрбияли ала. Алдынгы илләр моны инде күптән белеп эш итә. Аларда бала, ата-ана, гаилә хокуклары сагында торучы күпләгән канун, программаларның эшләп килүе шуны күрсәтә. Димәк, безгә дә алар тәҗрибәсеннән файдаланырга бик вакыт.

Яңа Программа, кабул ителеп тә, гамәлгә ашмаган әүвәлгеләреннән кай ягы белән аерыла соң?

Беренчедән, Программада бала яралганчыдан алып 18 яшькә җиткәнчегә кадәрле чорда мөһим саналган бик күп яңа мәсьәләләргә игътибар бирелә. Аларның иң мөһимнәре буенча аерым программалар төзелә. Икенчедән, ул 1998 елдан дәүләт бюджетына кертеләчәк. Һәрхәлдә, өмет бар.

Игътибарга лаеклы мәсьәлә дигәннән, мисал өчен, "Сәләтле балалар"га кагылышлысына тукталып китик әле. Күпме бездә сәләтле балалар? Аларны тәрбияләү өчен ниләр таләп ителә? Безнең беркайчан да бу турыда баш ватканыбыз булмады ләбаса! Авыл баласын гына алыйк, күпмесе аның бүгенге тормышта үз-үзен күрсәтә ала? Бармы аның сәләтен үстерә алу мөмкинлеге? Юк. Репетиторлар яллау, өстәмә дәресләргә, түгәрәкләргә йөрүдән мәхрүм ул. Шул сәбәпле, югары уку йортларына керү мөмкинлеге дә бик чикле. Кергән хәлдә дә җитмеш мең сум стипендиягә яши алмый. Ә ярдәм итү ата-ананың хәленнән килми. Туган теленең әле һаман дәүләт теле буларак гамәлгә кермәве нәтиҗәсендә татар баласы икеләтә кыенлык кичерергә мәҗбүр. Бу мәсьәлә дә җентекләп өйрәнелә.

Сер түгел, без бүген ятимнәр иленә әйләнеп калдык бугай. Бездәгедәй балалар йортлары беркайда да юк. Иң аянычы шул, 95 процентының ата-анасы исән. Әлбәттә, хөкүмәт ятимнәрне үз канаты астына алырга мәҗбүр. Бер яктан караганда, бу бик мактаулы, кешелекле сыйфат булып тора. Әмма нәтиҗәсе аяныч. Балалар йортларыннан ятимнәр тормышка яраксыз булып чыгалар. Ни җүнле һөнәре, яшәр урыны, кыен чакта сыенып кешесе, терәгегаиләсе булмаган яшүсмерләргә нишләргә кала? Аларның 20 проценты үз-үзенә кул сала, кайберләре җинаять юлына баса, үзләренә битараф өлкәннәргә, җәмгыятькә нәфрәт хисе белән яши.

Булганмы бездә элек балалар йортлары? Ятимнәр? Юк. Чөнки өлкәннәр баланы беркайчан да гаилә җылысыннан аерырга ярамаганлыгын аңлап эш иткән. Әти-әнисез калган сабыйны тәрбиягә туганнары, күршеләре яисә авылдашлары алган. Ятимне читкә җибәрү үзенә күрә милләт, нәсел дәрәҗәсен төшерү кебек үк түбәнлек саналган. Ә бүген ничек?

Соңгы өч ел эчендә Татарстаннан 14 баланы Америкага уллыкка алдылар. Моңа игътибар итүче, каршы килүче булмады да. Американың үзендә тәрбиягә алырлык балалар юкмы икәнни? Бар, билгеле. Безнең үз балаларыбызга карата ни дәрәҗәдә кадерсез мөнәсәбәттә торуыбызны күреп йөрәкләре әрнегәндер ул америкалыларның, мөгаен. Чөнки Америка кешесе ятимне багуны әхлак эше — Ходай каршында да, бәндә алдында да үзенең кешелек бурычын үтәү итеп кабул итә. Ә бездә үз балаларыннан баш тартучы ата-аналар саны көннән-көн ишәя бара. Моңа матди кыенлыклар гына сәбәп булып бетә алмый, билгеле. Бүген бер ятим баланы балалар йортында ел буе асрау өчен 10 миллион сум акча китә. Ул акчаны гаиләләргә бүлеп биргән очракта файдалырак булмас идеме?

Инде Программаның "Гарип, авыру балалар" һәм "Балалы гаиләләрне социаль яклау" дигән өлешләренә дә игътибар итеп китик. Гарип балалы аналарга ике юнәлештә ярдәм итү күздә тотыла. Беренчесе: алдан ук гарип баланы тудырмау чарасын күрү; икенчесе: туган очракта, ул балага белем биреп, һөнәргә өйрәтеп, тормышта үз урынын табарга булышу. Бу Программа Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан тулысынча әзерләнде инде. Финанслауны гына көтеп тора.

"Социаль яклау" сүзен ишеткәч, кайберәүләрнең балалы һәр гаиләгә күп итеп льготалар билгеләнәчәк икән дип аңлавы ихтимал. Бу алай түгел. Киләчәктә хөкүмәт гарип, авыру кешеләрне кайгыртуны гына үз өстенә алачак. Сәламәт кешегә төп ярдәме — яхшы эш урыны, хезмәт хакы белән тәэмин итүдән торачак. Димәк, яхшы яшисең, балаңа әйбәт белем, тәрбия бирәсең килә икән — тырышып эшлә, сәламәтлегеңне кайгыртырга өйрән! Әгәр гаилә теге яки бу мәсьәләдә кыенлык кичерә икән, юридик, психологик һәм медицина буенча махсус үзәкләр һәрчак аларга ярдәм итәргә әзер торачак.

Бүген барыбызны да иң зур борчуга салганы — туклану мәсьәләседер, мөгаен. Галимнәр кеше сәламәтлегенә кагылышлы тикшеренүләр үткәреп, шундый ачыш ясаганнар: кеше сәламәтлегенең 55-60 проценты аның тормыш рәвешенә, 15-20 проценты экологик, генетик һәм башка сәбәпләргә, ә калган 10-15 проценты табибларга бәйле икән. Ә тормыш рәвешендә туклану мәсьәләсенә аеруча зур әһәмият бирелә. Нәрсә ашыйсың, ничек ашыйсың, ни эчәсең — берсе дә сәламәтлегеңдә эзсез калмый. Бигрәк тә балаларга кагылганы куркыныч тудыра. Бала сәламәт үссен өчен аңа экологик чиста ризык таләп ителә. Бүгенге көндә эшләп килүче сөт кухнялары ихтыяҗның нибары 40-50 процентын гына тәэмин итә ала. Ә авыл баласы моннан бөтенләй мәхрүм. Туклану индустриясен җайга салу бик чыгымлы, кыен эш. Моның өчен экологик чиста кырлар булдырырга, сыерга чиста азык кына ашатырга кирәк. Хәзергә мондый мөмкинлекләр юк әле. Әмма инде нәрсә эшләргә тиешлегебез ачыкланды, бу юнәлештә дә Программа төзелде.

Бала һәм ана, гаилә мәсьәләләрен дәүләт дәрәҗәсендә хәл итүгә беренчеләрдән булып алынып, Татарстан Республикасы үзенең алга карап эш итәргә сәләтле икәнлеген тагын бер кат раслады. Инде хәерле сәгатьтә дияргә генә кала. Ә Татарстан Дәүләт Советы эшнең ничек барышын даими төстә күзәтеп торачак.

Укытучы Гайния

1946 елның август ахыры. Мәләкәс педагогия училищесы ишегалды гөр килә, җәйге каникулдан соң укучылар җыелган. Бер читтә яңа кабул ителүчеләр баскан. Бу минем булачак курсташларым. Кечкенә, ябык кына кызлар һәм егетләр. Киемнәр чуар. Әби-бабайлардан калып, сандыкларда күз карасы кебек кадерләп сакланган истәлек киемнәрдән үзгәртелеп тегелгәннәре дә бар. Чиккән сөлгеләр дә кофта итеп киелгән. Аягына чабата кигән бәрхет күлмәкле кызны күргәнегез бармы сезнең? Минем бар. Арада бер кечкенә буйлы кызчык аерылып тора. Ул минем булачак дустым Шаһидуллина Гайния. Ул Башкортостаннан килгән. Әтисенең бертуган абыйсы Мәләкәстә яши икән. Урысча бик әйбәт сөйләшә, диктант, иншаларны дә "бишле"гә генә яза. Гомумән, барлык фәннәрдән дә яхшы укый. Кечкенә дә, төш кенә, дип шаярта идек үзен. Аның өчен иң авыр нәрсә скрипка, ноталар иде. Ике ел буе үзләштерә алмыйча интекте. Музыка укытучыбыз Петр Иванович Иванов аның теңкәсенә тия иде. Класста 20 скрипка уйный, шулар арасыннан Гайниянең ялгыш уйнаганын ишетеп ала иде. Аның мәшһүр скрипкачы булуын, сугыш өермәсе аны безнең якларга китереп ташлавын ул чакта кем белгән? Зур концерт залларында алкышларга, чәчәкләргә күмелеп яшисе урынга, безнең кебек наданнар белән җәфа чигә иде. Училищеда концертлар вакытында укытучыбыз сәхнәгә чыга һәм скрипкасын сыздырып җибәрә. Сокланып тыңлый идек.

Гайния кышкы озын төннәрдә абзасы белән чит кешеләргә утын кисеп, утын ярып йөри, ә иртән укытучының һәр соравына төпле җавап бирә. Училищены тәмамлаганнан соң туган ягы Нурман районы Яңа Субай авылына кайтып китте, югары классларда урыс теле укытучысы булып эшли башлады. Кияүгә чыкты, ике бала тапты. Әмма язмыш дигәнең син уйлаганча гына булмый шул. Ирдән аерылып, ике бала тотып калды. Югары уку йортына да керде. Ике баласын да кеше итте.

Авылның тырыш механизаторы Галиев Фатихның хатыны үлеп китә. Өч баласы ятим кала. Гайния шул балаларга ана булды. Ул аларны да үз балалары кебек яратты. Үсеп җиттеләр, өйләнештеләр. Төп йорттан берсе дә бизмәде. Бергәләшеп, чөкердәшеп яшиләр.

Хәзер Гайния лаеклы ялда. 40 еллык хезмәт үзе генә дә мактауга лаек. Кем ул хәзер? Менә дигән биш баланың кадерле әнисе, иренең сөекле хатыны, авыл халкы арасында дәрәҗәле укытучы. Йөрәгендәге миһербанлылык, тырыш хезмәт менә шундый биеклеккә күтәрде аны.

Сания АЛИЕВА, Ульяновск өлкәсе, Яңа Тимерчән авылы.

Зыялылар кавеменнән

Бу 1959 елның сентябре иде. Мин эшләгән "Совет мәктәбе" (хәзер — "Мәгариф") журналы редакциясенең ишеген йомшак кына шакып, бер хатын-кыз килеп керде. Сәлам бирде, исемен әйтте. Университет аспиранты Гөлчәчәк Әдһәмова икән. "Мәкалә китергән идем, кемгә тапшырсам, дөрес булыр?" — диде. Язма әдәбият укыту мәсьәләсенә кагылышлы булып чыкты. Танышлык менә шулай башланды. Без инде берничә дистә еллар аралашып яшибез. Моның өчен язмышыма рәхмәтлемен, чөнки әйбәт кешенең әйбәтлеге йога, диләр бит.

Гөлчәчәк 1927 елның 31 августында Татарстанның Аксубай районы, Яңа Ибрай авылында укытучылар гаиләсендә дөньяга килә. Әтисе —Мирзаһит Әдһәмов, Мәскәү университетын тәмамлагач, авыл мәктәпләрендә рус теле һәм әдәбиятын укыта. Чистай кантонының мәгариф бүлегенә җитәкчелек итә. Кантоннар бетерелгәч, Яңа Ибрай мәктәбенә директор итеп билгеләнә. Әмма бик иртә, нибары 31 яшендә, үпкә авыруыннан вафат була. Шулай итеп, 5 яшьлек Гөлчәчәк әтисез кала. Әнисе — башлангыч сыйныфлар укытучысы Ләбибә ханым — кызына ятимлек хәсрәтләрен күрсәтмәскә тырыша. Кыз үзе дә төшеп калганнардан түгел. Урта белеме булмаган килеш, хәтта башлангыч сыйныфта укытып та ала. Болар — сугыш вакыты — 1943—1945 еллар. Гөлчәчәк ханымның яшьтән педагогика өлкәсенә тартылуы, күрәсез, буш җирлектә тумый.

Аның тамырларында зыялылар каны ага. 1995 елда басылып чыккан "Татар халкының тарихы һәм мәдәни һәйкәлләре" дигән китапның 219 битендә Мотыйгулла



Гөлчәчәк ӘДҺӘМОВА.

Халык педагогикасы

Яшүсмердә милли үзаң формалаштыру һәм шуның аша туган телен, халкын ихтирам итүче шәхес тәрбияләүне халык педагогикасыннан башка күз алдына китерүе кыен.

Шул уңай белән үзебезнең гаиләгә тукталмакчы булам. Мин мәктәпкә кергәнче үк укый-яза белә идем, мин аны өйдә әнидән өйрәндем. Ул татар халык җырларын, әкият, бәет, табышмак, мәкаль-әйтемнәрне күп белә иде. Үзе сөйләргә оста, әкият сөйләгәндә сихри, тылсымлы дөньяга алып кереп китә, аны тыңламый мөмкин түгел иде. Аның фольклор әсәрләрен, Тукайның "Халык моңнары"н яттан белүенә соклана идем. Гаиләбездә балага 4—5 яшь тулдымы — ул Тукайның "Халык моңнары"ннан такмакларны өйрәтә башлый иде. 6 яшемдә инде мин Тукайның "Бала белән күбәләк", "Бәхетле бала", "Туган тел", "Сабыйга", "Халык моңнары"н яттан сөйли идем.

Мәктәптә укый башлагач, әдәби телнең халыкчан, саф татарча үрнәген мин әтидән өйрәндем. Әтинең татар милли әдәби телен пропагандалауга, әдәби телнең нигез ташларын халыкка җиткерүдә куйган хезмәтләре бәяләп бетергесез. Ул, мәктәптә татар теле һәм әдәбияты укытучысы буларак, әдәбият түгәрәге белән үзе җитәкчелек итә иде. Бу түгәрәкләрдә күбрәк укучыны иҗади эшкә тартырга тырыша, мәктәп һәм авыл тормышыннан вакытлы матбугатка мәкаләләр язарга өйрәтә иде. Ул вакытта Мәскәүдә чыга торган "Октябрь баласы" журналында минем дә берничә мәкаләм басылган иде.

Әтинең ата-аналар, укучылар катнашында әкиятләр кичәсе үткәрүе хәтердә. Бу кичәдә ата-аналар да, укучылар да актив катнашты, сөйләүчеләргә төрле бүләкләр бирелде, мин дә икенче дәрәҗәдәге бүләк — бер кулмәклек ситса белән бүләкләнгән идем. Болар барысы да туган телгә мәхәббәт тәрбияләү максатыннан үткәрелгәннәрдер, мөгаен. Әниемнең тәрбия педагогикасын

Әдһәмовның (димәк, сүз Гөлчәчәкнең бабасы турында бара) 1883 елда Яңа Ибрай авылы мәчетенә имам итеп куелуы турында әйтелә. Ләбибә апаның әтисе Мөхәммәтзакир Юнысов та үзягында мулла, мөдәррислек вазифаларын үти.

Гөлчәчәк 1951 елда Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты факультетын тәмамлый. Аспирантурада укырга тәкъдим итсәләр дә, кыз үзен эштә сынап карарга уйлый. Мүлмә урта мәктәбендә (Татарстанның Биектау районы) укыта, завуч булып эшли. Мәгариф министрлыгында да, партиянең район комитетында да эшләп ала. Аны югары партия мәктәбенә укырга җибәрмәкче булалар. Ләкин Гөлчәчәк туташ башка юл сайлый: 1958 елда Казан дәүләт университеты каршындагы аспирантурага укырга керә. "Галимҗан Ибраһимов иҗатында хатын-кыз азатлыгы мәсьәләсе" дигән темага диссертация яклый.

1963 елда Казанда РСФСР милли мәктәпләр институтының Татарстан филиалы ачылгач, Гөлчәчәк Әдһәмованы шунда эшкә чакыралар. Ул анда бертоташтан 24 ел буена фәнни-тикшеренү эшләре алып бара. Һәм 1987 елда лаеклы ялга чыга.

Коммунистлар партиясенең сәясәте нигезендә, башка милли төбәкләрдәге кебек, Татарстанда да "ата-аналар соравы буенча", милли балалар бакчалары, мәктәпләр ябылып бетте диярлек. Эш кәгазьләре, җыелышлар урыс телендә генә алып барылды.

Гөлчәчәк һәм аның хезмәттәшләре шушы шартларда да телебезне саклап калырга тырыштылар. Күптән түгел берәү матбугат битләрендә: "Министр Мирза Мәхмүтов татар мәктәпләрен бетерде", — дип һичбер дәлилсез чыгыш ясады. Хәлләр җинел түгел иде, "милләтче" мөһере сугылганнарга эштән, партиядән куылу куркынычы яный иде ул чакта. Күрше — мари, мордва, удмурт, чуваш башлангыч мәктәпләрендә ана теле предмет буларак кына өйрәнелде. Аннан соң алар тулысынча рус мәктәпләре программалары белән эшләүгә күчтеләр. Ә татар авылларында милли мәктәпләр сакланды. Шәһәр мәктәпләренең кайберләрендә дә татар балалары ана телен өйрәнәләр иде. Бу эштә министрлыкка милли мәктәпләр филиалы фәнни хезмәткәрләре, укытучылар белемен күтәрү институты методистлары ярдәм иттеләр. Дәреслекләр, программалар, уку әсбаплары, күрсәтмә материаллар, методик эшкәртмәләр әзерләделәр. Мәсәлән, Гөлчәчәк Әдһәмова йөзгә якын фәнни мәкалә язды, дәреслекләр, хрестоматияләр, методик әсбаплар төзеде. Менә шуларның кайберләре: "Урта мәктәпнең 8-10 классларында татар әдәбиятын укыту методикасы", "Яшь буынны тәрбияләүдә әдәбиятның тоткан урыны", "Милли мәктәпләрдә җирле халыклар әдәбиятын өйрәнү".

...Бу хәлгә шактый вакыт узган икән. Әмма мин аны һаман искә алам. Ютазы районының бер мәктәбендә татар әдәбияты дәресендә утырам. Темасы: "Мәҗит Гафуриның "Кара йөзләр" әсәрендәге төп идея". Язучы әсәрендә революциягә кадәрге татар авылында "мәхәббәт мәсьәләсенең ничек чишелүен" тасвирлый. "Сыйнфый күзлектән караганда" татарның элекке тормышын тетеп ташларга мөмкинлек бар, югыйсә. Әмма шунысын онытмыйк, безнең халыкта "кызлар сафлыгы" дигән нәрсә, традиция буларак, буыннан-буынга күчеп килгән. Ләкин укытучы ялгыш юлдан китте. Укучылар, повестьне өйрәнү урынына, бер карчыкның магнитофон язмасына алынган 30 минутлык бик тә күңелсез "әңгәмәсен" тыңладылар. Әлеге "белгеч" фикеренчә, элек егетләр белән кызларның аулак урында очрашуы тыелган икән. Дәрескә анализ ясаганда, мин укытучыдан: "Сез Гөлчәчәк Әдһәмованың методика китапларын укыганыгыз бармы?" — дип сорадым. Ул башын гына иде.

Татарлар күпләп яши торган төбәкләрдә милли мәктәпләр эшли иде. Андагы укытучылар методик ярдәмгә аеруча мохтаҗ иде. Шуларны истә тотып, Гөлчәчәк Әдһәмова Красноярск краенда, Пермь, Саратов, Самара, Чиләбе, Төмән, Оренбург өлкәләрендә, Идел буе, Урал республикаларында булды, укытучылар белән семинарлар уздырды. Һәм бүген дә бу изге хезмәтен дәвам итә.

Гөлчәчәк Әдһәмова кебек ханымнар, күптән пенсиягә чыгып, оныкларын карыйлар, бакча үстерәләр. Ә Гөлчәчәк андый түгел. Менә ничәнче ел инде ул Казанның Беренче югары педагогия училищесы каршындагы педагогик көллияттә "Татар әдәбияты тарихы"н укыта.

Гөлчәчәк Әдһәмова — Россиянең һәм Татарстанның атказанган укытучысы. "Үкенечкә калмасын" дигән әдәби повесть авторы.

Була шундый шәхесләр, үзләре дә, күңелләре дә картаймый. Зыялылар кавеменнән булган Гөлчәчәк Мирзаһит кызы да әнә шундый зат. Без аңа иҗат уңышлары, сәламәтлек, иксез-чиксез ак юллар телибез!

Мәхмүт ӘХМӘТҖАНОВ.

Газинур ХАФИЗОВ фотосурәте.

күңелемдә яңартып, мин шул нәрсәгә төшендем: ул укуга омтылыш тәрбияләүдәме, хезмәткә аңлы караш булдырудамы — барысын да уйлап, безнең нәрсәгә сәләтле булуыбызны аңлап эш иткән, табигый сәләтебезне, мөмкинлекләребезне ачыклый алган. Барыбызның һәрьяклап үсеше өчен мавыктыргыч дөнья булдырырга, иҗади сәләтебезне үстерергә тырышкан. Гаиләдәге кечкенә балаларның психологиясен истә тотып, ул алар белән төрле уеннар: "Кем тизрәк", "Уйлап тап", качышлы уеннары оештыра иде.

Болар барысы да сөйләм телен үстерергә, тирә-юнь белән танышырга, баланың уй-теләген белергә, алар арасында үзара дуслык тәрбияләүгә ярдәм иткәннәр. Кече яшьтән үк әнинең халык иҗаты әсәрләрен өйрәтүе, әтинең әдәбиятка, милли мәдәниятебезгә мәхәббәт тәрбияләве эзсез калмаган.


Хәзерге көндә энем — тарих фәннәре кандидаты Изил Гарифуллин — авылларыбыз, үткән тарихыбыз, ата-бабаларыбыз тарафыннан калдырылган газиз мирасыбызны торгызуда зур эшчәнлек күрсәтә. Халкыбыз тормышында татар милли мәктәпләребезнең роле, халык хуҗалыгының төрле тармакларында, мәгариф өлкәсендә күп көч куйган мәгърифәтче якташларыбызның тормышын, аларның язмышын ачыклауда бик күп эшли. Икенче энем — Фатыйх Гарифуллин — Төмән университетының тарих-филология факультетын тәмамлап, дин-әхлак мәсьәләләрен халыкка кайтара. Аның бөтен килеш-килбәте, үз-үзен тотышы, һәр әйткән сүзе яхшылык, иман белән тулы.

Балага аң-белем, тәрбия бирүнең иң мөһим буыны, әлбәттә, мәктәп. Яшь буынны үз ана телендә укытуга ихтыяҗның төп сәбәбе шунда: тел мәдәниятнең төп өлешен тәшкил итә, кеше нинди телдә белем алса, шул ил һәм халык вәкиле булып формалаша. Әле хәзер дә татар теленә кимсетеп карау күренеше халкыбызның үз арасында да яшәп килә. Телебезнең матурлыгында ата-аналарыбызның бөек рухын, күңел хәзинәсенең киңлеген, фикерләү дәрәҗәсенең бөеклеген аңлата алган, моны иң әүвәл үз аң-акылына сеңдерә алган һәм шул фикер белән коралланган укытучы гына балаларны туган теленең бай алтын хәзинәсенә төшендерә ала.

Люция ХӘБИБУЛЛИНА, Төмән.

Күздән күзгә күчкән нур

Рәшит абый Зәкиевне бер-ике генә сүз белән тасвирларга кушсалар, мин аны "серле шәхес" дип атар идем. Зирәк кеше буларак та, "Чаян" журналының баш мөхәррире буларак та, тормышның күпләр күрә белмәгән фәлсәфи, көлкеле якларын эләктереп ала да, эченнән генә елмаеп йөри кебек ул миңа. Әлеге эчке елмаю, нур булып, аның җитди карашына кушыла. Шушы нур, исәнләшеп кенә үткәндә дә, сиңа күчеп кала. Һәм, ирексездән, күңел халәтеңне тигезлисең, бу ыгы-зыгылы дөньяда төшенеп җитә алмастай ниндидер бер тотрыклылык барына ышанып куясың... Күп еллар инде без Рәшит әфәнде белән бер сукмакны таптыйбыз. Көн саен очрашабыз, хәл-әхвәл белешәбез. Чөнки "Чаян" редакциясе дә, "Сөембикә" дә Татарстан газета-журнал нәшриятының тугызынчы катында урнашкан. Болай караганда, бер-беребезне шактый беләбез кебек иде. Баксаң... Хәер, кеше күңелен күккә тиңлиләр бит. Шагыйребез әйтмешли, "Күктә ни булмас дисең — очсыз-кырыйсыз күк бит ул!" Ут күршебез Рәшит Карип улы ЗӘКИЕВ тә шундый "очсыз-кырыйсыз", рухи яктан искиткеч бай шәхес булып чыкты. Әңгәмәбездән сез аны үзегез дә аңларсыз.







Г. ХАФИЗОВ фотосурәтләре

"Әниләр кырыс була. Минем әни дә кырыс иде. Әниләр йомшак була. Минем әни дә йомшак иде. Күзе зәңгәрсу-яшькелт иде. Чулпысы чәч толымында картайганчы йөрде. Сандыктан алсу күлмәген алып кияр иде, чәчләрен тарап үрер иде. Күршеләргә ашка, туганнарга кунакка барыр иде.

Әни эшләгән эш, әни сөйләгән сүз безнең җанда, канда, гадәттә..."

Рәшит ЗӘКИЕВ.

— **Рәшит Карипович, Сезне яшьтән үк гел "Ю" витамины, ягъни юмор витаминын нык ашаган кеше дип сөйлиләр. Хакмы бу? Андый витамин нинди ризыкларда күбрәк соң? Әллә Азнакай районының Тымытык авылында гына очрыймы ул?**

— Сөйләүләре хакка туры килгән шикелле. Ул витаминны мин, авыл малайлары белән бергәләп, Ык суы ташуыннан

калган камыш утрауларыннан казып таба идем. Өскә чыгып калган камыш тамырын тартып аласың да, кабыгын әрчеп, ашап җибәрәсең. Иллә дә тәмле була торган иде ул бананга охшаган камыш тамыры! Шуны корсак тутырып ашагач, малайлар белән гел кеткелдәшеп кенә сөйләшә башлый идек. "Ю" витамины яңа өлгергән арыш башагында да бар. Башакларны уып, учлап арыш ашасаң, бер кайгы да калмый — көлке үзеннән-үзе атылып чыга. Әлеге витамин чөгендер яфрагында, ат кузгалагында, балтырганда, кукыда да бик мул иде. Без бәләкәй чакта шушы үләннәрне капчык-капчык ашадык. Аллага шөкер, ул витаминның көче озакка җитте кебек. Чаянчы һөнәренә дә ярап куйды дисәм, ялгышмамдыр сыман.

— Ул камыш тамыры, һичшиксез, туган туфракка, туган авылга, нәсел-ыруга, әти-әнигә барып тоташадыр. Юморга һәвәслек нәселдән килә, диләр...

— Безнең әти яшьли вафат булды һәм тормыш йөге әни җилкәсенә күчте. Горур, көчле, сабыр, тыйнак иде ул. Табигате белән җор иде, сөйләме әйтемнәр, зирәк гыйбарәләр белән тулы. Һәр күренешкә бер җор сүзе, мәзәге, мәкале әзер иде. Аның шушындый сүз хәзинәсе минем кырык еллык журналистлык эшчәнлегемә дә җитте. Мин әле һаман да әни җөмләләре белән язам кебек. Исеме дә үзенчәлекле иде — Мәбрүрә. Авылда аны "Мәбер" дип йөртәләр иде. Без дә "Мәбер малайлары" дип телгә кердек. Әмма да безнең урамда Мәбер сүзе нык сүз иде. Әни — колхозда аш пешерүче, абруйлы, исемле кеше. Аңа бәйле матур хатирәләр хәзергәчә күңел түрендә саклана. Аларны искә алу әнием каберенә чәчәк салуга тиң булсын иде...

Сугыш еллары... Урак өстендә басу түрендәге учак тирәсендә, әни янында мин дә кайнашам. Авыр хезмәттән талчыккан, ярым ач уракчы хатын-кызлар, яшерел кенә арыш уалар да: "Мәбрүрә, кеше-кара күргәнче куырып кына бирсәнче", — дип, әнигә сүз кушалар. Әни арышны тиз генә казан төбенә сибә. Персидәтел-фәлән күренсә, аны ялт кына сыпырып төшерә дә, яулыкка төреп миңа тоттә. Мин, яланаяклы малай, җылы тәргәкне күкрәгемә кысып, арыш арасына сыптырам. Кача-кача теге түтиләргә илтеп бирәм. Әни һәр баласының үз төсмерен тоеп, һәрберебезне тигез ярата иде. Аның алдында мин мәзәк чыгара торган бераз бунтарь һәм бераз булдыксызрак сиземләнгән малай булганмын, күрәсең. Ул минем нинди шуклык эшләп, кайда качып ятуыма кадәр исәпләп чыгара ала иде. Мәсәлән, җыелышны саламга китәбез. Тейибез дә, басу түреннән җырлап кайтабыз. Әни чыгып тыңлап тора: әһә, Мәбер малайлары кайта. Кинәт җыр өзелә. Әни исә шундук төшенә, димәк, йөк ишелгән, чөнки өстә Рәшит утырган булган. Бу хәл гел кабатланып, гаилә тарихына кереп калды хәтта.

— Мәбрүрә апаның җорлыгы малайларына да күчеп калган, димәк?

— Аеруча олы абыебыз Фәриттә көчле иде җорлык. Ул өйдә стена газетасы чыгара, һәрберебезгә чәнечкеле шигырьләр яза, хәтта әтинең үзенә дә эләгә иде тәнкыйть угы. Менә кем буласы иде "Чаян" редакторы! Ләкин ул Бөек Ватан сугышында һәлак булды. Без, энеләре, аның пенсиясенә укып, югары белем алдык, дисәм дә ялгышмам. Һәммәбезнең икешәр-өчәр дипломы бар.

— Шул авыр елларда, ятим килеш гыйлем юлыннан китүегез дә әниегез тырышлыгыдыр?

— Әйе, бу яктан да мин әнигә һәм беренче укытучым, искиткеч кеше Хатирә апа Фазлыевага бурычлы. Аннан соң, борынгы Тымытык мәдрәсәсе традицияләрен дәвам иткән мәктәбебез дә көчле иде. Бервакыт элеккеге мәдрәсә бинасында уйнап йөргәндә мәдрәсә ташы төшеп башымны тишкән иде. Хәзер уйлап йөрим: "Энем, кайсы тамырдан үскәнеңне онытма", — дигән кисәтү булгандыр ул, дим. Гомумән, без нәсел тамырларына тугрылыклы булдык. Әнинең "Мин яшәгән чактагы кебек яшәгез" дигән васыятен тоттык.

Әмма шунысын әйтәсем килә: гаилә һәм тормыш мөнәсәбәтләрендә интеллект, зирәклек, акыл ягыннан әнинең биеклегенә һәм бөеклегенә җитеп булмый икән...

* * *

"Мин — суга сусаган юлчымын,
Җырларга ярсынган җырчымын.
Үтәлсәң юлларның ташлысын,
Эчәсең суларның татлысын.
Җырласаң җырларның хаклысын,
Халыкның ак эшен яклыйсың.
Суларга сусаган юлчымын,
Җырларга ярсыган җырчымын".

Рәшит ЗӘКИЕВ.

— Рәшит Карипович, Сезнең шигырьләр җыентыгын укыгач, гүзәл Ык буйларында шагыйрь булып тууыгызга тагын бер кат инандым. Ә язмыш юллары Сезне бераз читкәрәк алып киткән, ахры. Тәрҗемәи хәлегезгә күз салсак: Казан дәүләт университеты студенты, Дөбъязның "Колхозчы" газете, Норлатның "Дуслык" газете хезмәткәре, "Социалистик Татарстан"ның махсус хәбәрчесе, Ленинград югары партия мәктәбенең журналистика бүлеге студенты, Татарстан партия өлкә комитетының пропаганда һәм агитация бүлеге инструкторы. Һәм... 1975 елдан бирле "Чаян" журналының алыштыргысыз баш редакторы. Өстәвенә, Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре... Шигырьләр язу шулай тукталып калдымы?

— Шигырьләр хәзергә күңелдә яшәп килә, кайчак "Чаян" битләренә чыгалар-чыгуын... "Чаян" өчен, журналны тиешле югарылыкта тоту өчен җәмәгать эшләреннән дә, башкаларыннан да баш тарттым дию дөресрәк булыр. Үземә язарга вакыт җитми. Мөхәррирлек хезмәтен колачлап бетерү мөмкин түгел. Мин, мәсәлән, каттый режимда эшлим, алай да көч-колач җитми. Һәм шунысы бар: әлеге күзгә күренми торган редакторлык эше матди яктан һич тә җаваплылыгына тәңгәл бәяләнми дип уйлыйм. Халык әйтмешли, өе биек, өйрәсе сыек. Журналның һәр санына күпме көч куелганын, күпме күз нуры түгелгәнен, бәлки, бездән соң, яшьләр аңлар, бәяләр дип өметләнәм.

— "Чаян" мөхәррире кәнәфие бик җайсыз урын. Юморны, тәнкыйтьне кем аңлый, кем юк, дигәндәй. Четерекле хәлләр дә шактый очрагандыр?

— Хикмәт ул четерекле хәлләрдән чыгу юлларын таба белүдәдер, дип саныйм. Ягъни, әйләнеп тә узма, турыдан да бәрмә, акыллы һәм бераз хәйләкәррәк, зирәгрәк сукмакны шәйләргә өйрән — баш мөхәрриргә шулайрак килешә шикелле. Дөрес, кайбер фельетоннарны чыгару өчен көрәшеп, сырхауханәләргә эләккән дә булгалады. Әмма гаделлек хакына анысына да түзәсең.

— Соңгы вакытта "Чаян" тоткан мәйдан киңәйгәннән-киңәя бара. Журнал укучылар моны тоймый калмагандыр. Америкада штаттан тыш хәбәрчегез бар икән. "Чаян" битләреннән Билл Клинтон, Хельмут Коль елмая. "Елмаю - 96" конкурсында Америка кызы Һайди үзенең фоторәсемен юллаган. Казахстан Президенты Нурсолтан Назарбаев исеменнән пресс-үзәк җитәкчесе хат җибәргән. Хәтта Якутиядә яшәүче аз санлы юкагир халкының аксакалы да "Чаян"га рәхмәтен белдерә.

— Бусын инде журналны дөньяның һәр ноктасына барып җитеп көлдерә алырлык итеп чыгара белүче чаянчыларның уртак хезмәте дип әйтер идем. Табигатебез шундый: мөгез чыгарырга яратабыз.

— Рәшит Карипович, мин белә башлаганнан бирле дә, аннан элекке фоторәсемнәрдә дә Сез гел мыеклы. Мыекка тугрылыкның да сере бармы әллә?

— Әлбәттә. Әнидән тугыз малай таптырган әтиебез очлары бөтерелеп торган менә мо-ондый мыеклы иде. Ә малайлары мыек үстерми. Минем мыек әтигә охшарга тырышудандыр, мөгаен. Мыек йөртүнең үз нечкәлекләре бар икән, үстерә-үстерә анысына да төшендем. Бервакыт Сочида казах егетләре белән бергә ял итәргә туры килде. Болар көн саен 10 чакрым йөгерәләр. Мин әйтәм, туктале, татарлар уздырырга тиеш. Һәм араны 15 кә җиткердем. Карыйм, бер казах мыек җибәрде. Мәйтәм, татар мыегы шәбрәк булачак! Үсә мыек, куе, матур — уздырдым моны. Ул вакытта өлкә комитетында эшлим бит, ә анда таләпләр кырыс: галстук, костюм киярга, мыек булмасын. Сочидан кайткач, бераз шүрли-шүрли җитәкчем Николай Демидов янына кердем. Ни әйтер? Озак кына текәлеп карап торды да:

"Безнең мыек шәбрәк, афәрин!" — диде. Баксаң, ул минем мыекны күрше бүлек мөдиренекеннән күркәмрәк дип тапкан икән. Шулай итеп, мыекка обком үзе "фатиха" бирде.

— Һәм Сез мыек астыннан елмаеп йөрүче "Чаян" образына бик туры киләсез...

— Ипигә май яккан кебек, һөнәр дә иясенә йогынты ясый, әлбәттә. "Чаян"ның эләктереп, чирттереп, төрттереп алу гадәтенә ишарәлисендер. Хәер, болар минем үземдә дә юк түгел. Еш кына миңа: "Нишләп Сез үтә житди?" — дигән сорау бирәләр. Чынлап та, авыз гел ерык түгел болай. Шаркылдап йөрүдән "Чаян"га файда килми бит. Биредә үз-үзеңне тиешенчә тота белү мәсьәләсе бар. "Чаян"ның күренекле авторлары Мирсәй Әмир, Салих Баттал кебек шәхесләр дәрәжәсенә чыгарга кирәк. Бу уңайдан мин үземнең остазларымны искә алып үтәр идем. Кулымнан житәкләп журналистлык юлына чыгарган укытучым Хатыйп ага Госман, Шәмси Хамматов, өлкә комитетында күп тормыш сабаклары биргән затлы шәхес Мөхәммәт Мозаффаров. "Чаян"ның баш мөхәррире, хәтта рәссамы булып та эшләгән, редколлегия әгъзасы күренекле язучы — Мирсәй Әмир. Мине "Чаян" дөньясына алып керүче, редактор итеп тәрбияләүче ул иде. Мирсәй Әмир кебек бөек акыл иясе белән аралашуыма сөенеп туя алмыйм.

— Журналистның журналисттан интервью алуы шактый сирәк күренеш. Форсаттан файдаланып, журналистның бүгенге җәмгыятьтәге урыны турында фикерегезне беләсе иде.

— Бүген без үз һөнәребезне зурлау гамәленә тотынырга тиеш. Журналистка түбәнсетеп карау, хезмәт күрсәтүче ролендә куллану ешаеп бара. Без түбән кешеләр түгел, без — горур. Үз дәрәҗәбезне үзебез югары тотарга тиешләр дип беләм. Иҗтимагый фикер һәрвакыт журналист каләме очында. Иң биек вә бөек кешеләрнең фикерен дөньяга чыгару безнең каләмдә һәм кулда. Кеше дигән каты чикләвек журналист каләме белән ярыла, ачып бирелә. Бу зур мәгънәгә ия. Без моны расларга һәм берберебезгә таяныч булырга тиеш.

— "Чаян" һәм "Сөембикә" журналлары кебек дисәм, каршы килмәссез кебек. Безнең редакцияләр инде ничә ел "аркага арка куеп" дус һәм иптәш булып гомер кичерәләр...

— Күрше хакы — Тәңре хакы дип юкка гына әйтмиләр. Безнең күршелек — очраклы хәл түгел дип уйлыйм. Күп тапкырлар сыналган, кадерләп сакланган күршелек ул. Шуңа күрәдер, һәр иртә эшкә килгәндә үземне туган йортыма кайткандай хис итәм. "Сөембикә"дәге кебек ышанычлы күршеләрең булу үзе бер бәхет.

* * *

"Сөйкемле сөяк — оныгымның сөт тешләре төшеп, елтыр үскән ак тешләре белән елмаеп торуы миңа елның иң истәлекле вакыйгасы булды. Шушы вакыйга башка барлык ыбыр-чыбырларны күмеп китә, кайгы-борчуларны оныттыра.

Ышанмасагыз, үзегез онык үстереп карагыз, аның белән бергә-бергә сайрашып карагыз — шунда гына төшенерсез минем халәтемне..."

Рәшит ЗӘКИЕВ.

— Рәшит Карипович, яшерен-батырын түгел — Сезгә быел 60 яшь тула. Гадәттә, түгәрәк даталарда кеше бераз тын алып, нәтиҗәләр ясый, бәйрәм үткәрә...

— Минемчә, юбилей — ул мәҗбүриятькә этәрүче күренеш. Әйдә, үткәрик дип аптырата башлыйлар. Мин бит юбилейлар үткәрерлек бай кеше түгел, дип җаваплыйм. Чынлап та, гомер буе эшләп тә баеп булмады. Баесам, дача түбәсен калай белән ябармын дигән сүзем бар иде. Үз гомеремдә велосипед та ала алмаганмын икән. Хөкүмәттән ике әйбер оттым, анысы. Берсе: саклык кассасына акча сала алмаган идем — янмадым. Икенчесе: буш шешәләрне озак тапшырмаган идем — бәяләре артты. Хәер, мин җыеп өлгергәнче бәя кабат төште һәм аларны бик рәхәтләнеп сукбайларга бүләк иттем. Яшермичә, тагаен әйтәм: мин — туры Рәшит һәм ярлы Рәшит. Абый-энеләр дә көлешеп куялар. Әлеге дә баягы, әни сүзе: салам йөге ауса — Рәшит, димәк, нәселдә кемнең машинасы юк, ул да — Рәшит.

— Әгәр бердән бер көнне: "Әти, син безгә ни калдырасың", — дип сорасалар?

— Мин малдан кыйммәтрәк чын хакыйкатьләргә табынып яшәгән кеше. Күңелгә сиздермичә генә әни салган мөселман фәлсәфәсеннән киләдер, минем яхшы исемем бөтен нәрсәдән өстен дигән фикердәмен. Пычранмаган, буялмаган исем. Мин һәркемнең күзенә туры карый алам икән, бу — зур нәрсә. Балаларга да әйтәм: "Сезгә минем яхшы исемем кала", — дим.

— Гадәттә, Сезнең кебек эшлекле ир-атларның гаиләгә игътибары җитенкерәми. Ә Сез, киресенчә, гаилә җанлы, йомшак күңелле. Моның сәбәбе нидә?

— Бусы да әти-әнидән киләдер. Гаиләмне, кызларымны, оныгымны артык яратам бугай. Кесәмдә гомер буе сумка йөрттем, берәр нәрсә алып кайтып, аларны гел сөендереп яшим. Кыз балаларның күңеле йомшак, фәрештә җанлылар бит алар. Кырыс ир-ат күңелен нечкәртеп җибәрәләр. Гомумән, гаиләмнән канәгатьмен. Хатыным Сания — врач, абруйлы белгеч, эшендә дә ихтирам итәләр. Ике иңдәге ике фәрештәм — кызларым Миләүшә һәм Карлыгач инде үсеп җиттеләр. Карлыгач — юрист, Миләүшә "Казан" милли-мәдәни үзәгендә эшли. Аның кызы Лена — сөекле оныгым — өченче фәрештәм.

— Оныгыгыз "дәү әти, дәү әни", дип өзелеп тора. Сезнең күзләрдән дә оныгыгызга мәхәббәт сирпелүен күрмичә мөмкин түгел. Әллә барыннан да нык ратасыз инде?

— Үз балаларыңны үстергәндә, берничәгә бүленеп чабасың да чабасың, фәлсәфәсен уйларга вакыт юк. Ә менә онык тугач, бала фәлсәфәсе кирә башлый икән. Нәсел дәвамы хакында уйлыйсың. Ул әйтеп бетереп булмый торган гаҗәеп хис, ул ташып тора. Оныгыма мин вакыт кызганмыйм, кайчак урамга чыгып 2-3 сәгать йөрибез, сөйләшәбез, серләшәбез. Гүя дөнья юкка чыгып тора, чөнки үз дөньябыз түгәрәк ул чакта, башка бер нәрсә кирәк түгел. Мәхәббәт әнә шулай башка төсле әйләнеп кайта. Бусы инде чын мәхәббәт, ялган була алмый. Анда бәхилләшү төсмере дә бар дип уйлыйм. Ходай биргән соңгы мәхәббәттер ул...

— Рәшит Карипович, ут күршегез "Сөембикә" журналы исеменнән туган көнегез белән котлыйбыз. Тагын оныклар туып, күңелегездә мәхәббәт артуын, шул мәхәббәтнең "Чаян" битләренә дә өлгәшүен, яңа иҗади биеклекләргә илһамландыруын телибез. Әңгәмәгез өчен зур рәхмәт.

...Рәшит абый Зәкиев яшәгән урам ямьле дә, чиста да, агачларның чал ябалдашлары астында тын гына уйга чумып утырган шикелле. Аның кайбер урыннарын төзекләндерүдә "Чаян"ның да катнашы бар, диләр. Һәрхәлдә, безгә очраган һәр кеше иң баш чаянчыга хөрмәт белән сәлам бирде. Хәтта мышык борынлы бер кечкенә малай да, Рәшит абый: "Менә журналның тагын бер герое", — диюгә, "Юк, "Чаян"да ул мин түгел", — дип күздән югалырга ашыкты.

Һәр иртә урамның горур тынлыгын бозучыларның берсе — Рәшит Карипович үзе. Ул урам буйлап йөгереп килә, мәктәп ишегалдындагы спорт корылмаларында яшь егетләр булдыра алмастай гимнастик күнегүләр ясый. Үзем күрдем! Хәзер кайвакыт иртән уйлап та куям: "Рәшит абый инде йөгерергә чыккандыр"...

Бу серне әле чаянчылар үзләре дә белмидер...

Нурсөя ШӘЙДУЛЛИНА.



Г. ХАФИЗОВ фотосурәте

Асия
ЮНЫСОВА

Нинә тапкыр таңнар кабынса да,
Берензсе аның кадерле...
Чишмә башы итеп саныйк әле,
Саныйк тәуге, ихлас шигырьне.

Йолдызлы күк ганылган ул гишмә
Безгә серен айты түгелме?
И Асия!
Мәңгелек бит дәшә,
Яшә, диеп, дәшә күңелне!

И Асия! Шигырь кәнизәге,
Җиһанның бер сәер җимеше...
Гәр язганың булсын — соңгы сыман!
Гәр язганың — хиснең тәүгесе!

ЗӨЛФӘТ

Көлүемне сагынырсың

Йөрүзәнгә тирән кермә

Йөрүзәнгә тирән кермә, диден,
Эчтә кечле, диден, агымы.
Көмеш өзәнгеле йөрәгемнең
Агымнардан куркыр чагымы.

Кермим диме, сине, ай-көмешем,
Йөрүзәнгә килеп мин таптым.
Тирән суда түгел, күзләреңнең
Зәңгәренә кереп мин баттым.

Хәзер инде гел сагынып яшим
Чәчләреңнең көмеш дулкынын.
Йөрәгемдә очкын итеп йөртәм
Күзләреңнең серле ялкынын.

Кайгылардан мине араладың,
Караларны йотты зәңгәрлек,
Якыннардан якын кешем минем,
Кайда йөргән идең син элек?

Дога

Күреп калып, бүтән иңендә
Иреннәрем тигән бу куллы,
Мин елладым шунда беравык.
И ходаем, сакла син аны!

Мине ташлап китеп баруы,
Әйләндереп бөтен дөньямны.
Ә юлларда шундый бозлавык.
И ходаем, сакла син аны!

Төннәр айсыз, көннәр болытлы,
Тозлы яшьләр юа күз явын.
Бу яшьләрем аңа төшмәсен.
И ходаем, сакла син аны!

Төшләремә керә һаман да.
Өсләренә киеп караны.
Бу төшләрем җилгә сибелсен.
И ходаем, сакла син аны!

Алдану

Канатланып баруларым
Яралар алыр өчен.
Кояшлы туган кәнемнең
Шәмнәрсез кала киче.

Алтын бөртекләр чәчсәм дә,
Такыр калды басуым,
Күзләреңдә кем икәнен
Карар өчен баруым.

Бәхетеңне үзем белгәч,
Минем шаһитлык нигә?
Ятим сукмагым кайтара
Ялгыз яшәгән өйгә.

Син мине бүтән чакырма,
Алгысытма һичьюгы.
Боз булып йөрәккә төште
Алданулар суыгы.

Шалтыратмыйм

Түзим әле. Бүтән шалтыратмыйм.
Ул яратмый мине, яратмый.
Җылы сүзе белән җанны сыйпап,
Кайгыларым минем таратмый.

Түзим әле. Бүтән шалтыратмыйм
Бер югалтып мине карасын.
Тыны белән ялгап карасын ул
Шәһәр белән шәһәр арасын.

* * *

Китәм, китәм. Җан көйдереп
Йөрмәм бүтән.
Югалырмын. Өй тутырып
Көлмәм бүтән.

Түрегезнең чите китек,
Син сөймәгәч.
Үземә дә бик күңелсез,
Шуны белгәч.

Җиңел түгел эчтән елап,
Калу көләч.
Көлүемне сагынырсың,
Ерак киткәч.

Бу хакыйкать мәңгелектән:
Сөю – көрәш!
Күрмәдеңме? Еладым бит!
Күземдә яшь.

Китәм

Җиңдем, диден.
Ике учак иде ике күзең.

Берни түгел!
Яшьләремне генә йотыйм да
Мин кабаттан булам сабыр, түзем.

Белсәң иде:
Кемнәр табышын кемнәр югалтыр,
Җиңелсәм ни!
Ярлар ерак, юлым озын бит,
Юл юатыр әле, юатыр.

Дәрьяларны
Япа-ялгыз, ялгыз кичәсем бар,
Мин җырлармын,
Ялгызлыкны шулай җиңәрмен,
Ахыргача озатып барыр җыр.

Менә китәм.
Ятим көймәм инде ярдан этәм.
Син кал әйдә,
Югалырмын ипле, җайлы гына,
Мин борчымам килеп сине бүтән.

Инде менә
Сыңар ишкәк белән кузгалдым да.
Җиңгән идең.
Ике учак иде ике күзең,
Зәңгәр сагыш булып боз калды.

Көмеш тәңкә

(Җыр)

Челтер-челтер чишмәгезгә
Тәңкәләр салып китәм.
Сагынырмын, кәтәм диган
Вәгъдәләр алып китәм.

Кушымта: Көмеш тәңкә бөтерелә
Дулкында уйнар өчен.
Көлә-көлә китеп барам
Соңыннан елар өчен,
Көмеш тәңкә – өметемне
Көн дә төн уйлар өчен.

Күңелемнең ярсу чагы
Ошаган агым суга.
Киләм әле, тагын киләм
Чишмәле авылыгызга.

Агым суда көмеш тәңкә
Уйнаклап йөзәр микән,
Җан яраткан ярым мине
Уйламый түзәр микән?

Мәгърифә

Ничек яшисең, авыл?



Мәгърифә Хөрмәтова

Кызы Венера ул көнне дә, гадәтенчә, иртә уянды. Өч бармагын тырпайткан да кетер-кетер сөйләнә:

— Миңа бүген өс тула бит, иеме, әнием! Әтием туган көнеңә өс тәгәрмәсле сәпид апкайтам, диде бит... Иеме, әнием...

Сабыеның бәхетле көне әтисенең матәм көне булыр дип кем уйлаган: "Әтиең инде беркайчан да сине кулларына күтәреп түшәмгә кадәр чөймәс, беркайчан берни бүләк тә итә алмас. Син аны башка күрә алмассың", — дип газиз нарасыеңның күңелен ничек китәсең?!

Мәгърифә гүя таш сын булып каткан, сөйләшә дә, уйлый да, хәтта елый да алмый. Гомер буе эштән бушамаган каенанасы Мәхмүзәттәй дә ике кулына бер эш таба алмый интегә: әле карты Лотфулла янына барып карый, әле килененең нечкә-нәфис сынына кытыршы, бирчәйгән куллары белән йомшак кына кагылмакчы була, юату сүзләре таба алмый тилмерә. Кем белә бит, бәлки, аңа — анага кирәгрәктер ягымлы, өметле сүз?! Бу мизгелдә дөньясының асты-өскә килгән бәхетсез сәгатьтә тәкъдиргә үпкәләргәме? Мәгърифә тик эчтән сыкрана, бәргәләнә, яна...

Әйе, тимер айгырын иярләп кичтән җир сөрергә чыгып киткән Гыйльмулланы инде юату, ялварулар белән кайтара алмыйсың. Егерме алты яшьлек имәндәй таза ир бусаганы бүтән атлап кермәс. Акыллы, эшчән, тырыш егетнең төсе булып нәни кыз гына үсәр.

...Мәгърифә ерактан — Сарман ягыннан төшкән килен иде. Алабуга китапханә техникумын тәмамлагач, ар-удмурд авыллары арасына адашып утырган Яңавылга аны мәгърифәт учагы кабызырга дип җибәрделәр. Күмер яккан паровоз төтененнән түбәләре кап-кара булып ысланган Әгерҗенең үзен дә, йөк машинасы әрҗәсендә кайта-кайта күзләрне күгәрткән, сөзәк таулар ышыгына посып, чокырда утырган бәләкәй-җыйнак Яңавылны да беркайчан якын, үз итәлмәс кебек тоелган иде. Сабакташы, ахирәте, клуб мөдире булып эшләячәк дусты Мөнҗиягә дә әйтте:

— Мәҗбүри ике елымны ничек уздырырмын, бигрәк ерак бу як...

— Берәр баһадир егеткә гашыйк булсаң, бу ерак як иң сөйкемле, иң матур җиргә әйләнер әле, — дип көлде дусты.

— Белмим. Йөрәк ятар микән? Тауларына кадәр тәбәнәк бит. Егетләре бәйләнчек...

— Тыйнаклары, әйе, әлегә читтә йөри, сынауларыдыр, бәлки...

Мөнҗия хак әйткән: берсе биюче, икенчесе оста җырчы кызларны сынап-күзәтеп торганнар авылда. Насыйп яр да ерак йөрмәгән: авылның уңган тракторчысы Гыйльмулла. Карап торышка тыйнак, басынкы күренсә дә, таянычлы ир булырдай ир-егет иде. Яңавылда яңа клуб әле салынып кына ята икән, китапханә дә шул бинада булачак, имеш. Ә хәзергә... Яшьләр гомер бакый аулагөйләрдә күңел ачкан, өмәләрдә егет сөйгән, басуда, кырда танышкан.

Махсус белемле Мөнҗия белән Мәгърифә исә авылга мәгърифәт нуры балкытырга тиеш иде. Авыл зур түгел, алай да егет-җилән, кыз-кыркын байтак. Җырга-биюгә осталар да бар икән. Дөрес юнәлеш биргәндә, күңелләрендә ут кабызганда, нидер майтарып булачак төсле. Кино сирәк килә, театр-концертлар булмый, дип кул кушырып утырмаска гына кирәк.

Өмә арты өмә ясап, ниһаять, клубны күтәрделәр, озакламый утларын балкытыр. Әлегә үзешчәннәрне барлый торырга, спектакльләр әзерли башларга кирәк. Татар халкы сәнгатькяр бит. Ул театр карарга, җырлар тыңларга ярата. Монда да шулай — кичәләр булганда халык залга гына сыеп бетә алмый. Мондый тамашачы булганда юлсызлык та, сусызлык та — бар да онытыла икән. Шул рәвешле авыл сәхнәсенә "Галиябану", "Асылъяр"лар менде. Үзешчән сәнгать бәйгеләрендә Мәгърифә куйган биюләр бүләк арты бүләк яулады. Укучылар конференцияләре гөрләп уза, яңа сулыш белән авыл мәдәниятка, мәгърифәткә тартыла. Ул монда вакытлыча дип килгәнен онытты. Ипле, гаҗәеп тату, әйбәт гаиләдә үскән Гыйльмулла белән чәчләре чәчкә бәйләнгәнен сизми дә калды. Тик бәхет кояшы гына тиз сүнде. Кыска гомерле булды бәхете. Авылның абруйлы, хөрмәтле Хөрмәтовлар килене булуына куанып туя алмаган иде, югыйсә. Олпат гәүдәле, аз сүзле, бетмәс-төкәнмәс эш-мәшәкатьләреннән тәм таба белүче тырыш каенатасын — Лотфулла агайны Мәгърифә үз гомерендә күреп, туйганчы сөйләшә алмаган әткәсенә охшаткан иде. Ә каенанасы — тәмле телле, сабыр, итагатьле, йомшак табигатьле Мәхмүзәттәйдән ул үз әнкәсеннән күрмәгән кадер-хөрмәт, наз-ярату тойды. Ә үзенең әнкәсе, Шәмсебәдәр апаның язмышын сугыш тәгәрмәче тетелкәләп-таптап узды, алты бала белән яшь-яшь килеш тол калган хатын иртә картайды, тузды, таушалды. Котдус останы — сугышның беренче көннәреннән фронтка киткән әткәсен, шул яман ут йотты, сагынганда карарга уч төбе тиклем фоторәсеме дә калмады, ичмасам.

Әйе, бәхетен шушы авылда таптым дип ышанган иде ул. Язмыш башкача тәгаенләгән икән. Кемгә сыеныр ул хәзер?! Бәгырь кисәге — кызы да үксез, ятим үсәр микәнни?!

— Сабыр бул, балакаем, — дип юатырга тырыша аны Мәхмүзәттәй. Аптырап тәрәзәгә текәлә. - Ичмасам Нуруллам да кайтып җитә алмады.

Нурулла ул чак еракларда — алман иленда солдат хезмәтендә иде, абыйсын җирләргә кайтып өлгермәде, атна-ун көннән соң гына туган туфракка аяк басты. Ятим калган кызчыкны күкрәгенә кысты: "Ай, безнең Венера! Үскән дә соң!"

Ни хикмәттер, көйсезләнүдән бушамаган нарасый абыйсының күкрәгенә йомшак бөдрәләрен



яшереп тынып калды. Әтисенә охшатты бугай төз буй-сынлы абыйсын. Бер кан бит!

Китапханәнең эш сәгате бетүгә, өйгә ашыккан Мәгърифә артыннан солдат егет тә иярә торган булды. "Син яшь-җилкенчәк белән күңелеңне ач, кал, иртә бит әле", — дип карады аңа җиңгәсе, егет башын гына селки: "Юк, мине Венера көтә!" Ә бала, чыннан да, абыйсын күрүгә, күбәләктәй очынып аның кочагына ташлана.

— Мәгърифә апаны бездән чыгарып җибәрә күрмәгез. Мине көтегез! — дип китте Нурулла хезмәтенә.

Мәгърифә шул елны Алабуга педагогия институтына укырга керде. Күченеп үк китмәкче иде, колхоз рәисе Рифкать Гыйльметдинов үгетләде: "Кая барсаң да бер кояш, сине монда чын күңелдән яраталар, — диде. — Без дә сиңа ияләштек. Эшеңне ратасың. Бу үзе зур бәхет. Без әле сине авыл Советына кодаларга ниятләп торабыз..."

Әйтергә генә җиңел, хатын-кыз җитәкче урынга утырса, мең төрле чишелмәс мәсьәлә баш калкыта. Гаиләңә дә, эшкә дә, бөтен авыл халкына да игътибарны каян җиткермәк кирәк? Әмма ният иткән гамәлләрең, уйларың изгелектә булса, барысына да өлгерергә мөмкин икән. Мәгърифә дә бетмәс-төкәнмәс мәшәкатьләргә чумды.

Авыл Советы рәисе — авылның акылы да, хакиме дә, казые да, яклаучысы, киңәшчесе дә. Табаксавыт шылтыраса да, җәнҗал купса да, килене булсын, каенанасы — йөгереп кемгә килә?! Мәгърифәгә. Кемнең гаепле, кайсысының хаклы икәнен әүвәл үзең аңла, аннан гозерлегә аңлатып кара. Әгәр үзең шул авылда, авылның күз алдында каенана йортында яшәсәң?! Кыен хәл. Бәхетенә Мәхмүзәттәй киленен беркайчан кыек сүз, ямьсез караш белән рәнҗетмәде, хәер, килен үзе дә гомер бакый аны үз анасыннан артык күреп, кадерен белеп яшәде. Нурулла солдат хезмәтен тутырып кайткач, Мәгърифә аңа кияүгә чыкты. Аңарчы хатлар белән аңлаштылар...

Бу хәлләрдән соң инде утыз елга якын вакыт узып киткән. Шул чорда колхозда алты рәис алмашынган. Җиденчесе — шушы якта үскән Ильяс Кәрәмиев — Мәгърифә апасы бу авылга килгәч туган егет. Колхоз үзе дә таралырга өлгерде, дөресрәге, "Нур" ассоциациясе итеп үзгәртелде. Мәгърифә исә әүвәлгечә... Халык аны ратып, үз итеп "Безнең Мәгърифә" дип йөртә. Җирле үзидарә Советы рәисе дип исеме үзгәртелсә дә, эшенең асылы да, җисеме дә һаман элеккечә: зират коймаларын яңарту да, чишмәләрне карап тәрбияләп-чистартып тору да, авыл урамнарының чисталыгын тәэмин итү... Авылның уртасында яңа мәчет балкып утыра. Тик Гыйбадәт йортын өлгертү белән генә түгел шул, мулласы да, намаз укый белә торган динле кешеләре дә кирәк. Әлегә өзелгән буыннар җебен ялгау кыенрак.

Җәйрәп яткан тирән сулары да, шаулап утырган урманнары да юк бу авылның, әмма барыбер Яңавыл гаҗәеп матур. Урамнар киң, төз. Халкы тырыш, булдыклы. Йортлар берсеннән-берсе чибәр: карнизлары челтәрле, тәрәзә йөзлекләре бизәкле, каралты-кура нык, таза. Урам якта шомырт, алмагач, чия язын ак күбектәй ак чәчкәгә күмелә, ян-якта карлыганы, җиләге пешә, баланы кызара. Кара көзгәчә кып-кызыл тәлгәшле миләшләр уттай янып-кызарып утыра. Дөрес, яшьләр авылда төпләнеп калуга караганда, шәһәрне артыграк күрә, әмма барыбер һәр нәсел, төп йортны сакларга тырыша, урамнар ишәя, арта.

Гомер елгасы җай гына, талгын гына ага да ага. Иртәдән кичкәчә халык кырда, басуда, фермада, бер карасаң, бар да элеккечә, тик яңалык та юк түгел: бөтен Рәсәйдәге сыман халык вакытында хезмәт хакын алалмый, әмма ач түгел, үзенең җиләк-җимеше, яшелчәсе, бәрәңгесе... Яшь киленнәр бәби таба. Мәгърифә — ЗАГС мөдире дә, сабыйларга исем куша, яшь парларга өлфәт мәхәббәт теләп фатиха бирә, язылышу турында таныклык тапшыра, үлем-җитем булса да, янавыллар аңа йөгереп килә. Аларның йорты да нәкъ авыл уртасында. Ул тормышның кыл уртасында кайный: бозау караучы авырып китсә дә, кемнедер хастаханәгә озатырга туры килсә дә, олысы-кечесе, яше-карты аңа килеп ярдәм сорый. Һәркемне ачык йөз, якты чырай белән каршы ала, гозерлене беркайчан кире бормый.

Ире Нурулла да шундый кеше, ярдәмчел, риясыз, миһербанлы зат.

Ул озак еллар инде машинада, илле чакрым ераклыктагы Әгерҗегә сөт ташый. Кар яуса да, яшен, күк күкрәсә дә, бозлавык-тайгалак булса да — юлда. Әгерҗе ягының иң авырткан җире — юлсызлык. Олы юлдан читтә утырган Яңавылга исә бу афәт икеләтә йөк сала, ни барып, ни кайтып булмый. Әле ярый, мәңгелек буш такси — сөт машинасы бар. Нурулла абый яшәсен! Сине үзенә авырлык килсә дә, чатта ялгызыңны бастырып калдырмас. Каян шул кадәр ышаныч?! Дөньяда, бәлки, риясыз, һәр кешегә — яхшымы ул яманмы, дусмы, түгелме — ярдәм кулы сузарга әзер кешеләр бардыр, әмма Нурулла абый кебеге сирәктер. Университетта укый башлаган заманнардан бирле мин шәхсән үзем шул бушлай "такси"дан файдаланам. Буш дидем, чөнки берәүнең дә хезмәте өчен Нурулла абзыйга акча тәкъдим итәргә башына килми. Хәер, бервакыт әнкәй таслап салган берлекләрне актара башлаган идем, кулын гына селекте: "Ерак җый акчаңны! Якын алырсың!" Ул шундый кеше — күңеле, җаны гел изгелектә.

Инде Мәхмүзәттәй дә, Лотфулла агай да сиксәннең өстенә чыккач, тау башындагы мәңгелек йортка күчеп ятканнар, эшкә карусыз, риясыз, тырыш кече уллары Рәшит тә бик яшьләй җир куенына кереп ятты. Дәвам булып Нурулла абый белән Мәгърифә ханымның Рамиле, кызлары Венера ул-кызлар үстерәләр. Венера Казан авыл хуҗалыгы институтында экономика факультеты тәмамлады да, Ижевск телевизион үзәгендә баш бухгалтер булып эшли.

Ә Мәгърифә ханым ялгыз калган караучысыз карт-карчыкларның мәнфәгатьләрен кайгыртамы, авылны яшәту һәм яшәртү артыннан чабамы Рифкать абый сүзләрен искә төшерә: "Эшеңнән тәм-ләззәт таба белү үзе зур бәхет ул".

Роза МУЛЛАНУРОВА.



Илдар ЮЗИ

Мин каен булалмадым...

Парчалар

Әнкәй мине авыр тудырган. Мине якты дөньяга китергәннән соң хәле җиңеләймәгән, гомерлеккә өзлегеп калган.

Әнкәй аккаеннар ярата иде. Безнең өйнең тәрәзә алдында аккаен үскән. Мин аны хәтерләмим, сабый чагымда күрә алмый калдым.

Әнкәй табигатенең бер сыйфаты күчкәндерме, мин дә гомерем буе каеннарга гашыйк! Һәрбер поэмамда диярлек каеннар, туган ягым каеннары...

Каләмдәшләрем дә, үзем дә каеннарны гүзәл кызга тиңлибез, "каен сеңелләр" дип дәшәбез.

Хәзер инде мин аккаенны әнкәйгә тиңлим.

Шулай бер көнне әткәй мине - ике яшьлек сабыйны күтәреп, тәрәзә янында басып тора икән. Тышта көчле яңгыр ява, күк күкри, яшен яшьни, каеныбыз, давылланган чәчләрен-яфракларын тузгытып, җиргә кадәр иелә, нидер әйтергә тели кебек... Урында яткан әнкәй, эчтән генә белгән догаларын укый-укый:

- Яшен яшьни, кит тәрәзә яныннан! - ди.

Әткәй тыңламый. Курыкма, янәсе, безгә тими ул!

Сүзен әйтеп бетерергә дә өлгерми, - коточкыч шартлау өйне тетрәтә. Әткәй идәнгә барып төшә. Урында яткан әнкәй мине көчсез куллары белән эләктереп ала. Башта мине яшен суккан дип куркалар, бераз вакыт узгач, мин кычкырып елап җибәрәм...

Һушларына килеп, тәрәзәгә карасалар: өй алдындагы каенны яшен суккан. Аккаеныбыз, яшеннең үтергеч көчен үзенә юнәлтеп, мине коткарган. Әнкәй дә, аккаен сыман, тормышның бөтен авырлыгын үзенә алып, авырып, мине саклап калган.

Хәзер мин әнкәйне аккаенга тиңлим.

Мин генә каен булалмадым. Әнкәйне авырулардан, үлемнән саклап кала алмадым.

Февраль, 1996.

"Сәлам белән шагыйрь улыгыз"...

1959 елның 27 нче сентябрендә Шәүкәт Галиев белән Кайбыч районының Бакырчы авылында - аның туган җирендә әдәби кичә үткәрдек. Кичәгә яше дә, карты да җыйналды. Без дулкынланып шигырьләр укый башладык. Чират миңа да җитте. Мин сугыш еллары, әтиләребезнең сугыштагы хәлләре, халыкара фестивальдә үземнең катнашуым турында шигырьләр укыдым. Англиядән килгән делегатка багышланган "Авторучка" исемле шигыремне сөйлим.

Ул татарча язды "Тынычлык" дип,
Инглизчә дә
"Тынычлык" дип язсын иде ул!
....
Очрашырга язсын киләчәктә
Автоматлар түгел,
Авторучка тотып кулларга!

Үзем сөйлим - үзем күреп торам - клуб ишеге ачылды һәм залга майга буялып беткән эш киеменнән илле яшьләрдән өстен бер абзый килеп керде. Менә ул иң алгы рәткә килеп утырды һәм туп-туры миңа текәлде. Мин, тәмамлап, өстәл артына урнаштым. Теге абзый, шуны гына көткән кебек, урыныннан кузгалды да:
- Миңа сүз бирегез әле, - дип трибунага атлады. - Гафу итегез, эштән кайтып килешем... - Ул кесәсеннән бер фоторәсем алып, миңа сузды. - Бәлки, ялгышамдыр. Бу рәсем сезгә таныш түгелме? Күргәнегез юкмы бу кешене?
Мин рәсемне кулга алдым һәм ни әйтергә дә белми аптырап калдым. Рәсемнән хәрби кием кигән, гимнастеркасына "Кызыл йолдыз" ордены таккан, аз гына елмайган кыяфәттә... минем әти карап тора иде. Өйдәге альбомда да нәкъ шул рәсем саклана бит. Хәтта рәсем артындагы сүзләре дә хәтеремдә: "Улым, сезнең бәхет өчен сугышып йөрүче әтиеңнән".
- Бу минем әти! - дидем мин шатланып.
Залдагылар шаулап алдылар. Без, әдәби кичәдә утыруыбызны онытып, сөйләшә башладык.
- Кайттымы сугыштан? Исәнме ул?!
- Кайтты. Мәктәптә эшли.
- Кичәдән соң миңа адресын бирерсез.
Абый кеше йөзе белән залга борылды.
- Менә, иптәшләр, мин үземнең фронтташ. дусымны таптым. Мин аны югалтып тора идем. Салкын окопларда бер тәмәкене икегә бүлеп тарткан дусым иде ул. Нинди генә авырлыклар күрмәдек. Өеннән хат килсә, ул шатланып миңа йөгереп килә иде. "Менә, иптәш Галимов, ун яшьлек улым үзенең хатын шигырь белән язган" - дигәне бик яхшы хәтердә. Димәк, сез язгансыздыр инде аны. Безнең күрмәгән калмады, туганнар. Дошман мине ничә җирдән яралагандыр, санап караган юк.
Ул соңгы сүзләрен барыбызга да карап әйтте:
- Без, сезнең әтиләрегез, сезгә тынычлык яулап бирдек. Хәзер сезнең тынычлык турында шигырьләр язуыгыз мине сөендерә. Соңгы сүзем шул: бүгенге тормышыбыз күп корбаннар биреп яуланды, сез аны эшләп тә, шигырь язып та саклагыз...
Хәзер миңа бик тә якын булып тоелган шушы абзый, Хәй абый, трибунадан төшеп, иң арткы рәткә китеп югалды. Әмма безнең һәммәбездә дә әйтеп бирә алмаслык дәрт, якты омтылыш кузгатып китте ул...
Шундый очрашулар да була тормышта.
1996 елның февралендә Казанга килгән укытучылар Шәүкәт белән икебезне Тукай музеенә очрашуга чакырдылар. Бер ханымның Бакырчыдан икәнен белгәч, мин шул вакыйганы сөйләдем.
- Хәй Галимов исәнме? Миннән сәлам әйтегез, - дидем.
Хәй абзыйның авылдашы башын түбән иде:
- Ул юк инде.
Укытучылар Шәүкәт белән минем дуслыкның кайчан башлануы турында кызыксындылар.
Көтмәгәндә Шәүкәт болай диде:
- Якташым Хәй абый минем әткәй белән дус булган. Илдар белән минем очрашу ихтималы безнең әтиләрдә үк яралган, димәк...
Ә 1943 елда фронттагы әтиемә язган, татар солдатлары җыелышып укыган шигырьне мин кесәмдәге дәфтәремдә кадерләп йөртәм. Аның белән укытучыларны да таныштырдым. Менә ул:

Дошманнарга төбәп аткан чакта,
Калтыранмаслык булсын кулыгыз,
Сугышларда батыр булыгыз,
Сәлам белән шагыйрь улыгыз...



Тугызлылар рәхмәте

Исәнмесез, кадерле "Сөембикә"леләр!

Матур тышлы, тирән эчтәлекле, эчкерсез журналыгыз ай саен бәйрәм алып килә. Без, Тугыз авылы халкы, аны бик яратып укыйбыз.

Безнең авыл район үзәгеннән 70 чакрым ераклыкта урнашкан. Тугыздан ары юл юк, бездән башланган сазлыклар Омски өлкәсенә барып тоташа. Шул энҗе-мәрҗән кебек җәйрәп яткан күлләр тирәсендә берничә татар авылы – Кече Уват, Усак, Ачытбаш бар.

Авылыбыз зур. Өйләрне хәзер иркен, зур итеп салалар. Мәдәният йорты, урта мәктәп, берничә кибет бинасы авылыбызны бизәп торалар.

Халык кул кушырып, хөкүмәттән килгәнне генә көтеп утырмый, эшләп таба. Торна күз (клюква) җыялар, балык тоталар, хайван асрыйлар, кәсык (кедр чикләвеге) сугалар. Шулай да, яшәү көннән-көн кыенлаша. Авыл хуҗалыгы бетте диярлек. Ике урман хуҗалыгы бар иде, аларда да хәзер эш юк. Безнең төп байлыгыбызны – нарат агачын – Казахстан ягына, Омскига, Төмәнгә ташып бетерделәр. Как тактага утырдык та калдык. Алай да халык азгын түгел әле, ялкаулыкка, эчүгә сабышмый. Тугызлылар Себердә яшәүчеләрнең һәрберсе кебек каты телле, ләкин йомшак күңелле. Җырларга, биергә яратабыз. Әле хат язырга да, тормыштан зарланырга дип түгел, авыл халкының бер үтенечен җиткезергә, дип, утырган идем. Бик тә татар телендә спектакльләр карыйсыбыз килә. Без үзебез куябыз да, әмма профессиональ артистлар уйнауга җитми инде, билгеле. Себер татарларының күңеле сезнең өчен һәрвакыт ачык. Килегез, кайчандыр Шәйхи ага Маннур избач булып эшләгән борынгы Тугыз авылы кешеләренә җыр-моң бүләк итеп китегез әле.

Зәйтүнә МАРГАНОВА.
Төмән өлкәсе,
Вагай районы,
Тугыз авылы.



Н н



Нәни булышчы

Ул әле нәни булса да,
Һәрбер эштә булыша.
Аңар, нәни булышчым, дип
Әнисе исем куша.



Мине раббым тәрбияләде,
шуңа тәрбиямне дә күркәм итте.
(Хәдис.)

Уңай хисләр тәэсире

Галимнәр, уңай хисләр аша балада фикерләү, акыл сәләтен үстереп була, диләр. Моны ничек аңларга соң? Мәсәлән, бәби әти-әнисен күргәндә җанланып китә, елмая, димәк, анда уңай хис-тойгылар пәйда була дигән сүз. Әнисе белән әтисе дә нәниләренә иркә сүз белән шатланып, елмаеп җавап бирә. Шулай итеп, алар арасындагы элемтә-йогынты киңәя, көчәя төшә. Белгечләр, елмаю күрмәгән яки аз күргән баланың үсеше тоткарлана, диләр. Елмаюын гына түгел, баланың сөйләшергә омтылуын да җавапсыз калдырырга ярамый. Гомумән, аның һәр мөстәкыйль кыланмышын хуплап тору зарур. Чөнки нәрсәнедер үзе эшләргә омтылганда гына бала иҗади кеше булып үсә ала. Киресенчә икән, ул бары тик кушканны гына үтәргә сәләтле булачак. Балагызның үтә хәрәкәтчән, тиктормас булуы, кызыксынучанлыгы да сезне куркытмасын. Вакыты җиткәч, ул үзе игътибарын башка җитдиерәк нәрсәләргә юнәлтер. Барыннан да элек шуны яхшы аңларга кирәк: нәрсә дә булса ярамый икән, бала өчен ул баштан ук "ярамый" булырга тиеш. Ләкин шунысы да бик әһәмиятле, тыюлар белән артык мавыгырга ярамый. Сабыйга нәрсәне дә булса рөхсәт итмәгән очракта, нәрсәнең мөмкин икәнлеген дә аңлатыгыз. Мәсәлән, ипине идәнгә ташларга ярамый, ә тупны – ярый. Песине рәнҗетергә ярамый, ә иркәләп сыйпарга ярый. Бу чагында балада үз мөмкинлекләренә өмет чүрелми. Һәм ул алга таба моны ничегрәк башкарачагын күзаллап үзен тынычрак, ышанычлырак тотарга күнегә.

Сабый белән якыннан аралашмыйча торып, аның нормаль үсеше турында сүз дә була алмый. Дөрес, чамадан тыш игътибар да үзен акламый. Әйтик, әби-бабаларның кайгыртучанлыгы, гадәттә, бер яклыга – "ул кечкенә бит әле", дип оныкларын иркәләүгә, яклауга кайтып кала. Нәтиҗәдә, сабый моны шулай тиеш икән дип кабул итә. Ә менә үзенең дә башкалар турында кайгыртырга тиешлеге турындагы уй аның башына да кереп карамый. Артык иркә, тыңлаусыз, үз-үзен генә яратучы балалар менә шулай тәрбияләнә. Мондый күңелсез хәлдә калмас өчен, балага кечкенәдән өлкәннәргә ярдәм итә алу мөмкинлеге тудырырга кирәк.

Наратлар

Зур наратлар күккә кадәр үсеп
Чистартырга күкне телиләр.
Кояш чыккач, яңгыр явып узгач,
Бигрәк матур, аяз көн, диләр.



Намуслы булу нигә кирәк?

"Намус", "намуслылык" еш кына "чисталык", "сафлык" сүзе белән янәшә йөри.

Әдәпле һәм намуслы бала әти-әнисе, әби-бабасы, гомумән, кешеләр хезмәтенең кадерен белә, ихтирам итә. Үзе дә хезмәт сөя. Шуңа күрә һәрбер әдәпле малайның, кызның өйдә ул башкара торган эше була. Әгәр дә әти-әниең, әби-бабаң әлегә кадәр бу турыда сүз кузгатмыйлар икән, ул хакта син үзең аларның исенә төшер. Күн дә башкара торган эшләрең булса, аны яхшы итеп вакытында үтәргә тырыш.

Әлбәттә, төрле көтелмәгән хәлләр килеп чыгарга мөмкин. Ә син, ялгышлык белән чынаяк ватсаң да, яшермә, әйт. Гаебеңне бервакытта да башкага сылтама. Һәрвакыт дөресен сөйлә, ялгышың өчен гафу үтен.

Намуслы кешегә теләсә нинди шартларда да таянырга була. Шуңа күрә андый кешене барысы да хөрмәт итә, ышана.

Әдәпле вә намуслы бала иптәшенең китабын алып торса да, аны, рәхмәт әйтеп, вакытында кайтарып бирә. Китапны ертмый да, пычратмый да.

Бу җәһәттән, кечкенә дустым, минем сиңа берничә киңәшем бар:

1. Тәртиплелек һәм пөхтәлекне төп гамәлең ит.

2. Көчле һәм җитез булу өчен көн саен күнегүләр ясарга онытма.

3. Танышларың белән дә, таныш булмаган кешеләр белән дә үзеңне һәрчак әдәпле тот.

4. Автобус, трамвай һәм башка транспортта үзеңнән өлкәннәргә һәрвакыт урын бир.

5. Иптәшләреңне дә, өлкәннәрне дә алдама. Куркаклар һәм тәрбиясезләр генә алдаша, хәйләли. Алар кебек булма!

Ңң





Яңгыр

Яңгыр, яңгыр, язгы яңгыр!
Өзелеп көтте сине кыр.
Үсеп күзгә бәрәңге,
Яфрак ярсын өрәңге!



Сәгать суга Даң-Даң.
Хәбәр бирә таңнан.

Йә, әйтеп кара

— Кырмыска оясына карап яңгыр килүен белеп буламы? (Була. Яңгыр алдыннан кырмыскалар ояларына качалар, "ишекләрен" томалыйлар.)

— Кошларның барысы да җәй көнендә бер генә мәртәбә бала чыгарамы? (Юк. Чыпчыклар, мәсәлән, бер җәйдә өч мәртәбә бала чыгара.)

— Ни өчен кош оясындагы йомыркаларны кул белән тотарга ярамый? (Кош оясын ташлап китмәсен өчен.)

— Чәүкә, сыерчык ише кошлар ни өчен ат, сыер, сарыклар өстенә куна? (Оя корырга йон җыялар.)

А. ТИМЕРГАЛИНА,
Ә. ВӘЛИЕВА рәсемнәре

Зәки ЗӘЙНУЛЛИН

ЮЛДА



Н. ХАЖИӘХМӘТ рәсеме

Җитез йөрешен кискен акрынайтып өсте каплаулы КамАЗ автобус станциясе янында туктады. Чандыр, җиңел гәүдәле шофер машина кабинасыннан сикереп төште дә, автобус көтеп, җыелып торган кешеләр төркеменә таба атлады. Чибәр генә кызга елмаеп дәште:

— Исәнме?! Казанга китәсеңме?

Кыз гаҗәпләнгәндәй матур итеп елмая башлаган иде, егетнең йөзен таныгач, елмаюы юкка чыкты. Йөзенә уңайсызлану билгесе булып сизелер-сизелмәс кенә кызыллык йөгерде.

— Әй-е! — диде тотлыга биреп. — Ка-занга-а...

— Мин дә шунда барам бит. Әйдә, җилтерәтеп илтеп куям. — Күзләрен кызның йөзеннән алмыйча өстәде: — Бу машина минем тегесеннән дә шәп! Әйдә!

Үзе кызның зур букчасын кулына алды да, машинасына таба атлады. Кыз сүзсез генә аңа иярде...

Авылны чыккач, КамАЗ кечкенә калкулыкка үрмәли башлады.

— Ялга кайттыңмы? Озаккамы? — дип сорады шофер кабина эчендәге киеренке тынлыкны бозып. Үзе тиз генә кызга карап алды. Тегесе баш кагып күңелсез генә елмайгандай итте.

Егет ачык күңелле, сөйләшергә яратучан җан иде, ахрысы.

— Әти-әниләрең исәннәрдер бит?

Кыз юлдан күзләрен алмыйча гына:

— Бер авылда яшәгәч, беләсеңдер инде ничегрәк икәннәрен, — дип куйды.

— Һы! Гали абзыйны бик сирәк күрәм бит. Мин автобазада, ул колхозда, каравылда. Сирәк күрешәбез. Аннан соң ул... — Кызга тагын карап алды: — Исәнләшсәм, җавап та бирми. Читкә карап китә. Нилектәндер инде. Минем бер гаебем дә юк бит.

Кыз елмайгандай итте. Тик елмаюы күңелсез һәм гаепле кешенеке кебегрәк иде. Азрак сүзсез генә бардылар. Тик егет тыныч кына яши торган җаннардан түгел икән.

— Ничегрәк соң... гарадскуй тормышлар? — дип сорашырга тотынды.

— Бер ыңгайга шунда, — диде кыз теләмичә генә. Тавышында кырыслык сизелә иде.

— Һы, бер ыңгайга, имеш! Ничек аңларга инде ул "ыңгай" дигәнеңне?

— Теләсәң ничек аңла.

— Үзең аңлат.

— Төпченмә. Нәрсәгә инде ул сиңа?

— Һы, нәрсәгә, имеш. Гурыт, гурыт дип миңа кияүгә чыкмадың бит. Беләсем килә, ничегрәк икән ул гурыт дигәнең.

Кыз дәшмәде. Шофер да азрак сүзсез барды да, җәһәт кенә кызга карап алгач, тагын сорады:

— Кияүгә... чыкмыйсыңмы соң әле?

— Алучы юк! — диде кыз. Исәбе азрак ирония кушып әйтү иде, тик сүзләрендә авыртканлык сизелде. Ә шоферның үз туксаны туксан иде.

— Һы! Мин ялынганда, миңа киләләр аны. Ике елдан артык йөрдек бит...

Ачуы чыга башлаган йөзен кызга табан борды да, тормозына басылган машинадай туктап калды:

— Йә-ә, син нәстә инде-ә! Ә? Тукта, хәзер үк!

Кызның чибәр бите буйлап бер-бер артлы эре яшь бөртекләре тәгәри иде. Егет машинасын уңгарак, юл читенәрәк туктатты. Рульне ике куллап кочаклап, аңарга күкрәге белән яткандай алдагы юлга текәлеп, сүзсез генә утырды. Ул елаган хатын-кызны юата белми иде шул. Кыз мышык-мышык килеп, тавышын чыгармыйча, байтак елады. Аннан кулындагы кечкенә сумкадан кульяулыгын чыгарып, күзләрен сөртте, кечкенә көзгегә карап азрак төзәтенгәндәй итте. Егеткә карамыйча акрын гына дәште.

— Әйдә... кузгат инде машинаңны.

— Кузгатырбыз ла ул, — диде егет. — Аны кузгатуның әллә нәрсәсе юк. Мин сине, әле Казаннан кайтып килешли, узып барганда чамалап алдым. Кире борылдым, байтак киткәч. Йөрәк түзмәде. Сагындырган дисәм инде. Чурт белсен. Шулай да бер күреп сөйләшәсе бик тә килеп йөри иде инде. Әллә кайчаннардан бирле. Менә җае чыкты...

Кыз аның сөйләгәнен машина тәрәзәсеннән тышкы якка карап тыңлады. Егетнең тавышы, инде чит ирнеке булса да, аның өчен бик тә кадерле иде. Егет сөйләвеннән туктагач, башын борып аңарга карады. Күз карашлары тулы сагыш һәм ярату иде.

— Син, Әлим, мине гафу ит инде. Авылдагы авыр эштән гарык булып, шәһәрдәге... җиңел тормышка дип чыгып киттем бит мин. Сине ташлап киткән өчен Ходай әҗерен бирде, ахрысы. Бетерделәр башымны, ярты елга да бармадым. Кала егетләренең башында сине тоткалау да... Һәм бүтәне генә икән шул. Синең кебек түгел алар. Оят инде әйтергә дә... Фатир юк. Аны алам дигән өмет тә юк бөтенләй. Теге Алла каргаган тулай торакта — общежитиеда уза көннәр... төннәр. Син сораткач, әти белән әни дә каршы төштеләр. Нәселләре тегеләй дә, нәселләре болай. Малны күп тоталар, син анда катыргага барасың бит, мал карарга гына, диләр. Гаиләләре ишле, балалары күп, диләр. Хәзер менә фабрикада эшлим. Андагы эш авылдагыдан да авыр. Түләү дә начар. Шәһәрдә — культура диләр иде. Бөтен культуралары шул — кичен бәйләнгән исереклләр. Эштә мастерлар бәйләнә. Каршы торсаң, үзеңә тагын да начаррак була. Бик үкенәм мин сине ташлап калага киткәнгә. Син миңа ачу тотма инде, зинһар, гафу ит?!

— Ярар инде. Син нәстә?! Гафу үтенәсең. Син киткәч, тәүге ел бик авыр булды инде булуын. Йөрәк әллә нәрсә эшләде дә куйды. Азрак эчеп тә йөргән булдым әле, басылмасмы дип. Шуннан эчкән баштан ава-түнә кичен кайтып бара идем, берәү арттан килеп култыклады. Өйгә хәтле бергә кайттык. Эчкән баштан мин тегеңәргә бәйләнәм: "Әйдә, миңа кияүгә чык", — дип. Көлә бу. "Эчүеңне ташласаң, чыгам. Син чыкмаслык егетме әллә", — ди. Күрше урамнан, теге Гафур абыйның төпчек кызы Мәрьям икән бу. Дүрт ай дигәндә, өйләнешеп туй ясадык. Аракыны бөтенләй ташладым. Аңарга да эчергәнем юк. Утырабыз табыннарда икәүләшеп лимонад эчеп. Инде менә ярты елдан артык — җомга намазына йөрим. Биш яшьлек улымны да үзем белән йөртәм. Миннән дә шәп белә намазны сабый. Безгә ияреп бабай да йөри башлады. Элек коммунист ие. Аллага шөкер — дингә кайта башлады татар халкы. Хатын инде икенчегә авырлы. Давай, мин әйтәм, үзең кебек чибәр бер кыз бала тап миңа. Картайган көндә кияү дә кирәк бит дип көлдерәм тегене. Яшибез! Аллага мең шөкер, биргәненә...

Машина моторы гөрелдәвенә кушылып, шофер егет тавышы агыла да агыла. Сөйләгәннәреннән тулы шатлык, бәхет бөркелеп тора. Кыз, аның тиз-тиз сөйләвен тыңлап, азрак тынычлангандай булды бугай...

Ике сәгатькә якын вакыт үтүгә, Казанга килеп җиттеләр. Җиденче троллейбус янында егет машинасын туктатты

— Гафу ит, Гөлсинә... Син троллейбус белән кит инде. Минем башкача һич кенә дә вакыт юк. Кайтырга кирәк...

Кыз аңа туры карамыйча гына әйтте:

— Әдрисне исеңдә калдыр. Кереп йөр... Казанга килгәндә...

— Ю-у-ук, син нәрсә?— диде шофер егет. - Нинди әдрис тә, нинди кереп йөрү, ди тагын. Мин бит әти кеше. Менә дигән хатыным бар. Ю-у-ук! Аллага шөкер биргәненә. Артыгы кирәкми.

Машина эченнән авыр сумканы алып җиргә куйды.

— Ташла калаларын. Кайт бөтенләйгә авылга. Әти-әниең дә ялгыз. Авылдагы абзаң эчә, тегесе читтә марҗа белән. Кайтып өйләнгәне дә юк. Синең бәхет, бәлки, үзебезнең авылдадыр. Авыл тулы буйдак егетләр! Йөриләр каңгырап... Гурыт дип качып беттегез авылдан...

— Хуш! — диде Гөлсинә. — Рәхмәт сиңа!.. Бәхетле бул!

Зур сумкасын күтәреп троллейбуска таба китеп барды. Әлим кабинага кереп утырды, машинасын тиз генә борды да, китеп тә барды. КамАЗ борылган җирдә сыек, зәңгәр төтен генә һавада эленеп калды...

"Гаилә әлифбасы" фикер туплый.

Без, Казан шәһәренең 72 нче урта мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучылары, "Сөембикә" журналының һәр санын зур түземсезлек белән көтеп алабыз, яратып укыйбыз, фикер алышабыз.

Журналның дүртенче саныннан танылган язучы Марзия Фәйзуллинаның "Әнигә дә, бәбигә дә" дигән яңа сәхифә алып бара башлавы безне бигрәк тә сөендерде. Анда басылган шигырь, тизәйткечләр, милли рухтагы төсле матур рәсемнәрне без инде үз эшебездә файдалана да башладык. "Гаилә әлифба"сының балаларыбызга милли тәрбия бирүдә, аларны халкыбыз тарихы, мәдәнияте белән таныштыруда зур өлеш кертәчәгенә ышанып калабыз. Рәхмәт сезгә, яңа сәхифәне бүләк иткән өчен!

Фирдәүс ВАФИНА,
милли мәсьәләләр буенча
директор урынбасары.

* * *

Минем биш яшьлек кызым бар. "Гаилә әлифба"сын аның белән бергәләп укыйбыз. Кызыма бик ошый. Шигырьләрнең күпчелеген ул инде яттан сөйләргә өйрәнде. Башваткычлар, балалар уеннары турында да онытмасагыз иде.

Рузиләнең әнисе — Гүзәл ЗАРИПОВА.

* * *

Бүгенге көндә гәзит-журналларны күпләп алдырып булмый. Шулай да "Сөембикә"гә һәр елны язылабыз. Безнең гаиләнең иң яраткан журналы ул. "Әнигә дә, бәбигә дә" дигән яңа сәхифәгезнең бирелүе бик вакытлы булды. Бигрәк тә балалар бакчасына йөрми торган балалар өчен файдасы зур. Ана телен начар белүче яшь әниләргә беренчеләрдән булып ярдәмгә килүегез үзе бер мактауга лаек. Рәхмәттән һәм хөрмәттән башка сүзебез юк. Уңышлар телибез.

Суфия ШӘМСЕТДИНОВА, дәү әни. Казан.

Розалина ШАҺИЕВА

Күңелемнең гөмбәзендә

Этнографик шигырь

...Булган сыман гашыйк Мәҗнүн
Ләйләсенә,
Төшенмичә хәтта моның
мәгънәсенә –
Борынгыга гашыйк була –
Матди исәп-хисап тулы фани
дөнья...
Сагындыра борынгының
табигате,
Гүзәллеге, нәзакәте, тын хәяты...
Салмак кына алга таба хәрәкәте,
Камиллеге, тулылыгы, бәрәкәте...
– Кайда алар – узган гомер,
"иминлекләр",
Нәзек күкрәк, күе керпек,
җеп-инлекләр?
Кайда алар – энҗе калфак,
кандиль алка,
сабыннары "Гөлҗиһан" вә
"Гөлзөләйха"?!
Асыл кием, һөнәр хәвәс якты
мәҗлес,
Калфак чигеп, келәм тукып
"алларган" күз?
Гөлҗамаллар зәвык биргән нурлы
мохит –
Сандыкларда тынкычланган
маллар шаһит...
Әфсүн уку, кич утыру, "фал
салулар",
Исемнәре: Бәдерхәят,
Таңсылулар?
...Ул кызларның сөрмәләре,
бөрмәләре –
Алсу ияк төпләрендә "төрмәләре" –
муенында җепкә тезгән хөрмәләре,
орчык кебек бөтерелеп йөрмәләре,
Авылларда әтләренең өрүләре!
Ирләренең ат өстендә йөрүләре –
Мәхәббәттән өстен булып
көлүләре,
Туры килсә гашыйк булып үлүләре –
Гармунының йөрәкләрне телүләре!
Сукалары, путалары, туталары,
Сөлгесендә елкылдаган укалары!..
Агайлары, тугайлары,
тургайлары –
Такырбае, Бакырбае, Тукайлары!..
Сабантуе, көрәш ашы, хөррияте,
Хөр булырга, көр булырга – ил
өйрәтте.
Мәңге яшәр халыгымның чын
мирасы –
тутыкмасы, бирешмәсе,
җиңелмәсе...

Казан бакчалары

Гыйшык ахы тулы
Кичке бакчаларда
чатный куак,
чатный йолдыз,
яфрак ява...

Күңел шул җәйләрдә
Шакый җилләр булып
сөю исе сеңгән
төнге капкаларга...
Юлыксам шуларга,
абынам үткәнгә,
чумам
кайтмаслыкның
коесына.
Яшьлек әремнәрен,
бөкре дәвачыдай,
әле җыясы бар...
Соңгы тоясына...



Д.ЮСУПОВ фотосурәте

* * *

Телгәләнә йөрәк...
бәһасе юк
тирәнлөргә төшеп сөюнең –
Бары бер кыл калдым, бары
бер кыл –
бер талпыну... Сулып-сыену.
Әй, машина,
көпчәк арасында –
нәрсә бара шыңшып, ял сорап?
Миннән калмый торган гүзәл
афәт –
Сагынуым чаба әлсерәп.
Шәмәхә җәй! Нинди азгын чәчәк –
үз кодрәтен биргән тугайга!
Мин дә шулай, үз төсемә кертеп,
Сине кочлап сөйдем бу җәйдә.
Сау бул сөю! Сылулыгың белән
тарих битләренә кереп кал!
Бер кыл калдым, бары бер кыл,
бер юл шигырь, бер сүз, бер хыял...
Койма артларында яшәүчеләр,
Сизмәүчеләр гомер үткәнен –
бер кыл... Чиртсәң, ләкин җавап
бирә
җан-ватаным, телем, үз каным.

Шушы кылның тибрәнүе – иркем,
Татлы уем, моңым, кураем!
Киң күкрәкле илем – җаным күрке,
Шигырь коем, күңел сараем!

* * *

Сентябрь, 1995 ел.
Багдадтан кайткач

Айлар үтте...
Сары болытлар артыннан
дөнья каплап, чыңгылдашып,
күчмә чегән теркемедәй,
кош көтүләре үтте...
Кош өмәсе – симәнке капчыгы
итте газиз гөмбәзне.
Тотрыксыз уйларым –
боз булып каткан
тылсым куыгы –
дөньядай, –
көмеш пәрдә белән капланды.
Сумала эчендәге җанлы зат сыман
тырпылдап калды сөюем.
Йөрәгемне – бу иңнәрне камап алган
шәхессезлек авырлыгын үлчәүче
геремне –
яшердем эчкәре:
күзем йомып, күз кабагы
сәхнәсендә
уйнатам татлы хәтер
театрымны.
– Бу ямьсез, үксез, тарихсыз
дөньяның
хуҗасы кем?
Гыйсьянчы акыл, пәрәвездәй, өзә
ялган-фәхешлек пәрдәсен.
Һәркөн Казансу өстендә,
шыксыз мәеттәй, узган михнәт
чайкала...
Пәйгамбәрләр ташлаганга,
нурсыз кышларда
сулкылдый, елый
нәүмиз Казан-кала...

* * *

Әй, мине илгә китергән
кара чегән арбасы!!!
Тигәнәкләр арасында
ник калдырдың алласы?!

Күчмәләр күкрәп киткәндә
Җаегына, Дагына –
бабаларым азык булган
аждаһа корсагына!..

* * *

Тимер кара ишекләр артында
Нарасыйлар
татарчалап җавап бирә
тишекләрдән –
йорт тавыгы болар, диеп
шикләнсәм дә,
һуштан язам шатлыгымнан,
телем исән.

Бу утлы тузгынган шәһәрне,
әйтерсең,
мегезкәем белән кочкә тотып
торам.
Өстәлдәге савытларда гөнаһ
ташый...
Ямьсез көннәр шыксызларны
алмаштыра.

Бу дөньяны тудыручы, изге гайрәт,
бир татарга бәхет, диеп,
дога чыгам...
Үз язмышым карачкысы
тыпырчына...
– Халкым, диеп, еглый-еглый,
мин тончыгам.

* * *

Нәни кызым, нурлы йөзем,
гомерең булсын, бәгърем, озын.
Кыр чәчәгем, киләчәгем,
нәрсә чәчсәм: үсәчәгем...

* * *

Биш ел гомер тоз кундырды
Күз төбенә дәрья ясап...
Ымсындырды, юксындырды
Яман көнгә буш көн ялгап...

Күз түрендә ак карамчык –
бирешми кара көюгә –
Әллә сәдәф,
Әллә кәфен –
бу дәрьяда
үксезлектән батып үлгән
бер сөюгә.

Тәкәнештә

Җен көләтө. Моржасыннан төтен чыга...
Кәртче карчык... Күз багучы, җен капчыгы...
Ник алдадың – асылташлар вәгъдә итеп?
Аргамаклар,
хаума-кошлар,
алтын тәхет...
Падишаһлык, дәфнә тажы,
хозур язмыш,
Тешсез кара авызларың
чалыш-чалыш
диде: саклан! – юкка күккә тиярсең, дип, –
Татлы бәла - кара кеше сөярсең, дип...

Юрауларың күңелемнең гөмбәзендә,
Йолдыз булып калка
маңгай кәгаземдә.
Үзең генә серле карчык –
кара киезитек,
каурый булып,
салкын котыпларга гиздең...

...Көләтең юк... уырт кебек, урыны гына.
Сагынам йортың, синең иске
комганыңны...
Мәңге мохтаҗ синең изге
им-томыңа...
Тирәкләрдә
"ак яулыгың" – искән моңың...

"Киләләр"

Ах, киләдер, ахры,
патша йөгереге "кортка"!

Татар әкиятеннән.

Зонтик асларында чайкалалар,
лилипутлар, "күзле капчыклар",
зыр-зыр әйләнәләр, үчеклиләр
бөкре картлар, җәнҗал карчыклар.
Күпме ихлас,
дәрт һәм яшәү көче
җиргә чүккән карчык затында!
Җир акылы, җир маемы сеңгән
Үлем белән яшәү чатында?!
Ник рәссамнар
карчык йөзләренә,
потка табынгандай, табынган?!
– Маңгайларда, шифа кәгазедәй,
Киләчәккә хәбәр язылган...
Бозык-черек токым арасында
"Алтын мая" булып калалар –
Меңьяшәгән сабый дәү әниләр,
хәр күңелле
"үҗәт" бабалар...





Г. ХАФИЗОВ фотосурәте

Минем каенанам – "мировой"!

Киндер сөлге

1951 ел, 30 апрель, булачак иремә нәкъ 20 яшь тулган көн. Ә минем өчен иң мөһиме, бик теләп алынган килен булып төшкән көн. Исәпләсәң, исең китәрлек, 46 ел гомер инде узып та киткән. Бүгенгедәй хәтеремдә, матур итеп киенгән каенанам мине, булачак киленен, ике беләгенә бик матур чүпләм сөлге салып, сөлге өстенә башланмаган түгәрәк кайнар ипи куеп, кызы Сафура апай белән, бал белән май тотып, елмаеп каршы алганнары, зур мамык мендәргә бастырып, күзләремә туры карап әйткән җылы да, бик тирән мәгънәле дә сүзләре:

— Улым да сине бик яратып өйләнә, без дә бик теләп килен итеп кабул итәбез. Әгәр үзеңне яраттыра алган барлык сыйфатларыңны да гомерең буе саклый алсаң, барыбыз да бәхетле булырбыз. Кайчак бу сиңа да бик җиңел дә бирелмәс, тормыш дигәнең гаҗәп катлаулы, без дә һәрвакыт баллы гына да булып бетмәбез. Кайбер урыннарда гафу итә белергә дә өйрәнергә туры килер. Икегезгә дә тигез мәхәббәт, саулык, бәхет бирсен Ходай! Мин тудырган кадәр үк булмаса да (10 бала), бәхетле әти-әни булырга да насыйп булсын! Сиңа бирдәнбер бүләгем үз бирнәмә, үз кулларым белән суккан шушы киндер сөлгем булыр, гомерең буе сезгә килә торган бүләкләргә юл ачсын!

Чыннан да, каенанамның барлык теләкләре дә кабул булды, изге җаннардан булган, күрәсең. Үзе дә бездән һәрчак риза булып, күп елларын безнең белән бергә яшәде.

Бер авылдан булганга, әти-әниләребез аралашып гомер иткәнгәдер, мин каенанамның бөтен тормышын яхшы белә идем кебек. Әтисе — Галимулла абзый озын буйлы, таза, нык кеше. Һөнәре — вак тартмалы сәүдәгәр, йорттан читтәрәк кәсеп иткән. Әнисе Миңнехан әби кечерәк кенә буйлы, төскә бик чибәр, шактый укымышлы, һәр эшкә уңган, искиткеч пөхтә, җитез, тау ягы кызы. Нәкъ әтисенә ошаган бер генә кыз тудырып (каенанамны) аны бик кадерләп, матур киендереп үстерә. Башта әнисеннән, аннан минем бабамның (зур мәгълүматлы Бәдретдин мулла) әнисе Мәһүбә абыстайдан гыйлем ала. Күрәсең, каенанам үзе дә бик сәләтле кыз булгандыр, бөтен Коръәннең күп өлешен тәрҗемәсе белән белә иде.

Яшьли генә күршеләрендә үк яшәгән, ишле гаиләле Мөхәммәтгали абзыйның дүртенче улы Мөхетдингә кияүгә бирәләр. Каенанам әнисеннән күп аермалы буларак, туфрагы бик уңдырышлы хатын булып чыга. Һәр ике ел тулар-тулмастан куенына яшь бала алып, аларның санын 10 га тутырганын тоймый да кала.

Әмма ни кызганыч, 1938 елны каенатамның фаҗигале үлеменнән соң өй тулы бала белән тол кала. Әтисе шактый еллар каенанама

булышса да, ул да бит мәңгелек түгел. Җитмәсә, олы улы Гаяз абый сугышта һәлак була. Авыр, ач елларда, хәйран зур булгач тагын 4 баласының үлем ачысы, аның өстенә, фәкать 33 яшендә генә, каенанам кулына 2 сабыен калдырып, кызы Сафура апайның йөрәк авыруыннан үлеп китүе ничек бу ананы аяктан екмагандыр. Сабыр, бик сабыр иде шул ул.

Бергә гомер итү елларында мин аның һәрвакытта үз дәрәҗәсен белеп яшәгәнен сизә идем. Менә нәкъ шул ягы белән ул зур хөрмәткә лаек булды. Бервакытта да вакланмады, юкны-барны күрмәде. Аздан гына да канәгать булды. Кечкенә генә бүләкне зур итеп, чиксез рәхмәтле булып ала белде. Мин тегеп биргән күлмәкләрне яратып киде. Чөнки мин аның гомере буе хыялланган бер серен белә идем. Ул гәүдәгә озын, ләкин ябык. Тулы булып күренәсе килеп, өчәр кат күлмәк кияр иде. Мин күп уйлап тормый гына әнкәй өчен күлмәкләрнең эчкесен дә, тышкысын да үзбәкләрчә, күкрәктән бик мул итеп бөреп-бөреп тегә башладым.

Шулай бервакыт, әнкәем безгә килгәч тә булды бу хәл, ирем эштән кайткач, гадәтенчә, аякларын юып, чиста оекбашларын киде дә, салганнарын юа башлады. Йа, Хода! Бу хәлне каенанам күреп тора икән ләбаса. Мондый очракларда кайбер каенаналарның:

— Шул оекбашларыңны да юмагач, нәрсәгә ул хатын? Китер үзем юып бирәм дигәннәрен ишеткәләгәнем бар иде. Ә мин: "И җаным! Гомер кыланмаганны әнкәй алдында әллә миңа үч итеп юасың инде?" — дигән булам. Менә шулчак әнкәй:

— Юсын, балам, юсын. Ни өчен аңа ике кул бирелгән? Ул өйдә дә юа иде, сиңа юарга әйбер болай да бик җиткән, — димәсенме, рәхмәт яугыры!

Аннан тагын бик матур гадәте — кешеләрдәге матур сыйфатларны күрә белү, шул турыда сөйләргә ярату иде. Безгә килгәч, дусларыбызга әнкәй белән әңгәмә кору ошый иде. Шаянраклары:

— Кәшифә апа нәрсәләр сөйли соң? — диюгә, икенчеләре инде күптән аның ни турында сөйләгәнен белеп:

— Гөлчәчәген мактый, киленнәрен мактый инде, — дип сокланалар иде. Ә үзләре аны күбрәк миңа ишеттерергә теләрләр иде. Тирәнрәк уйлап карасаң, нинди зур акыл иясе булган ул. Тормышның күркәмлеген, килен белән ике арадагы мөнәсәбәтләрнең тыныч, матур агышын саклаучы дипломатиянең бик акыллы төре булган бу.

Тормышыбыздагы узган гомернең тагын бер матур мизгелләрен искә аласым килә.

Каенанам кайда гына булса да, улы белән рәттән утырырга ятатты. Чөнки улы әнисе янына килеп утыруга, аның кулларын учына алып:

— И, әни! Бигрәк тә йомшак инде синең кулларың, — дип назлап сыпырмый калган көнен, ә анисенең үзенең кулларын сыпырган улының кулын үбеп алмаган чагын хәтерләмим.

Шулай бервакыт каенанам белән иремнең, алда язып үткән наз тулы матур мизгеленә, бер дус хатыным тап була, бәлки, беренче мәртәбәсе генә дә булмагандыр. Ул миңа:

— Косасыларым килде боларның бу кыланмышларына, белмим син ничек түзеп утыргансыңдыр, — диде. Күрәсең, анага йомшак күңелле, итагатьле булган ир кешенең хатынга да, балаларына да, тирәюньдәгеләргә дә шундый ук булганын аңлап җиткерә алмагандыр. Иремнең бу матур, назга бай сыйфатларын әнисеннән килгәндер дип уйлыйм. Яшьтән үк ятим калып, ата тәрбиясен күрми үскән бит ул.

Каенанамның тагын бер изге, матур сыйфаты — кемгәдер үпкәсе булса да, аны озак сакламыйча үткәреп җибәрә белү сәләте иде. Күңеленең нинди генә чагында да без эшкә киткәндә һәрчак ачык чырае белән, хәер-фатихасын биреп озатып кала, кайтып кергәндә дә тәмле сүзе белән каршы ала иде. Инде менә күптән безнең арада булмаса да, без аның хәер-догасын тоеп яшибез. Ирем эшләгән елларда кайчакта премияләр биргәлиләр иде. Безнең йортта аның исеме бервакытта да премия дип аталмады, әнкәйнең хәер-догасы дип йөртелә иде.

Аллага шөкер! Без хәзер дә сау-сәламәт, назга бай, тыныч узган һәр көнебезне, балаларыбызның безгә карата итагатьле җылы карашын тоеп яшәвебезне дә каенанамның, әни-әниләребезнең хәер-догасы дип кабул итәбез.

Гөлчәчәк ГАЛИЕВА.

Яшь әни язмалары

Ничек балага узмаска?

Шәфкать туташы ятагыма кадәр озатып, бозны эчемә куеп ук чыгып китте. Ул ишекне ябуга, одеялымны тартып китердем дә, битемне томаладым. Тамактагы төерне ничек тә тизрәк йотып җибәрергә, күзләремә мөлдерәп тулган яшьне хатыннарга күрсәтмәскә кирәк иде. Сизмиләрме соң?

— Әллә елыйсың? Шулай каты авырттымы?

— Туңдым, шуңа ябынып яттым, — дигән булдым. Тәнем авыртамы, әллә җаным күбрәк әрниме?

Соңгы ике атнада ниләр кичергәнемне Ходай да, үзем генә беләм.

Буйга уздыммы әллә, дигән уй аяз көнне яшен суккандай итте. Икенче бала? Билгеле, кирәкми. Әлегә мин бу вакыйгага физик яктан да, аннан бигрәк, рухи яктан да әзер түгелмен. Кеше: "Берсе янында икенчесе үсә", — дигән була да ул. Башкалар өчен җавап бирә алмыйм, теләсәләр, рәттән өчне тапсыннар, ә миннән булмый.

УЗИдан күренеп, әле мини абортка өлгерә алганымны белгәнче, йокламадым да бугай. Тегесенә, зурысына барудан котым очып куркам мин. Күргән нәрсәм булмаса да, укыганым, ишеткәнем бар. Карынымдагы баланы кисәк-кисәк тунатып алырга йөрәгем житмәс кебек тоелды. Көлсәгез, көләрсез, әмма аның кычкыруын ишетермен дигән уйдан котыла алмадым. Авыртуына да түзәрсең, хатыннар, әнә, бик кимсетәләр анда, дип сөйлиләр. Өстенә нинди генә сүз әйтмиләр, диләр. Ыңгырашсаң "артист" буласың икән. Монысы әле иң йомшагы. "Ирең белән ятканда рәхәт булган бит", "Анда җәелмәскә идең"... Тагын әллә ниләр, әллә нәрсәләр. Әйтерсең, үзләре роботлар, җаннары да, тәннәре дә юк.

Мин барган поликлиникада мини

аборт кына ясыйлар. Кызганычка каршы, төгәл адресларын күрсәтә алмыйм. Биредә хәзер абортка 18 яшькәчә булган хатын-кызларны гына кабул итәләр. Поликлиника башка юнәлештә эшли, ул ханымнарга теләмәгән йөклелектән ничек котылырга икәнен түгел, ә аны булдырмау юлларын өйрәтә.

Алга китеп булса да әйтим, мин монда бер генә битәрләү сүзе дә ишетмәдем. Танышларым аша кергәнгә генә түгел, һәммә кешегә мөнәсәбәтләре шундый аларның.

Операция бүлмәсенә кергәч, куркып, югалып калуымны күреп, врач аркамнан кагып, мине тынычландырды. Шәфкать туташы операция буена күзен минем йөздән алмады, үзе гел елмайды. Соңыннан, әйткәнемчә, бүлмәгә кадәр озатып куйды. Аннан, һәр ун минут саен врач кереп хәлебезне белешеп торды.

Әйе, теләмәгән йөклелектән мин әнә шулай, чагыштырмача җиңел котылдым. Тик менә...

Уйланганыгыз бармы, безнең илдә аборт һәрбер хатын кичерергә тиешле котылгысыз нәрсә кебек бит ул. Теләмәгән йөклелектән котылуның күпләр башка юлын белми дә бугай. Авылны әйтмим дә, әле шәһәрдә шулай.

Чит илдә, хатын-кыз бала табу йортыннан чыгуга, гинеколог аның янына: "Хәзер ничек сакланырга уйлыйсыз?" — дип килеп җитә икән. Өемә үк килуләренә өметләнмим инде анысы. Мөрәҗәгать иткәч, кешечә кабул итсәләр икән, дим. Паспортың булса, билгеле. Инде биргә 5-10 ел йөрсәң дә, әгәр һәр килүеңдә янында паспортың булмаса, регистратурада синең белән сөйләшеп тормыйлар, бернинди врач та сине кабул итми.

Абортка керергә анализ биргәндә, берочтан гинеколог белән киңәшеп китәрмен, дигән идем, ул ни дияр, бәлки, миңа спираль куйдырырга кирәктер? Килеп керүгә: "Нигә уздың?" — диде дә, сөйләшергә дигән теләгемне сүндерде. Киңәше дә шушы соравы кебек үк мәгънәсез булмас дисезме?

Хәер, аңардан башка да мин үземне балага узудан саклану чаралары хакында азмы-күпме хәбәрдар дип саныйм. Шулай тиеш булганга гына сөйләшмәкче-киңәшмәкче идем. Кайбер хатыннар кебек гармональ төймәләр эчүдән дә курыкмыйм мин. Инде бу төймәләр хакында сүз чыгарганмын икән, күптән әйтергә теләгән бер-ике фикеремне дә сезгә җиткезәсем килә.

Журнал битләрендә ул таблеткалар турында сез дә еш язасыз. Әмма күбрәк аларның исемнәрен санап чыгу белән генә чикләнәсез шул. Мин аларны теләсә кайсы аптеканың витринасына күз салып та укый алам. Сез бу мәсьәләнең башка ягын күтәрсәгез иде. Әйтик, журнал укучы хатын-кызлар исеменнән дәүләт җитәкчеләренә, хәтта Президентның үзенә үк (ә нишләп алай итмәскә, безнең, хатын-кызларның сәламәтлеген саклау аның да бурычы бит!) бу төймәләрне күпләп сатып алуны сорап мөрәҗәгать итәргә кирәк. Үзе аларны эчә башламаган кешегә генә алар даруханәләрдә күп кебек тоела. Берьюлы бөтен гомереңә җитәрлек итеп алып куя алмыйсың ләбаса. Икенче тапкыр аптекага шул ук даруны алыйм дип керсәң, бетте, кайчан буласы да билгесез, диләр. Мәсәлән, иң әйбәтләрдән саналган "Марвелон" бүген шәһәрнең ничә генә аптекасында бар икән? Минем кебек яшь балалы хатын аны эзләп каланың бер ягыннан икенче башына бара алмый бит әле.

Мондый даруларны без түгел, ул төймәләр үзләре безне эзләргә тиеш. Сатсыннар, әнә, халык иң еш йөри торган ипи, сөт кибетләрендә. Ольлар тагын чәчләренә ябышырлар дисезме? Алар бүген презервативларның да һәр чаттагы киоскта сатылуын яратмыйлар. Әмма минем исәнлегемне аборт чиратларында җуясым килми. Килми!

Тагын бер нәрсә бар. Бу төймәләрнең бәяләрен дә кеше буе җитәрлек итәргә иде. Киләчәге, үз гражданнарының сәламәтлеге турында чынлап торып кайгырткан хөкүмәт, гомумән, аларны бушлай өләшер иде әле.

Абортны минем сыман фаҗига итеп кабул итүчеләр байтак дип беләм. Карынындагы әнә шул яралгыны җәлләү, чарасызлык, курку, авырту — барысы бергә бутала. Минем алдан операция бүлмәсенә кергән ханым өстәлдә анын җуйды. Үзе дә әйтеп тора — нервылар. Күптән түгел ул Вишневский урамына урнашкан түләүле поликлиникада мини аборт ясаткан. Акчасын алгач, "тырышканнар" тегендә, соңыннан аны "ашыгыч ярдәм" машинасында алып китеп, тагын ике больницада чистартып җибәргәннәр. Аборттан чыккач, ул гел теге түләүле поликлиниканың банкротлыкка чыгуын теләп ятты.

"Ничәне ясатканымның санын да белмим", — дип бары безнең ханымнар гына "мактана" aладыр. Әйе, аборт бу проблеманы хәл итү юлы түгел. Тик башкасы, кешелекләргә кая соң анын, кая? Күршеләр бүген тагын сугыша, әнә. Хатыны, балага узмауның бердәнбер юлы ире белән йокламау дип белә. Кызыкмы? Юк, кызганыч, әйеме?!

Күңелдәген кәгазьгә түктем-түктем дә, кинәт бик күңелсез булып китте. "Суга батучы саламга ябыша", — диләрме әле? Мин ачынып, мин үртәлеп кенә, әлбәттә, бернәрсә дә үзгәрмәячәк. 1997 ел бюджетында "Гаиләне планлаштыру" программасын финанслау, әнә, 2,5 тапкырга кимегән. Депутатларга бала тапсаң ни дә, еллар буе буйга уза алмый җәфалансаң ни. Рәсми статистика сифилис ише чир белән авыручылар саны моңарчы күрмәгән, ишетмәгән тизлектә үсә, илгә СПИД эпидемиясе яный, дип чаң суккан бер мәлдә, бу программага хөкүмәт чыгымнарын чикләү — дуамаллыктыр, мөгаен? Әллә бу депутатларның: "Мәхәббәт уйнар чак түгел, илдә акча кытлыгы, эшсезлек, ул хис-теләкләрегезгә йозак салып торсагыз да зыян итмәс", — диюләреме? Булыр, булыр...


Г. ХАФИЗОВ фотосурәте

Айгөл.
Казан.

ИР
белән
ХАТЫН

Ачы кәнбагыш



А. ТИМЕРГАЛИНА коллажы

Кама аръягы районнарының берсендә булган бу вакыйганы ул якта әле дә хәтерлиләрдер. "Исемнәрен үзгәртсәгез дә, сеңлемне дә, кияүне дә, Фәридәне дә авыл халкы гына түгел, райондашлар да таныячак инде", — диде миңа Рәшидәнең апасы. Бу хәлләр турында язуымны да ул үтенгән иде. "Дөрес аңлагыз, берәүдән дә үч алу өчен яздыртасы килүем түгел. Башкаларга сабак, гыйбрәт булмасмы, дим. Гаиләле ирләрне аздыручы хатыннар да адым саен очрый, мөмкинлек чыккан саен хыянәт итәргә әзер торган ирләре дә аз түгел бит. Сеңлем дә шулай дияргә кушты". Рәшидәнең балалары, Фәриданең кызы хакына без исемнәрне, барыбер үзгәртергә кирәк, дип, килештек.

Алты балалы зур гаиләнең төпчек кызы ул Рәшидә. Сабый чакта, бәлки, иркә, назлы бала да булгандыр, әмма үскәч, апасы сөйләвенә караганда, тормыш һич тә иркәләп-үсендереп тормаган аны. Яшьли генә кияүгә чыккан, бер-бер артлы ике бала тапкан. Эчкече ир белән күргән газапларын, аерылып кайтып, апаларына сөйләгәч, болары башта ышанмаганнар хәтта. Кыйнау, мыскыл итү, ач тоту дисеңме...

— Бу хәлләрдән соң ир-ат ягына күз дә салмас инде бу дисәк, авылда артыннан бер егет йөри башлады моның. Рәшидә Камилнең үзенә өйләнергә теләге барлыгын да сиздерде. "Балаларыңны үстерешәбез, сабыр ит", — дип, без һәммәбез каршы килдек. Яратуы булдымы, күрәчәге идеме, чыгарга уйлады шул Рәшидә. Камилдән дә ике бала тапты. Үги-үги инде, азрак эчсә, ияреп килгәннәр күзенә җен булып күренә, бәргәләп алырга да күп сорамый. Югыйсә, малайлар "әтием, әнием", дип өзелеп торалар.

Авылда ялгыш басканыңны да читләрдән яшерә алмыйсың. Шундый үткер күзле берсе Рәшидәгә яңалык җиткезә: "Камилең йөри бит синең!" Башта, билгеле, ышанмый хатын, әмма теге хәбәр дөрес булып чыга. Кем белән дип әйт әле, үзе белән янәшә сыер савучы Фәридә белән.

Ире белән җайлап та сөйләшә Рәшидә, йортта табак-савыт шалтыраган көннәр дә еш була. "Болай йөргәнче, барып аның белән торып кара. Кайтсаң, балалар хакына кертермен", — дип тә карый. Вакытыннан алда чәчләргә кырау төшә, җыерчыклар күзгә күренеп арта, йөрәк чәнчеп-чәнчеп авырта. Көндәш ачысы диләр шул аны. Ә тегеләр арасындагы гыйшык (әллә азгынлык микән?) уены айларга гына түгел, елларга сузыла.

Әмма түземлекнең дә чиге була шул.

Юк, кәнбагыш җәл булмый Рәшидәгә. Ризыкмыни ул?! Инде болай да тулып ташыган кесәгә соңгы тамчы гына була әлеге кәнбагыш. Авыр, гаугалы тамчы.

Кичке ашны ашап, табын янынннан кузгалгач,

Камил: "Әниләргә төшеп менәм әле", — дип, капчыкка көнбагыш тутыра башлый. Ишек төбеннән ирен Рәшидә кире бора.

— Нигә аз алдың? Китер, үзем тутырып бирим әле.

Мөлдерәмә тутырып, бау таба алмагач, капчык авы-зын иске ал күлмәгенең ал путасы белән төйнәп үк куя.

Ире китеп берәр сәгать узгач, ул да, тукта, мин дә үземнекеләргә барып килим әле, дип урамга чыга.

Тыкрыктан борылганда Фәридә белән йөзгә-йөз бәрелешә язалар. Тегесе, баш кагып кына исәнләшә дә, тиз-тиз атлап, узып та китә. Азрак баргач, ток суккандай хатын туктап кала.

— Көнбагыш! Фәридә кулында көнбагышлы капчык! Ал тасмасын да алмаган!

Калганы әллә төштә, әллә өндә эшләнә. Кискен бер карарга килгән Рәшидә, кая барганын да онытып, кире өйләренә борыла. Кулына эләккән беренче пычакны алып бик тиз әйләнеп тә чыга. Гөнаһ шомлыгына каршы дигәндәй, урамда беркем дә очрамый. Берәрсе: "Исәнме, Рәшидә? Кая барышың?" — дип, эндәшсә дә, ул әле бәлки кире уйлар, әрнүен, үртәлүен кабат үз эченә генә бикләнеп үткәреп тә җибәрер иде.

Ишек шакыган тавышка башта Фәридәнең әнисе чыга.

— Фәридә янына килгән идем, Газизә апа.

Әлеге минутта үзен ничек тыныч тота алуына соңыннан Рәшидә үзе дә шакката. Бусагада Фәридә күренгәч тә, йөрәктә кайнаган ачу, ярсуны тыеп калыр көч таба.

— Көнбагышны кире китер, Фәридә.

— Нинди көнбагышны? Нәрсә сөйлисең син?

— Камил биргән көнбагышны чыгар дим мин сиңа!

Аның тавышында моңарчы булмаган кискенлекне ишетеп, тегесе шым гына өенә кереп китә.

Рәшидә бүген дә белми: әгәр Фәридә көнбагышлы капчыкны матур гына аның кулына тоттырса, ул кире борылып чыгып киткән булыр идеме, юкмы? Тик тегесе соңгы минутта ал путаны чишеп җибәрә дә, көнбагышны Рәшидә өстенә сибә. Шул бөтенесен хәл итә дә инде. Җиң эченә яшерелгән пычак секундлар арасында Рәшидә кулына күчә, көндәше абайлап өлгергәнче, ул пычак белән Фәридәнең эченә кереп тә чыга. Берсе, эчен тотып, аяк астына чәчелгән көнбагышлар өстенә бөгелеп төшә, икенчесе шул көнбагышларны таптый-таптый чыгып китә.

Аяклары бу юлы Рәшидәне туп-туры әтисе йортына алып килә.

— Үтердем мин Фәридәне...

Ә аннан суд була.

Терелеп больницадан чыгарга өлгергән Фәридә дә катнаша судта. Бәхеткә, аның ярасы алай ук куркыныч булмый.

— Судка кадәр Рәшидәне күрә алган бөтен туганнар аны:"Мин гаепле, бик үкенәм", — дип әйтергә үгетләдек, — дип сөйли апасы. — Ә ул тотты да, судьяга: "Алар мине бу адымга үзләре этәрделәр, мин гаепле түгел", — диде. Аннан: "Тик, зинһар, миңа ана буларак та карагыз, дүрт балам барын онытмагыз", — дип тә өстәде.

Прокурор аны дүрт елга хөкем итүләрен сорады. Сеңлебез бөгелеп кенә төште. Ул бу кадәр срок көтмәгән иде, күрәсең. "Йөрәге болай да начар, күтәрә алырмы?"— дип, котыбыз калмады.

Фәридәгә дә сүз бирделәр.

— Тырнак очы кадәр дә гаебем юк, — диде ул. — Һәммәсе гайбәт. Ялгызым булгач, йөри, дип, сөйлиләр инде.

Үзенә сүз бирүләрен дә көтмәстән, Камил торып баса.

— Нәрсә яшереп торырга?! Бөтен авыл белә, ләбаса. Йөрдек. Үзең чакыра идең бит, Фәридә.

Шуннан соң Камил гел бер сүзне кабатлый: "Рәшидә түгел, мин гаепле. Ул болай да күп түзде". 8 Март бәйрәменә Фәридәгә — кул сәгате, баласына уенчык — йомшак аю бүләк иткәнен дә әйтергә онытмый. Хатынының яңа эчке күлмәкләре дә сөяркә чемоданына күчкән икән. "Ник әйтмисең, мунчада очрашып йөрдек, дип, әйт",— ди ул Фәридәгә.

Рәшидәне бер елга ирегеннән мәхрүм итәләр.

Хөкем карары укылып бетүгә, Фарида корт чаккандай урыныннан сикереп тора.

— Утыртмагыз! Зинһар, утыртмагыз аны төрмәгә. Бөтен гаепләремне кире алам. Нинди кәгазьгә кул куйыйм? Мин бит аны куркытырга гына теләгән идем. Больницага килеп гафу үтенмәде ул.

Суд берәүләргә кызык ясар өчен оештырылган тамаша түгел шул. Йорт тулы бала (олысы 8 класста укый, кечесенә дүрт яшь), үкенүдән, гаепле булуыннан үзен-үзе кая куярга белмәгән ир кала, Фәридәнең соңарып тамган күз яше дә ярдәм итми, Рәшидәне, хөкем карарын җиренә җиткезү өчен, Бөгелмә төрмәсенә озаталар.

Камил ике атна саен Бөгелмәгә чапты. Эчүен ташлады. Рәшидә аңа: "Эчәсең икән, кайтуга аерылышабыз", — дип киткән иде. Юк, йортны тараттмадылар. Әнә шул сигездә укучы олы малай бөтен эшне эшләп торды, сыерны сауды, көтү куды, идән юды. И-ии, әниләрен бик сагындылар инде. Сигез ай утырып кайтты Рәшидә. Президент каршындагы Ярлыкау комиссиясе аның срогын азга булса да киметә алды.

Әллә кайчан тел очымда торган сорауны бирәсе иттем.

— Хәзер ничек яшиләр?

— Күптән түгел генә бездә булып киттеләр. Мин дә синең кебек: "Ничек яшисез?" — дип сорадым. "Ул Фәридә белән тагын ничек бергә эшләрсез икән?" — дим. Көлә Рәшидә. "Берәр юләрлек кылмасын, дип, минем өчен куркасыз инде, беләм, — ди. — Юк, апа, мин аңа бүтән бармагым белән дә чиертмим. Ә менә телем белән үтерәчәкмен. Ансыннан мине берәү дә тыя алмый".


Хатын-кызның бер уңай ягы (әллә сәер гадәте дип әйтергәме икән?) бар — үткәннәрне оныта, гафу итә белә ул. Рәшидә дә менә Камилнең сигез елга сузылган хыянәтен кичерерлек көч тапкан. Алай гына да түгел, төрмәдән чыгып, ел узуга дүрт малай янына кечкенә кыз да алып кайткан. Зур таш өй салып кергәннәр.

Гөлнур САФИУЛЛИНА.

Ни гажәп, фәхишәлек иң борынгы, шул исәптән, иң керемле һөнәрләрдән санала. Кызганыч, хәтта татар кызлары да тәннәрен сатып, көн күрә башладылар. Соңгы мәгълүматларга карагандa, Казанда фәхишәләрнең саны арта бара икән. Минем әңгәмәдәшем Клара (исеме үзгәртелеп бирелә) да әлеге гамәлне һөнәр итеп сайлаган. Аңа 23 яшь. Бүгенге көндә Казан шәһәренең бер югары уку йортында укый. Сезгә дә шул әңгәмәнең кыскартылган вариантын тәкъдим итәбез.

Замана кызлары

Һөнәрнең дә була төрлесе...



— Ни өчен бу һөнәрне сайладың? Үзеңне бу өлкәдә профессиональ дип саныйсыңмы?

— Минем кешечә житешле тормышта яшисем килә. Әлеге һөнәрем миңа шуны тәэмин итә. Ә инде үз эшемне әйбәт белмәсәм, клиентлар арасында уңыш казанмас идем. Бу инде профессиональ дигән сүз.

— Син үзеңә күпме бәһа куясың?

— Бер төн өчен 50 дән 200 долларга кадәр. Кешесенә карап. Нинди кеше эләгә бит әле, баймы ул ярлымы?

— Фәхишә дигән исем кыерсытмыймы? Бәлки, болай атаганны өнәп тә бетермисеңдер?

— Сер түгел, бездә хәзер иң яхшы, иң мул тормышта өстәгеләр, эшкуарлар, рэкетчылар һәм фәхишәләр яши. Мин хәләл акчамны алам, кеше рәнжетү-алдау белән шөгыльләнмим. Хәзерге вакытта иң чәчәк атучы һөнәр иясе булуымнан бер дә кимсенмим.

— Безнең шәһәр фәхишәләре арасында татар милләте вәкилләре бармы?

— Бик сирәк булса да бар, ләкин алары руслашкан, дияр идем.

— Сиңа партнерларыңның гашыйк булу очраклары булмадымы?

— Булгалады. Әмма мин аны кабул итмим. Минем өчен беренче чиратта акча. Ә элемтә тотабыз, алар минем көндәлек клиентларыма әйләнде.

— Ихтимал, үзеңнең гашыйк булганың бардыр? Мәхәббәт бик самими хис бит.

— Мәхәббәт, ярату?! Болар минем өчен түгел.

— Клиентлар белән кайда очрашасыз? Ничек табасыз?

— Очрашу кунакханә номерларында, мунчаларда, эш урыннарында. Кыскасы, кайда мөмкин, шунда. "Чакыру" буенча өйләренә дә барабыз. Ә табуга килгәндә, анысы да төрлечә, җәмәгать урыннарында, урамда. Танышлары үзләре шалтырата.

— Кайчан бу эш белән шөгыльләнә башладың?

— 3 ел элек.

— Казанда күпме андыйлар? Сезнең арада конкуренция бармы?

— Безнең шәһәрдә югары дәрәҗәдәге фәхишәләр чагыштырмача аз. Якынча 20 кыз. Иң яшенә 16 яшь. Ә конкуренция юк диярлек. Дөрес, кайбер вакытларда клиентыңның башкага киткәнен ишетү авыр була.

— Клиентларыгыз кемнәр?

— Төрле контингент: бизнесменнан алып колхозчыга кадәр. Шулай ук чит ил кешеләренә, югарыда утыручы түрәләргә дә хезмәт күрсәтәбез.

— Нинди чит телләрне беләсең?

— Инглиз һәм немец телләрен.

— Буш вакытларыңда нәрсә белән шөгыльләнәсең?

— Табибка күренү, гардеробны җайга китерү белән шөгыльләнәм.

— Берәр маньяк кулына эләгүдән курыкмыйсыңмы?

— Мин психик яктан сау-сәламәт ир-атларга гына хезмәт күрсәтәм. Әлбәттә, төрле хәлләр булырга мөмкин, Ходай сакласын.

— Туганнарың синең бу эшең турында беләләрме?

— Юк. Бу бит минем өчен вакытлы эш. Хәзергә исә акча туплыйсы бар.

— Күп тупладыңмы соң?

— Тәүлегенә уртача 10 клиент кабул итәм. Бу аз түгел. Миңа машина алырга җыенам.

Әңгәмәдәш — Гөлнара БОРИСОВА.



№ 9, 1997 ел.

«Сөембикә» журналының кушымтасы

"Аш-су" конкурсы дәвам итә

Чаллы шәһәрендә яшәүче Гөлфия ҖӘЛӘЛЕТДИНОВА рецептлары

Каражимешле торт

Тугланган 3 йомыркага 1 стакан шикәр комы, 130 г эретелгән атланмай, ярты стакан төелгән чикләвек төше, 1 стакан он һәм аш серкәсе белән сүндерелгән 1 чәй кашыгы чәй содасы салып, барысын бергә болгатыгыз.

Аннан соң барлыкка килгән камырны тигез ике өлешкә бүлегез дә, бер яртысына 1 аш кашыгы какао өстәп болгатыгыз, икенчесе шул килеш калсын. Һәм һәр икесен дә аерым-аерым табаларда 35 минут пешереп алыгыз.

Каражимешне 20 минут чамасы җылы суга салып тотканнан соң, 25 минут кайнатып алыгыз һәм ваклап турагыз.

Аннары суынган кабартманың берсенә 1 катлам крем, 1 катлам туралган каражимеш, 1 катлам төелгән чикләвек сибеп, икенче кабартманы шуңа каплагыз. Өстенә кабаттан крем ягып, каражимеш белән чикләвек сипкәч, тортны үзегез теләгәнчә матурлап бизәгез.

Крем түбәндәгечә әзерләнә: 300 г атланмайга 1 аш кашыгы какао, 100-150 г куертылган сөт кушып туглагыз.

Эремчек бәлеше

Иң элек бәлеш эчлеге ясагыз, ул түбәндәгечә әзерләнә: 6 йомыркага 200 г эремчек, ярты стакан шикәр комы салып туглагыз.

Инде 120 г атланмайны яисә маргаринны он белән уалап таба төбенә сибегез дә, өстенә әлеге эремчек эчлеген салыгыз. Шуның өстенә кабаттан он белән уаланган 120 г атланмай сибеп, мичтә пешерегез.

Майны он белән уалаганда аш серкәсе белән сүндерелгән ярты чәй кашыгы чәй содасы салырга онытмагыз.

Кумәч

200 г эремчеккә ярты стакан шикәр комы, 1 чәй кашыгы чәй содасы, 4 йомырка һәм әз-әзләп он салып йомшак кына итеп камыр басыгыз. Әлеге камырдан йомры шарчыклар ясап уртасын тишегез. Шул күмәчләрне ике ягы да кызарганчы майлы тирән табада пешерегез. Мондый күмәч чәй эчәргә бик тәмле була, балалар да бик яратып ашый.

Г. ХАФИЗОВ фотосурәтләре





№ 9, 1997 ел.

«Сөембикә» журналының кушымтасы

Йолдызнамә



Ә. ВӘЛИЕВА рәсемнәре

Октябрь



Кучкар


Максатка омтылыш һәр эшегездә юлдаш булсын. Хәзер чәчкән хезмәт орлыклары кышын җимеш бирәчәк.



Үгезбозау

Ир-ат мәхәббәте хатын-кызлар өчен иң күркәм бүләк. Сөйкемле ханымнарның җан тынычлыгы ир кешенең намуслылыгына бәйләнгән.

Үгезбозауларга кешеләр белән үзара мөнәсәбәт хакында уйланырга бик уңай вакыт.




Игезәк

Берьюлы барысына да ирешергә теләп, күпне югалтуыгыз ихтимал. Максатлы эш һәр яктан да отышлы.



Кысла


Бары тик сабырлык һәм игелеклелек аша гына теләкләрне тормышка ашырып булачак. Үзсүзлелек белән әлләни майтара алмассыз.



Арыслан

Хезмәттәшләрегездә таяныч табарга теләсәгез, кешелеклерәк, шәфкатьлерәк булырга тырышыгыз.


Дуслар белән башкарылган күмәк эш күп файда китерер.



Кыз


Физик сәламәтлегегез рухи халәтегезгә, кәеф күтәренкелегенә бәйле.

Тормыш мәшәкатьләрен артык көч куймыйча гына хәл итү мөмкинлеге туачак. Хезмәттә уңышлар көтелә.




Үлчәү

Актив эшчәнлек аша күпкә ирешергә мөмкин. Хезмәт сөючән, чыдам кешеләрне уңышлар көтә.



Чаян

Яңа дус-ишләр яңа эш башларга юл ачачак. Сүздә һәм гамәлдә гадел, намуслы, сабыр һәм игелекле булырга тырышыгыз.



Укчы

Шәхси тормышыгызда да, эшегездә дә зур үзгәрешләр көтелә.

Тирә-юньдәгеләргә ярдәм итеп яшәргә тырышыгыз. Файдасы тиячәк.



Кәҗәмөгез

Кешеләргә күрсәткән җан җылысы рухи күтәренкелек алып киләчәк.

Эш белән гаилә тормышын җайлый белү үзара мөнәсәбәтләрне яхшыртуга китерер.



Сукояр

Вакытлыча кәеф кырылуның тавыш-гауга чыгуга сәбәп булуы ихтимал.

Ниятеңне тормышка ашыру матди ярдәмгә юл ачачак.



Балык

Эштәге уңышлардан башыгыз әйләнеп, бөтенләй бушанырга ашыкмагыз. Бер атналык кыска ял мәгъкуль булыр иде.

Йолдызнамә мәгълүматларын астролог Рәмзия КУЛЕВЦОВА әзерләде.

Сылубикә

Көз

Сезнең күзләр бераз караңгырак төстә, әмма нурлы, саргылт-яшел (зәйтүн җимеше төсендә), алтынсу-көрән яки фирүзә төсле. Тирегез кара-кучкыл яки абрикос төсмерендә, кояшта кызынгач, алтынсу бронза төсенә керә. Чәчегез көрән яки каштан төсендәдер. Сез җылы төсләргә бай кием-салым яратасыздыр, мөгаен. Көрәнсу төсмерле иннекләр сезгә аеруча килешә, шулаймы? Димәк, сез — Көз заты.

Көз тибындагы хатын-кызга нәфислек һәм мөлаемлык хас. Гадәттә, ул ачык чырайлы, төсе-бите күзгә ташланып торучан. Күзләре тәэсирле. Чәче, нигездә, куе төсләрдә. Бит тиресе нәфис, персик яки бронза сыман төсмерле була. Көз хатын-кызына бирелгән шушы күркәм табигый үзенчәлекләргә җир төсләре һәм аш тәмләткечләр төсе кебек җылы тоннар туры килә. Көз ханымның карашыннан ук җылы бөркелә, шул сәбәпле аңа җете төсләр бик килешә. Ә менә артык кычкырып торучы чамадан тыш ачык, салкын яки тоныкл төсләрдән баш тарту кулаерак булырдыр.

Кара-кучкыл яки бронза төсендәге тиреле Көз хатын-кызы бизәнмәсә дә — гүзәл, аның ачык йөзе, нурлы күзләре, табигый сөйкемлелеге һәммә ир затын әсир итәрлек. Инде кемгәдер, чамасын белеп кенә, бизәнү ошый икән, җылы, җете төсләр сайлаган хатын-кыз ялгышмас. Бит тиресе өчен алтынсу-сары тональ крем кирәк. Әгәр сипкелләр булса, аларны тулысынча бетерергә яки буяп яшерергә тырышмагыз. Сыек тональ кремның юка гына катлавы аркылы күренер-күренмәс сипкел-торткеләр Көз хатын-кызына аерым бер ягымлылык бирә.

Көз ханымнарына бакыр яисә коралл төсендәге кершән, пудра сайларга киңәш итәбез. Алтынсу төсмерләр дә йөзегезне ачып торачак. Көз затларының нурлы күзләре фантазия өчен киң мөмкинлекләр ача. Керфекләргә куе көрән сөрмә тарту килешер. Ә инде күз кабаклары өчен күләгәләр (тени) төсе мондыйрак: аксыл-көрән, абрикос төсе, алтынсу-бакыр һ. б. Күзләрнең төсенә бәйле рәвештә камыш, зәйтүн җимеше, аерым очракларда — зәңгәрсу-яшел, баклажан төсләрен куллану да урынлы булыр.


Кич белән ниндидер мәҗлескә яки бәйрәмгә барырга җыенучылар кичке макияжның үзенчәлекләренә игътибар итсеннәр. Күзләр нечкә алтынсу сызык белән әйләндереп алына. Инде иннек буялган иреннәрнең уртасына бер тамчы алтынсу ялтыравык "тамызып" алу үтә килешле күрсәтәчәк. Ул ялтыравык күз кабагындагы күләгә (тень) төсендә булса, сезнең макияждан хәйран калачаклар.

Көз ханымына иннек сайлау җиңел түгел, чөнки, нигездә, аңа теләсә нинди иннек килешә сыман. Әмма салкын, зәңгәрсу төсләләренә күз дә атмагыз, алар сезнең җылы төсләрдән торган макияжга һич туры килми. Кызгылт-сары һәм көрәннең лосось балыгы төсеннән башлап шоколад төсенә кадәр барлык төсмерләре сезгә килешә. Иннек сайлаганда шуны күздә тотыгыз. Иң кулай вариант — куе кызыл иннек һәм бер тамчы ялтыравык.

Ягымлы һәм нәфис Көз ханымның хушбуй исе дә җылылык тойгысы уятырга тиеш. Шул сәбәпле, сандал агачы, мускус, ваниль, җиләк-җимеш, чәчәк исләреннән торган исләр җыелмасы аның якты, җылы кыяфәтен тагын да тулыландырачак.



Г.ХАФИЗОВ фотосурәтләре



№ 9, 1997 ел.
«Сөембикә» журналының кушымтасы

Замана балалары



Бүләкләр көткәндә...

Бала үзеннән-үзе матур, аңа ни кидерсәң дә килешә, диләр иде элегрәк. "Әнием, миңа бу күлмәкнең нәрсәседер ошап бетми", — дип, көзге каршында бөтерелүче алты яшьлек кызыма, ни җитте киемгә исе китмәгән улыма карыйм да, авыр сулап куям. Замана балалары... Үзем эчтән генә сөенәм дә, димәк, сабыйларыбызда кечкенәдән үк зәвык хисе борынлый, алар матурлыкка, камиллеккә омтыла. Гаҗәп түгел, чөнки тирә-юньдә алар өчен мәгълүмат җитәрлек. Телевизордамы, концерт-тамашалардамы — бала күзе килешле киемгә төшә. Аеруча нәни кызлар киемдәге төсләр нисбәтенә сизгер була. Һәм, әлбәттә, аларны матур киендерәсе килә. Әлеге тойгылар һәммә ата-анага да таныштыр, дип уйлыйм.



Фестивальнең иң нәни, иң сөйкемле артисты — Карина Камалова — махсус бүләк иясе.

Базар киемнәренең бертөрлелегеннән туйган бүгенге көндә балалар модасы фестивале — бердән, ата-аналарның: "Баланы ничек киендерергә?" — дигән соравына җавап булса, икенчедән, нәниләрнең үзләре өчен соклангыргыч тамаша да иде. Фестиваль "Илдан" фирмасының "Лик" мода театрында үткәрелде. Анда Казан шәһәрендә эшләп килүче сигез балалар модасы театры катнашты.

Яшь артистларның сөйкемлелегенә затлы күлмәкләрнең ачык төсләре, дәртле музыка өстәлде. Тамашачы балалар да аларны көчле алкышка күмеп, ихластан елмайдылар, биеделәр, җырладылар.



Подиум дигән мода сәхнәсендә бер манзара.

Сабыйларның эчкерсез шатлыгы зурларга да көчте. Ул төнне, мөгаен, һәр кызчык төшендә үзен подиум дигән сәхнәдә, тылсымлы мода дөньясында күргәндер.

Фестивальдә күрсәтелгән кием коллекцияләреннән иң яхшылары дип "Илдан" фирмасы балалар мода театрының "Бавария пирожныйлары", "Ниязым Алисә" балалар мода театрының "Кояшлы җил", "Яшел нур" исемлеләре танылды. "Мотылек" (125 нче мәктәп-гимназия), "Шарм", "Юнита" театрлары, "Дина С", "Радуга" студияләре, 411 нче балалар бакчасының "Богема" театры да балалар модасы өлкәсендәге уңышлы эшләре белән куандырды.

Шунысы кызганыч, "Сөембикә" журналының "Иң яхшы милли коллекция өчен" дигән махсус бүләге быел иясез калды. Чөнки тәкъдим ителгән модельләр арасында милли рухта тегелгәннәре бөтенләй юк диярлек иде. Күрәсез, балалар өчен кием үрнәкләре иҗат итүчеләргә уйланыр урын бар.

Фестивальнең бер катнашучысы да бүләксез калмады. Оештыручылар (Казанның яшьләр һәм балалар эшләре буенча шәһәр комитеты, "Ниязым Алисә" мода театры) тырышлыгы нәтиҗәсендә спонсорлар да, бүләкләр дә җитәрлек иде. Балалар модасын үстерүгә үз өлешләрен кертүчеләргә — "Заря" акционерлык җәмгыяте, "Ирис" кибете, "Заречье" банкы, "Болгар-капитал" фонды, "Райден" фирмасы, "Заман" нәшрияты, "Джованни", "Александр ЛТД" кибетләре, "Казан чикләвекләре" компаниясенә балалар да, зурлар да рәхмәтле булдылар.

Инде киләсе елгы фестивальгә әзерлек башланды. Анда татар милли киеме үзенчәлекләрен файдаланып иҗат ителгән модельләр дә булсын иде дигән теләктә калыйк.



"Заря" акционерлык җәмгыятенең татлы бүләге — экияти сарайны җимерергә туры килде. Чөнки һәр баланың бу могҗиза-тортны татып карыйсы килә иде.



"Лик" театрының үз балалар мода театры бар. Ул Казанда иң күркәмнәрдән санала. Күрегез, нинди матурлар!



Сәхнә артында.

Гөлнара ГАБДУЛЛИНА.
О. КОСОВ фотосурәтләре



№ 9, 1997 ел.

«Сөембикә» журналының кушымтасы


Үзебез тегәбез

Иске яңаны саклый, ди халык. Әйе, саклау белән беррәттән, тузган киемнән бөтенләй башка яңа кием дә тегеп киярга мөмкин ич. Мәсәлән, рәсемдәге җылы кофталарны гына алыйк. Әлбәттә, тегү ысулы һәр кешенең үз фантазиясенә бәйләнгән. Без тәкъдим иткәннәрен сайлап алсагыз да ярый. Алар иске трикотаж, киҗе-мамык, күн кисәкләрен бер-берсенә ялгап тегелгән. Төрле тасма, төймә, замок кебек бизәгеч фурнитура куллану да үзен аклый. Тик нинди генә формада булуга



Т. БУРДАЕВА рәсемнәре

Искедән-яңаны



карамастан, әлеге кофталар түбәндәге гомум төп өлге буенча тегелә.

Инде тегү тәртибенә берничә киңәш:

Әгәр дә киемнең җөе тасма белән капланган булса, аны уң ягыннан тегү кулаерак. Ә трикотаж кисәкләрен алдан типчемичә генә, зигзаг җөе белән тегеп чыгарга киңәш ителә. Тоташтырып теккәндә иң элек җилкә җөен, җиңне, аннан соң гына җиң белән ян-як кырыйларын тегеп чыгыгыз.

Өлге детальләре:

1. Арттакта — 2 деталь
2. Алтакта — 2 деталь
3. Җиң — 2 деталь

Киемдәге ярлыклар

Киемгә тегелгән ярлыклар күптөрле. Алар тамгалары буенча бер-берсеннән аерылып торалар. Шулай да кайсысының нинәрсә аңлатуын һәр хуҗабикәгә белеп тору зарур.

60° — билгеле бер температурада юарга ярый.

— юарга ярамый

— үтүкләргә ярый


— үтүкләргә ярамый

A — барлык ысуллар белән дә чистартырга ярый

— чистартырга ярамый

CL — агартырга ярый

CL — агартырга ярамый



Йөкле хатынга - йөз төрле аш

Сабыйның тәмләп ими имүен күреп сөенгән анадан да бәхетлерәк кеше бармы икән бу дөньяда? Тик шунысы кызганыч, мондыйларның саны елдан-ел кими бара. Әлеге хәлдә калмас өчен яшь әнигә үзенә дә шактый тырышырга кирәк, билгеле. Чөнки сөтнең булу-булмавы күп нәрсәгә, һәм иң беренче чиратта, әни кешенең йөкле вакытта дөрес туклана белүенә дә бәйле. Ә нәрсә дигән сүз соң ул дөрес туклану? Яшь әни бигрәк тә нәрсәгә игътибар итәргә тиеш?

Йөклелекнең беренче айларында туклану төрен әлләни үзгәртмәскә дә була. Әмма ризыкта организм өчен кирәкле минераль матдәләр һәм витаминнарның булуы мөһим. Алар инде, әлбәттә, җиләк-җимеш, яшелчәдә күп.

Йөклелекнең икенче яртысында туклану күбрәк игътибар таләп итә. Кальций тозларына бай аксымлы ризыклар ашау сорала. Сөт, эремчек, пешкән ит, балык, яшелчә, җиләк-җимешне күбрәк кулланырга тырышыгыз.

Йөклелекнең ахырына таба тукланганда гәүдә авырлыгын арттырмауны да күздә тотарга кирәк. Шуңлыктан, татлы камыр ашамлыклары, ипи, шикәр ашаудан тыелу хәерле. Күбрәк "В" төркеменә кергән витаминнар һәм аскорбин кислотасына басым ясагыз.

Карынында бала үстерүче хатын-кызга исерткеч эчемлек, наркотиклар, тәмәке, шоколад ише әйберләр турында онытып тору зарур. Даруларны да табиб белән киңәшеп кулланырга тырышыгыз.



Менә сезнең нарасыегызның яралуына инде дүрт-биш ай тулып килә. Хәзер тукланугызның төрен бераз үзгәртсәгез дә ярый. Көндәлек ашамлыклар арасында 500-600 миллилитр сөт яисә әчегән сөт, 100-150 грамм эремчек, 150-200 грамм ит яисә балык, 500-600 грамм яшелчә, 200-300 грамм җиләк-җимеш булуы турында кайгыртыгыз. Кибетләрдә сатыла торган "Фемилак-1" сөт катнашмасында сезнең һәм балагызның организмы өчен кирәкле аксым компонентлары күп. Ул шулай ук минераль матдәләр һәм витаминнарга да бик бай. Аксым җитешмәгән очракта аны куллану файдалы.

Бала тугач, сөт күп төшсен өчен, йөкле хатынның өйдә тыныч шартларда, якыннарының кайгыртучан мөнәсәбәтен тоеп яшәве әһәмиятле. Чөнки төрле борчылулар да сөт кимүгә сәбәп булырга мөмкин.

Менә, сезнең балагыз исән-имин туып барыгызны да шатландырды, аваз салып ими сорый башлады. Инде сезгә дә туклыклы ризыклар ашау таләп ителә. Тәүлегенә 200 грамм ит (кош яисә балык ите дә әйбәт), бер литр сөт яисә әчегән сөт ризыклары, 100-150 грамм эремчек, 20-30 грамм сыр, 500-600 грамм яшелчә, 200-300 грамм җиләк-җимеш, 15-20 грамм атланмай, 20-90 грамм үсемлек мае ашарга тырышыгыз. Туклануның аксым, витаминнарга баерак булуын күздә тотканда, "Фемилак-2" дигән сөтле катнашманы файдалана аласыз.

Яшь әнигә күпме сыеклык эчәргә ярый соң? Күбрәк эчкән саен сөт арта, дип уйлаучылар да бар. Бу очракта, чыннан да, сөт күбрәк төшә, ләкин аның сыйфаты начарлана. Андагы аксым, май, витаминнарның микъдары кими. Бала имезүче ана углеводлар күләмен арттыра торган шикәр, татлы камыр ашлары, ярмалы ризыклар, ипине артыграк кулланса да, күкрәк сөтенең сыйфаты үзгәрә. Аксым, мәсәлән, таләп ителгәннән ике-өч тапкырга кими төшә.

Бала имезгәндә исерткеч эчемлекләр эчү һич ярамый. Кайберәүләр, бигрәк тә өлкән яшьтәге хатыннар, сыра эчкәндә ими сөте арта, дигән фикер белдерәләр. Ләкин шунысын истә тотыгыз: сырадагы алкоголь ана сөте аша балага күчеп, аның нерв системасына җитди зарар китерә. Кайбер очракта шуның нәтиҗәсендә баланың психик үсеше тоткарланырга да мөмкин. Никотин, ягъни тәмәке тарту да балага шундый ук зарарлы йогынты ясый.

Әни кешенең шоколад, кофе, какао, чикләвек, бал, гөмбә, лимон, әфлисун ише ризыклардан да тыелуы яхшы. Чөнки аларның балада аллергия авыруы тудыруы ихтимал. Суган, сарымсак ише исле, әче ризыклар белән дә мавыкмаска киңәш ителә. Чөнки сөтнең исен яратмыйча балагызның имидән бизүе мөмкин.

Зәйнәп
ГЫЙЛАҖЕТДИНОВА,
Казан дәүләт табибларның белемен арттыру медицина академиясенең икенче акушер-гинекология кафедрасы профессоры.



Г.ХАФИЗОВ фотосурәтләре

Сорагыз — җавап бирәбез

"Мин татар халкының чигүле калфакларына, түбәтәйләренә, күн читекләренә гашыйкмын. Үземнең дә аларны эшләргә өйрәнәсем килә. Казанда шундый училище бар дип ишеткән идем. Шул училище турында, андагы укыту тәртипләре турында журналда тулырак мәгълүмат бирмәссезме икән? Татарстанның башка шәһәрләрендә андый училищелар юкмы? Алдан ук сезгә рәхмәтемне белдереп калам.

Лилия, Бөгелмә шәһәре".

Лилия сорап язган училище Казанда дөрестән дә бар. Бу 40 нчы һөнәри-техник училище. Ул Казан шәһәренең Гвардейская урамындагы 9 нчы йортка урнашкан. Училищеда 1 ел укыйсы, керү имтиханнары юк. Әмма рәсем ясау сәләте булу мөһим, чөнки үзең белән рәсем алып килергә кирәк. Тулырак мәгълүмат алу өчен училищеның телефоны: 76-54-20 (директор).

Татарстанның башка шәһәрләрендә юкмы, дигән сорауга килгәндә, мондый училище Арча һәм Түбән Кама калаларында да бар.

Реклама

Сез яраткан җырлар

Хөрмәтле милләттәшләр!

Сез татар-башкорт җырлары, спектакльләре аудио-видео кассеталарын почта аша алдыра аласыз. А. Галимов, С. Фәтхетдинов, Г. Сафин, З. Шәрифуллина, З. Фәрхетдинова, З. Сәхәбиева, А. Фәйзрахманов һәм башка танылган җырчылар, шулай ук "Бәйрәм", "Хыял", "Заман" ансамбльләре сезнең юлдашыгызга әйләнер дип ышанабыз.

Видеокассета - 20000, аудиокассета 4000 сум тора. Заказларыгыз бер ай эчендә үтәләчәк.

Безнең адрес: 420108, Казан шәһәре, п/я-39.

Адресларыгызны төгәл языгыз! Сездән хатлар көтәбез!

Шаян сәхифә



Габдулла ГАЛИЕВ

Тел белгече

...Иптәшләр! ...Давайте, мәсьәләне читкә юнәлтмик әле. Понимайте, бирегә бүген бердәнбер важный вапрос карала. Ул да булса, укучыларыбызга татар теле дәресләре кертә башлау. Понимайте, иптәшләр, бу зур национальный вопрос. Кичә мине как директор школы, РОНОга чакыртып алдылар. И анда әйттеләр, давай, диделәр, родительское собрание җый, родительләр белән сөйләш. Вопросны кабыргасы белән куй. Понимайте, иптәшләр, начиная беренче сентября балаларыбызга татар теле кертә башлыйбыз. Моңар безне просто обязывают, иптәшләр, как хотите. И мин уйлыйм, правильно делают. Ведь безнең татарский язык - это язык Абдуллы Тукая, Джалиля и это... Гусейена Туфана. Нәрсә, нәрсә? Хәсән Туфан дисезме? Гусейена дип мин ялгыш әйттем, да? Тогда гафу итегез, Туфанны спутал Гусейен Ямашев белән... Нәрсә? Кайсыгыз ул анда?.. Ачыграк итеп сорап булмыймы? Тәк-тәк, татар теле дәресләрен кем алып барыр дисезме? Аңлашылды. Понимайте, бу бездә проблема түгел, иптәшләр. Эш сәгатьләре җитмәгән укытучылар достаточно бездә... Нәрсә? Именно кем укытыр, дисезме? Понимайте, без завуч белән бу вопросны хәл иттек. Татар телен Галина Петровна укытачак, иптәшләр... Нәрсә? Рус теле укытучысы бит ул? Ну што же, зато югары белемле! Нәрсә? Үзегез дә татарча ипилек-тозлык сукалый аласыз икән бит? Нигә үзегез генә укытмыйсыз? Сез нәрсә, иптәш укытучылар, миннән көлүегезме бу, понимайте!?.. Мин же физик-аналитик, ә Галина Петровна - языковед... Нәрсә? Рус теле укытучысы татар телен алып бара алмас! Кая алып бармаска? Шаулатып алып барыр иптәшләр! Кулларына словарь тоттырсаң, безнең укытучыларыбыз япон телен дә алып барырлар! Тәк што, монысына нет сомнение. Әллә сез Галина Петровнаны "Словарь татарского языка"дан файдалана белмәс диеп уйлыйсызмы? Ничек кенә файдаланып әле! Понимайте ли. Языкавед – ягъни тел белгече ич ул!.. Вот так...

Ринат МӘННАН

Сөенеч

Көлмә әле миннән хатын
Синнән ком коела дип,
Кичә генә сөендерде
УЗИга баргач табиб:

Ком тулы бөерләрең ди,
Ком тулган бавырыңа...
Әнә, әнә коела дип
Әйтмәде лә ул миңа!



К. КРУГЛОВА рәсеме



Сөембикә

СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

БӨТЕНТАТАР АЙЛЫК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ ӘДӘБИ-НӘФИС ЖУРНАЛ. ВСЕТАТАРСКИЙ ЕЖЕМЕСЯЧНЫЙ ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКИЙ И ЛИТЕРАТУРНО-ХУДОЖЕСТВЕННЫЙ ЖУРНАЛ.

Баш мөхәррир
Р. Р. ТУФИТУЛЛОВА

Редколлегия әгъзалары:

М. Ә. Әмирханов, Ф. В. Әхмәтова, Г. Х. Әхмәдиева, Г. Р. Балтанова, З. Р. Вәлиева, Р. Г. Камалетдинова, Г. Т. Минкина, Ф. Г. Мифтахова, Ф. Г. Мәҗитова, Д. Н. Нуруллина, А. А. Тимергалина, Д. Т. Хәйруллина, К. З. Хәмидуллина, Ф. Н. Хәкимова, Р. Г. Шаһиева, И. Г. Юзеев.

Баш мөхәррир – 43-27-83
Баш мөхәррир урынбасары –
Марат ӘМИРХАНОВ – 49-36-46
Җаваплы сәркатип –
Филисә ХӘКИМОВА – 49-36-42
Җаваплы сәркатип урынбасары –
Фәния САБИРОВА – 49-36-42
Бизәлеш мөхәррире –
Алсу ТИМЕРГАЛИНА – 49-36-42
Баш бухгалтер –
Алсу ХӘЙРЕТДИНОВА — 43-51-74

Бүлекләр:

Хатын-кыз сәясәте, иҗтимагый хәрәкәт, социаль мәсьәләләр –
Мәдинә АВЗАЛОВА – 49-36-44
Гаилә, әхлак, медицина хезмәте күрсәтү
– **Әлфия СӘГЪДИЕВА** – 49-36-33
Әдәбият һәм сәнгать, мәдәният, рухи мирас, гореф-гадәтләр –
Роза КАМАЛЕТДИНОВА – 49-36-44
Тәрбия, мәгариф, чит өлкәләр һәм мәмләкәтләр белән бәйләнеш –
Нурсөя ШӘЙДУЛЛИНА – 49-36-33
Хатлар, масса эшләре, кушымта –
Зөлидә ӘКБӘРОВА – 49-36-33
Гөлнар БАЗАРОВА – 49-36-40
Ләйсән ФӘЙЗРАХМАНОВА – 49-36-40
Компьютерда версткалау мөхәррире –
Лариса МАЛИКОВА – 49-36-42
Әдилә ВӘЛИЕВА – 49-36-42
Компьютерда җыю операторы –
Фәния ВӘЛИЕВА – 49-34-27
Фотокорреспондент
Газинур ХАФИЗОВ – 49-36-40

Тышлыкның беренче битендә: Рәисә Габдулла кызы СӘХИЕВА — Президент аппаратының дәүләт-хокук идарәсе җитәкчесе.

Д. ЮСУПОВ фотосурәте.

«Сөембикә» журналына ярдәм итәргә теләүчеләр игътибарына! Сез акчаларыгызны түбәндәге исәп буенча күчерә аласыз: ИНН 1657005751 р/с 2345127, кор/с 700161998 в ВКАБ РКЦ ГЦБ г. Казани МФО 049205798

Безнең адрес: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Оештыручылар: Татарстан Республикасы хөкүмәте; «Сөембикә» журналы редакциясенең хезмәт коллективы.

1926 елдан «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде.

Язма авторларының фикере белән редакция фикере узара тәнгәл килмәскә дә мөмкин.

Басарга кул куелды 10.09.97 ел. Заказ Н-435. Тираж 18807. Кәгазь форматы 60x90$^1/_8$. Күләме 5 басма табак. Татарстан газета-журнал нәшрияты типографиясе. Казан, Декабристлар урамы, 2.

Төс һәм аһәң балкышы

Фирәзә-зәңгәр айлы манзаралар тылсымчысы Зөфәр Низаметдин хакында, чын мәгънәсендә, тынгысыз шәхес, ә тудырганнарын — төс һәм аһәң балкышы дип фаразларга мөмкин булыр иде. Дөрес, иҗатының тумышында “Җир казучы галим — археолог”, “Мөселман кешесе”, “Гасыр башындагы татар гаиләсе” исемле адәм сурәтләре кергән гыйбарәләре дә булмады түгел. Ләкин ихлас дулкынлану, лиризм белән сугарылган бу әсәрләре сәнгать күгеннән чатнапянып үтә торды, алар урынына рәссамның иҗат бакчасында серле башлангычлар, хәвефле — химаялы яралгылар, гөлләр — манзаралар туа торды. Һәм шуны аныклап әйтергә мөмкин: туксанынчы еллар башында, Яр-Чаллы сәнгать мәктәбенең йөзе тәгаенләнгән чорларда, Зөфәрнең табынганы — бер яктан, дөнья, галәм киңлекләрендә яшәгән халыкларның тәрәккыятен фәнни нигезгә салучы Г. Н. Гумилев, татар этносының үз җәүһәрләрен системалаштырган олуг галим Ф. Вәлиев һәм дә мәшһүр сәнгаткяр Урманче булса, икенче яктан, күк гөмбәзләре астында чайкалган мәчет-манаралар, тәрбәләр, челтәрле ишек-пәнҗәрәләр (тәрәзә), балчык савыт-саба, серле кувшиннар, бизәкле диварлар, келәм-шамаилләр булды. Әйтерсең, гасыр урталарында табигать, галәм, раббенең кодрәтен танымый потпарастчылык (адәмгә, төрле шәхесләргә, җисемнәргә табыну) зәхмәтләренә кереп киткән, шактый рәсмиләшкән татар сынлы сәнгатенең иманын яңартты. Аны катып калган каноннардан, идеологик штамплардан арындырып, табигатьнең илаһилыгын таныган, адәмнең йөзе-тышкы кыяфәтеннән бигрәк, рухый гүзәллеген мәдхиялəгән сукмак буйлап алып кереп китте. Зөләйха сараендагы төсле вә гыйбрәтле кыйссаларны, мәңге сүнмәс шәрекъ келәмнәрен, Болгар, Алтын Урда архитектура әсәрләрендәге тутыкмас бизәкләрне хәтерләткән нәкышьләре әнә шундый изге ният белән дөнья күрде.

1987-1993 елларда Яр-Чаллы югары педагогия уку йортындагы рәсем факультетында армый-талмый милли кадрлар тәрбияләү өстендә эшләгән, аннан соңгаргы елларда Чаллы сәнгать төркеменең рухый мәзхәбен, иҗат концепциясен әзерләүгә гаҗәеп зур өлеш керткән, хөррият, иҗат иреге өчен барган көрәш мәйданнарында чыныккан Зөфәр Низаметдин үзенең шактый хәсрәтле, киеренке шәхси тормышы газапларын, ирләрчә кырыслык белән күңел иләкләре аша үткәрә, аларга дөрес бәһа бирә, сәнгатенең энҗе-якутларына әверелдерә белә. Аның әсәрләреннән кешелеклелек, киләчәккә инану, өмет вә гүзәллек бөркелеп тора. Аларда шәрекъ пантеизмы (үзенне табигать стихиясе белән дустанә итеп күрү, анда эреп, йолдыз-күлләр, үлән яфраклары итеп сиземләү, җанлы-җансызны бербөтен итеп тою-тану), суфыйчылык шаукымнары ярылып ята. Гүя Гомәр Хәйям, Хафиз, Сәйфи Сараи, Мөхәммәдьяр, Утыз Имәниләрнең шигъри метафоралары кабынып китә.


1996-1997 елларда Зөфәрнең иҗаты, шушы казанышларны туплаган хәлдә, яңа ачышларга, сәнгати киңлекләргә, образлылыкка юл тотты. Гәүдәсе белән бөтен яссылыкны каплаган, тамырлары мәңьеллыкларга үтеп кергән “шәҗәрә” агачлары, җәннәт җимешләре, асыл кошлар тирәсенә адәми затлар — сөекле гүзәл хатыннар, фидакарь асыл шагыйрьләр, акыл иясе иләмәннәр һәм башка шундый, берьяктан бик конкрет, икенче яктан, әкияти — бизәкле, шәрекъчә гомумиләштерелгән образлар куна башлады. Шулай итеп, бизәкле мотивлар арасында бүгенге көн чынбарлыгын, аның кешеләрен хыялындагы ассоциатив образлар аша, Иран-Япон сәнгате реализмы, авангард экспериментлары аша киләчәккә ургылып юл тоткан “татар картинасы” сыйфатлары пәйда була башлады.

Иншалла... Сәяси һәм икътисади тормышта беренчелеккә омтылган Яр-Чаллы шәһәренең үзе кебек, аның иҗаткарьләре дә милли мәдәният, милли сәнгать, милли картина өчен барган бәйгедә үз сүзләрен әйтергә омтылалар. Ә Зөфәр Низаметдин бу марафонда — беренчеләрдән.

Р. ШАҺИЕВА, сәнгать белгече.



“Мөселман кешесе”.
Зөфәр Низаметдин эше.



Иртә.



Тукай.



Төнге табигать.

Индекс 73002



Д.ЮСУПОВ фотосурәтләре

Сөмбелә — сөенеч

Көз. Җиһанда сөмбелә патшалыгы. Сөмбелә-сентябрь табигатьне үзенең тантанасына, сары алтынына урап, уңыш атлы бай, күркәм тәхетенә Сөмбелә — сылубикәсен күтәрә. Сөмбеләгә бирнә булып бакча-бакча алмалар нурда коена, амбар амбар гәрәбәдәй иген-тары тула.

Сөмбеләдә көзге муллык, куанычлар, вәгъдәләшкән туйлар көтә. Әби-бабаларыбыз мирас иткән туйлар чоры, бәхетл парлар чоры керә.

"Кызлы кеше — кызыл ›ай", — дигән халык. Һәркайсыгызга сөю-сәгадәт, рух байлыгы, гаилә шатлыгы насыйп булсын!